РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ
ҖИНАЯТЬ КОДЕКСЫ

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ҖИНАЯТЬ КОДЕКСЫ

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2006

УДК 343 : (094.4)
ББК 67.408
Р65

Китап
2004–2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын үтәү максатында нәшер ителә.

Россия Федерациясе Җинаять кодексын
татар теленә тәрҗемә итү буенча редакция комиссиясе:

Рәисе	Мөхәммәтшин Ф.Х.	Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Мөхәррире	Корманов М.М.	Татарстан Республикасы юстиция министры
Әгъзалары:	Әмиров К.Ф.	Татарстан Республикасы Прокуроры, икенче класслы юстиция дәүләт киңәшчесе
	Шәрифуллин Р.К.	Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе урынбасары
	Хисамов Н.Ш.	Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры
Тәрҗемәчеләре:	Әмирова М.Р.	Татарстан Республикасы Дәүләт Советы баш референты
	Хәйруллина Н.Г.	Татарстан Республикасы Дәүләт Советы баш референты
Җаваплы сәркатибе	Сәләхетдинов А.М.	Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы әйдәп баручы белгече
Рецензентлары:	Аверьянов М.А.	Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе ярдәмчесе
	Шакирьянов Р.В.	Татарстан Республикасы Югары суды судьясы
	Асылгәрәев Ш.Н.	Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм лексикография бүлеге мөдире

Р65 Россия Федерациясе Җинаять кодексы/ Тәрҗ.: М.Р.Әмирова, Н.Г.Хәйруллина. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 199 б.

ISBN 5-298-03961-8

© Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, 2006
ISBN 5-298-03961-8
© Татарстан китап нәшрияты, 2006

Россия Федерациясе Җинаять кодексы

1996 елның 13 июнендәге 63-ФЗ номерлы

(2006 елның 5 гыйнварына булган үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)

1996 елның 24 маенда Дәүләт Думасы тарафыннан кабул ителде

1996 елның 5 июнендә Федерация Советы тарафыннан хупланды

ГОМУМИ ӨЛЕШ

I кисәк. Җинаять законы

1 бүлек. Россия Федерациясе Җинаять кодексының бурычлары һәм принциплары

1 статья. Россия Федерациясе җинаять законнары

1. Россия Федерациясе җинаять законнары әлеге Кодекстан тора. Җинаять җаваплылыгы каралган яңа законнар әлеге Кодекска кертелергә тиеш.

2. Әлеге Кодекс Россия Федерациясе Конституциясенә һәм халыкара хокукның гомумтанылган принципларына һәм нормаларына нигезләнә.

2 статья. Россия Федерациясе Җинаять кодексының бурычлары

1. Әлеге Кодексның бурычлары кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, милекне, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген, әйләнә-тирә мохитне, Россия Федерациясенең конституциячел корылышын җинаятьчел янаулардан саклаудан, кешелек тынычлыгын һәм иминлеген тәэмин итүдән, шулай ук җинаятьләрне кисәтүдән гыйбарәт.

2. Шушы бурычларны гамәлгә ашыру өчен әлеге Кодекс җинаять җаваплылыгының нигезен һәм принципларын билгели, шәхес, җәмгыять яисә дәүләт өчен нинди куркыныч гамәлләрнең җинаять булып танылуын билгели, җинаятьләр кылган өчен җәза төрләрен һәм җинаяти-хокукый характердагы башка чараларны билгели.

3 статья. Законлылык принцибы

1. Кылган гамәлне җинаятькә кертү, шулай ук аның өчен җәза куллану һәм башка җинаяти-хокукый нәтиҗәләр әлеге Кодекс белән генә билгеләнә.

2. Җинаять законын аналогия буенча куллану рөхсәт ителми.

4 статья. Гражданнарның закон каршында тигезлек принцибы

Җинаять кылган затлар, җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәти һәм вазифаи хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, нинди иҗтимагый берләшмәләрдә торуына, шулай ук башка шартларга бәйсез рәвештә, закон каршында тигез булалар һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар.

5 статья. Гаепләү принцибы

1. Зат үзе тарафыннан кылынган (кылынмаган) җәмгыяви куркыныч гамәлләр өчен һәм аның гаебе аркасында барлыкка килгән җәмгыяви куркыныч нәтиҗәләр өчен генә җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш.

2. Объектив гаеп тагуга, ягъни гаепсез килеш зарар китергән өчен җинаять җаваплылыгы билгеләүгә юл куелмый.

6 статья. Гаделлек принцибы

1. Җинаять кылган затка карата кулланылучы җәза һәм җинаяти-хокукый характердагы башка чаралар билгеләү гадел булырга тиеш, ягъни җәмгыяви куркыныч җинаятьнең характерына һәм дәрәҗәсенә, аны кылган шартларга һәм гаепленең шәхесенә туры килергә тиеш.

2. Бер үк җинаять өчен беркем дә ике мәртәбә җинаять җаваплылыгына тартыла алмый.

7 статья. Гуманизм принцибы

1. Россия Федерациясе җинаять законнары кеше иминлеген тәэмин итә.

2. Җинаять кылган затка карата кулланылучы җәзаның һәм җинаяти-хокукый характердагы башка чараларның максаты физик газаплар ясау яисә кешелек абруен төшерү була алмый.

8 статья. Җинаять җаваплылыгы өчен нигез

Әлеге Кодекста каралган җинаять составының барлык билгеләре булган гамәл кылу җинаять җаваплылыгы өчен нигез булып тора.

2 бүлек. Җинаять законының гамәлдә булу вакыты һәм даирәсе

9 статья. Җинаять законының гамәлдә булу вакыты

1. Гамәл кылуның җинаятьчеллеге һәм аңа җәза билгеләнергә тиешлеге шушы гамәлне кылган вакытта гамәлдә булучы җинаять законы белән билгеләнә.

2. Нәтиҗәләр барлыкка килү вакытына бәйсез рәвештә, җәмгыяви куркыныч гамәл кылу (кылмау) вакыты җинаять кылган вакыт булып танылa.

10 статья. Җинаять законының кире көчкә ия булуы

1. Җинаять кылган затның гамәлендәге җинаятьчеллекне бетерә, җәзаны йомшарта яисә аның хәлен башкача яхшырта торган җинаять законы кире көчкә ия була, ягъни шундый закон үз көченә кергәнче тиешле гамәлләр кылган затларга, шул исәптән җәза узучы яисә җәза узган, әмма хөкем ителгәнлеге сакланып калган затларга кагыла. Җәзаны көчәйтә яисә затның хәлен башкача начарайта торган гамәлнең җинаятьчеллеген билгеләүче җинаять законы кире көчкә ия булмый.

2. Әгәр яңа җинаять законы җәза узучы зат кылган гамәл өчен җәзаны йомшарта торган булса, бу җәза чоры яңа җинаять законында каралган чикләрдә кыскартылырга тиеш.

11 статья. Россия Федерациясе территориясендә җинаять кылган затларга карата җинаять законының гамәлдә булуы

1. Россия Федерациясе территориясендә җинаять кылган зат әлеге Кодекс буенча җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш.

2. Россия Федерациясенең территориаль сулары яисә һава киңлеге чикләрендә кылынган җинаятьләр Россия Федерациясе территориясендә кылган җинаятьләр дип танылa. Әлеге Кодексның гамәли көче Россия Федерациясенең континенталь шельфында һәм махсус икътисади зонасында кылган җинаятьләргә дә кулланыла.

3. Россия Федерациясеннән читтәге ачык сулыкта яисә һава киңлегендә урнашкан Россия Федерациясе портына беркетелгән суднода җинаять кылган зат, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, әлеге Кодекс буенча җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш. Нинди урында булуга бәйсез рәвештә, Россия Федерациясенең хәрби корабында яисә хәрби һава судносында җинаять кылган зат та әлеге Кодекс буенча җинаять җаваплылыгына тартыла.

4. Чит дәүләтләрнең дипломатик вәкилләре һәм иммунитеттан файдаланучы башка гражданнар Россия Федерациясе территориясендә җинаять кылган очракта, аларның җинаять җаваплылыгы халыкара хокук нормалары нигезендә хәл ителә.

12 статья. Россия Федерациясеннән читтә җинаять кылган затларга карата җинаять законының гамәлдә булуы

1. Россия Федерациясеннән читтә җинаять кылган Россия Федерациясе гражданнары һәм Россия Федерациясендә даими яшәүче гражданлыгы булмаган затлар, әгәр алар гамәл кылган территориядәге дәүләттә бу гамәл җинаять дип танылса һәм бу затлар чит дәүләттә хөкем ителмәгән булса, әлеге Кодекс буенча җинаять җаваплылыгына тартылалар. Әлеге затларны хөкем иткәндә, җәза җинаять кылган территориядәге чит дәүләт законында каралган санкциянең иң югары чигеннән артыграк була алмый.

2. Россия Федерациясе хәрби частьларының Россия Федерациясеннән читтә дислокацияләнгән хәрби хезмәткәрләре чит дәүләт территориясендә кылган җинаятьләре өчен, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, әлеге Кодекс буенча җинаять җаваплылыгына тартылалар.

3. Россия Федерациясендә даими яшәмәүче чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар Россия Федерациясеннән читтә җинаять кылганда, бу җинаять Россия Федерациясе мәнфәгатьләренә каршы юнәлдерелгән очракларда һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә каралган очракларда, әгәр алар чит дәүләттә хөкем ителмәгән булсалар, әлеге Кодекс буенча җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш булалар һәм Россия Федерациясе территориясендә җинаять җаваплылыгына җәлеп ителәләр.

13 статья. Җинаять кылган затларны тапшыру

1. Чит дәүләт территориясендә җинаять кылган Россия Федерациясе гражданнары ул дәүләткә тапшырылмыйлар.

2. Россия Федерациясеннән читтә җинаять кылып, Россия Федерациясе территориясенә килгән чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар җинаять җаваплылыгына җәлеп итү яисә җәза узу өчен Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә чит дәүләткә тапшырылырга мөмкин.

II кисәк. Җинаять

3 бүлек. Җинаять төшенчәсе һәм җинаять төрләре

14 статья. Җинаять төшенчәсе

1. Әлеге Кодекста җәза билгеләнү белән куркытып тыелган, гаеп тагарлык итеп кылынган җәмгыяви куркыныч гамәл җинаять дип танылa.

2. Формаль яктан әлеге Кодекста каралган нинди дә булса гамәл билгеләренә ия булган, әмма әһәмияте ягыннан җәмгыяви куркыныч тудырмый торган гамәл кылу (кылмау) җинаять булмый.

15 статья. Җинаять категорияләре

1. Әлеге Кодекста каралган гамәлләр, характерына һәм җәмгыяви куркыныч булу дәрәҗәсенә бәйле рәвештә, авыр булмаган җинаятьләргә, уртача авырлыктагы җинаятьләргә, авыр җинаятьләргә һәм аеруча авыр җинаятьләргә бүленә.

2. Аңлы рәвештә һәм саксызлык аркасында кылган һәм алар өчен әлеге Кодекста ике елдан артмый торган иректән мәхрүм итү рәвешендә максималь җәза каралган гамәлләр авыр булмаган җинаятьләр дип танылa.

3. Аңлы рәвештә кылган һәм алар өчен әлеге Кодекста биш елдан артмый торган иректән мәхрүм итү рәвешендә максималь җәза каралган гамәлләр һәм саксызлык аркасында кылган һәм алар өчен әлеге Кодекста ике елдан күбрәк иректән мәхрүм итү рәвешендә максималь җәза каралган гамәлләр уртача авырлыктагы җинаятьләр дип танылa.

4. Аңлы рәвештә кылган һәм алар өчен әлеге Кодекста ун елдан артмый торган иректән мәхрүм итү рәвешендә максималь җәза каралган гамәлләр авыр җинаятьләр дип танылa.

5. Аңлы рәвештә кылган һәм алар өчен әлеге Кодекста ун елдан күбрәк иректән мәхрүм итү рәвешендә яисә тагын да катырак җәза каралган гамәлләр аеруча авыр җинаятьләр дип танылa.

16 статья. *Үз көчен югалтты.*

17 статья. Җинаятьләр җыелмасы

1. Ике яисә аннан күбрәк кылынган җинаять, әгәр зат аларның берсе өчен дә хөкем ителмәгән булса, җинаятьләр җыелмасы дип танылa, моңа ике яисә аннан күбрәк кылынган җинаятьләр әлеге Кодексның Махсус өлешендәге статьяларда аеруча каты җәза бирелә торган хәлләр буларак каралган

очраклар керми. Җыелма җинаятьләрдә зат һәр кылган гамәл өчен әлеге Кодексның тиешле статьясы яисә статьясының бер өлеше нигезендә җинаять җаваплылыгына тартыла.

2. Әлеге Кодексның ике яисә аннан күбрәк статьясында каралган җинаять билгеләре булган бер гамәл кылу (кылмау) да җинаятьләр җыелмасы дип таныла.

3. Әгәр җинаять гомуми һәм махсус нормалар буенча каралып, җинаятьләр җыелмасы булмаса, җинаять җаваплылыгы махсус норма буенча барлыкка килә.

18 статья. Җинаятьләр рецидивы

1. Аңлы рәвештә кылган җинаять өчен элек хөкем ителгән затның аңлы рәвештә җинаять кылуы җинаятьләр рецидивы дип таныла.

2. Түбәндәге очракларда җинаятьләр рецидивы куркыныч дип таныла:

а) аңлы рәвештә кылган уртача авырлыктагы җинаять өчен ирektән мәхрүм итү рәвешендә элек ике яисә аннан күбрәк мәртәбә хөкем ителгән зат авыр җинаять кылганда һәм аның өчен ул реаль рәвештә ирektән мәхрүм итүгә хөкем ителгәндә;

б) кылган авыр яисә аеруча авыр җинаять өчен реаль рәвештә ирektән мәхрүм итүгә элек хөкем ителгән зат авыр җинаять кылганда.

3. Түбәндәге очракларда җинаятьләр рецидивы аеруча куркыныч дип таныла:

а) кылган авыр җинаять өчен элек ике мәртәбә реаль рәвештә ирektән мәхрүм итүгә хөкем ителгән зат авыр җинаять кылган һәм аның өчен реаль рәвештә ирektән мәхрүм итүгә хөкем ителгәндә;

б) кылган авыр җинаять өчен элек ике мәртәбә хөкем ителгән яисә кылган аеруча авыр җинаять өчен элек хөкем ителгән зат аеруча авыр җинаять кылганда.

4. Җинаятьләр рецидивын таныганда, түбәндәгеләр исәпкә алынмый:

а) аңлы рәвештә авыр булмаган җинаять кылган өчен хөкем ителү;

б) унсигез яшькә кадәрге затның кылган җинаятьләре өчен хөкем ителүе;

в) әгәр шартлы рәвештә хөкем ителү яисә хөкем карарын үтәүне кичектерү юкка чыгарылмаган һәм зат ирektән мәхрүм итү урынына җәза узу өчен җибәрелмәгән булса, шартлы рәвештә хөкем ителгән йә хөкем карарын үтәү кичектерелгән җинаятьләр өчен хөкем ителү, шулай ук әлеге Кодексның 86 статьясында билгеләнгән тәртиптә кире алынган һәм юкка чыгарылган хөкем ителү.

5. Җинаятьләр рецидивы әлеге Кодекста каралган нигездә һәм чикләрдә катырак җәза билгеләүгә китерә.

4 бүлек. Җинаять җаваплылыгына тартылырга тиешле затлар

19 статья. Җинаять җаваплылыгының төп шартлары

Үз акылындагы, әлеге Кодекста билгеләнгән яшькә җиткән физик зат кына җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш.

20 статья. Җинаять җаваплылыгы башлана торган яшь

1. Җинаять кылу вакытына уналты яше тулган зат җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш.

2. Җинаять кылу вакытына ундүрт яше тулган затлар үтергән (105 статья), кеше сәламәтлегенә аңлы рәвештә авыр зыян китергән (111 статья), кеше сәламәтлегенә белә торып уртача авырлыкта зыян китергән (112 статья), кеше урлаган (126 статья), көчләгән (131 статья), сексуаль характердагы көч кулланган (132 статья), урлаган (158 статья), талаган (161 статья), юлбасарлык кылган (162 статья), куркытып (акча яки әйбер) алган (163 статья), урлау максаты куймыйча гына законсыз рәвештә автомобиль яисә башка транспорт чарасын куып киткән (166 статья), авыр шартлар тудырып, белә торып мөлкәтне юкка чыгарган яисә аңа зыян салган (167 статьяның икенче өлеше), терроризм (205 статья), тотык алган (206 статья), терроризм акты турында белә торып ялган хәбәр биргән (207 статья), авыр шартлар тудырып, хулиганлык кылган (213 статьяның икенче өлеше), вандализм (214 статья), корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч матдәләр һәм шартлату җайланмалары урлаган йә куркытып алган (226 статья), наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр урлаган йә куркытып алган (229 статья), транспорт чараларын яисә аралашу юлларын файдаланып булмый торган хәлгә китергән (267 статья) өчен җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш.

3. Әгәр балигъ булмаган зат әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә каралган яшькә җитсә, әмма психик кимчелеккә бәйле булмаган килеш психик үсеше тоткарлану аркасында җәмгыяви куркыныч гамәл кылуның (кылмауның) фактик характерын һәм җәмгыяви куркыныч булуын тулысынча аңлап бетермәгән йә аларга җитәкчелек итә алмаган булса, ул җинаять җаваплылыгына тартылмый.

21 статья. Үз акылында булмау

1. Җәмгыяви куркыныч гамәл кылган вакытта үз акылында булмаган, ягъни хроник рәвештә психикасы какшаган, психикасы вакытлыча какшаган, акыл зәгыйфьлеге йә башка психик авыру халәттә булуы аркасында үзенең кылган (кылмаган) гамәлләренең фактик характерын һәм җәмгыяви куркыныч булуын аңлап бетермәгән йә аларга җитәкчелек итә алмаган зат җинаять җаваплылыгына тартылмый.

2. Җинаять законында каралган җәмгыяви куркыныч гамәлне үз акылында булмаган килеш кылган затка әлеге Кодекста каралган медицина характерындагы мәҗбүри чаралар билгеләнергә мөмкин.

22 статья. Психикасы үз акылына зыян китермәслек итеп какшаган затларның җинаять җаваплылыгы

1. Психикасы какшаган, үз акылындагы зат җинаять кылган вакытта үзенең кылган (кылмаган) гамәлләренең фактик характерын һәм җәмгыяви куркыныч булуын тулысынча аңлап бетермәсә йә аларга җитәкчелек итә алмаса, җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш.

2. Психикасы үз акылына зыян китермәслек итеп какшаган булу җәза билгеләгәндә суд тарафыннан исәпкә алына һәм медицина характерындагы мәҗбүри чаралар билгеләү өчен нигез булырга мөмкин.

23 статья. Исерек килеш җинаять кылган затларның җинаять җаваплылыгы

Алкоголь, наркотик чаралар яисә бүтән төрле баш миңгерәткеч матдәләр кулланып исергән килеш җинаять кылган зат җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш.

5 бүлек. Гаеп

24 статья. Гаеп рәвешләре

1. Аңлы рәвештә яисә саксызлык аркасында гамәл кылган зат җинаятьтә гаепле дип танылa.

2. Бары тик саксызлык аркасында гына кылган гамәл әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда аерым каралган очракта гына җинаять дип танылa.

25 статья. Аңлы рәвештә кылган җинаять

1. Җинаять нәтиҗәләрен алдан күздә тотып яисә күздә тотмыйча кылган гамәл аңлы рәвештә кылган җинаять дип танылa.

2. Әгәр зат, үзенең кылган (кылмаган) гамәлләренең җәмгыяви куркыныч булуын аңлап, җәмгыяви куркыныч нәтиҗәләр барлыкка китерергә мөмкин булуын яисә барлыкка килүен алдан күздә тотып һәм аларның барлыкка килүен теләп җинаять кылса, ул алдан күздә тотып кылган җинаять дип таныла.

3. Әгәр зат, үзенең кылган (кылмаган) гамәлләренең җәмгыяви куркыныч булуын аңлап, җәмгыяви куркыныч нәтиҗәләр барлыкка китерергә мөмкин булуын алдан күреп, теләмичә, әмма аңлы рәвештә шундый нәтиҗәләргә китереп йә аларга ваемсызлык күрсәтеп җинаять кылса, ул алдан күздә тотмыйча кылган җинаять дип таныла.

26 статья. Саксызлык аркасында кылган җинаять

1. Уйламыйча яисә игътибарсызлык аркасында кылган җинаять саксызлык аркасында кылган җинаять дип таныла.

2. Әгәр зат, үзенең кылган (кылмаган) гамәлләренең җәмгыяви куркыныч нәтиҗәләр барлыкка китерергә мөмкин булуын алдан күреп, әмма шуңа җитәрлек нигезләрсез, үз-үзенә ышанып, шул нәтиҗәләрне булдырмаска исәп тотып җинаять кылса, ул уйламыйча кылган җинаять дип таныла.

3. Әгәр зат үзенең кылган (кылмаган) гамәлләренең җәмгыяви куркыныч нәтиҗәләр барлыкка китерергә мөмкин булуын алдан күрмәгән килеш, әмма тиешенчә игътибарлы һәм алдан күреп эш иткәндә бу нәтиҗәләрне алдан күрергә тиеш булып һәм күрә алып җинаять кылса, ул игътибарсызлык аркасында кылган җинаять дип таныла.

27 статья. Ике төрле гаебе булган җинаять кылган өчен җаваплылык

Әгәр аңлы рәвештә кылган җинаять аркасында закон буенча катырак җәза билгеләнә торган авыр нәтиҗәләр барлыкка килсә һәм зат аларны күздә тотмаган булса, мондый нәтиҗәләр өчен җинаять җаваплылыгы аларның барлыкка килү мөмкинлеген зат алдан белгән, әмма шуңа җитәрлек нигезләрсез, үз-үзенә ышанып, ул нәтиҗәләрне бетерергә тырышып караган очракта гына яисә зат бу нәтиҗәләрнең барлыкка килү мөмкинлеген алдан күрмәгән, әмма күрергә тиеш һәм күрергә мөмкин булган очракта гына барлыкка килә. Тулаем алганда, мондый җинаять аңлы рәвештә кылган җинаять дип таныла.

28 статья. Гаепсез зыян китерү

1. Әгәр зат кылган гамәлен аңлап җиткермәсә һәм үзенең гамәлләренең җәмгыяви куркыныч булуын төрле сәбәпләр аркасында аңлый алмаган булса йә җәмгыяви куркыныч нәти-

җәләрнең барлыкка килү мөмкинлеген алдан күрмәгән һәм төрле сәбәпләр аркасында аларны күрергә тиеш булмаган яисә күрә алмаган булса, ул гамәл гаепсез кылган гамәл дип таныла.

2. Әгәр гамәл кылган зат үзенең кылган (кылмаган) гамәлләренең җәмгыяви куркыныч нәтиҗәләргә китерү мөмкинлеген алдан күреп тә, үзенең психофизиологик сыйфатларының экстремаль шартлар таләпләренә яисә нерв-психик киеренкелеккә туры килмәве аркасында бу нәтиҗәләрне булдырмый кала алмаган булса, мондый гамәл дә гаепсез кылган гамәл дип таныла.

6 бүлек. Тәмамланмаган җинаять

29 статья. Тәмамланган һәм тәмамланмаган җинаятьләр

1. Әгәр зат кылган гамәлдә әлеге Кодекста каралган җинаять составының барлык билгеләре булса, ул тәмамланган җинаять дип таныла.

2. Җинаятькә әзерләнү һәм җинаять кылуга омтылу тәмамланмаган җинаять дип таныла.

3. Тәмамланмаган җинаять өчен җинаять җаваплылыгы, әлеге Кодексның 30 статьясына нигезләнеп, шушы Кодексның тәмамланган җинаять өчен җаваплылык каралучы статьясы буенча барлыкка килә.

30 статья. Җинаятькә әзерләнү һәм җинаять кылуга омтылу

1. Затның җинаять кылу чараларын һәм коралларын эзләп табуы, әзерләве яисә җайлаштыруы, җинаятьтә катнашучыларны эзләп табуы, җинаять кылу турында сүз берләшүе йә җинаять кылу өчен аңлы рәвештә башка шартлар тудыруы, әгәр мондый чакта җинаять әлеге затка бәйле булмаган сәбәпләр аркасында ахыргача җиткерелмәгән булса, бу җинаятькә әзерләнү дип таныла.

2. Җинаять җаваплылыгы бары тик авыр һәм аеруча авыр җинаятьләргә әзерләнгән өчен генә барлыкка килә.

3. Затның аңлы рәвештә кылган һәм турыдан-туры җинаять кылуга юнәлдерелгән гамәлләре (гамәл кылмаулары), әгәр мондый чакта җинаять әлеге затка бәйле булмаган сәбәпләр аркасында ахыргача җиткерелмәгән булса, җинаять кылуга омтылу дип таныла.

31 статья. Җинаятьтән ихтыяри рәвештә баш тарту

1. Затның, җинаятьне ахыргача җиткерү мөмкинлеген аңлап, җинаятькә әзерләнүен туктатуы йә турыдан-туры җина-

ятькә юнәлдерелгән гамәлләрен (гамәл кылмауларын) туктатуы җинаятьтән ихтыяри рәвештә баш тарту дип танылa.

2. Әгәр зат җинаятьне ахыргача җиткерүдән ихтыяри рәвештә һәм бөтенләй баш тартса, ул шул җинаять өчен җинаять җаваплылыгына тартылмый.

3. Җинаятьне ахыргача җиткерүдән ихтыяри рәвештә баш тарткан затның кылган гамәлендә башка җинаять составы булган очракта гына, ул җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш.

4. Җинаятьне оештыручы һәм җинаять кылуга котыртучы затлар хакимият органнарына вакытында җиткерелгән хәбәр белән яисә күрелгән башка чаралар белән җинаять башкаручының аны ахыргача җиткерүен булдырмый калсалар, бу затлар җинаять җаваплылыгына тартылмыйлар. Җинаять кылуга ярдәм итүче җинаятьне булдырмый калу өчен аның үзенә бәйле барлык чараларны күрсә, ул җинаять җаваплылыгына тартылмый.

5. Оештыручының яисә котыртучының әлеге статьяның 4 өлешендә каралган гамәлләре җинаятьне башкаручы тарафыннан аны башкармый калуга китермәсә, алар күргән барлык чаралар җәза билгеләгәндә суд тарафыннан җәзаны җиңеләйтә торган шартлар дип танылырга мөмкин.

7 бүлек. Җинаятьтә катнашу

32 статья. Җинаятьтә катнашу төшенчәсе

Аңлы рәвештә кылган җинаятьтә ике яисә аннан күбрәк затның бергә торып бергәләп катнашуы җинаятьтә катнашу дип танылa.

33 статья. Җинаятьтә катнашучыларның төрләре

1. Башкаручы белән беррәттән оештыручы, котыртучы һәм ярдәмче җинаятьтә катнашучылар дип танылa.

2. Җинаятьне турыдан-туры башкаручы йә башка затлар (башкаручылар) белән бергә аны кылуда турыдан-туры катнашучы зат, шулай ук яше, үз акылында булмавы яки әлеге Кодекста каралган башка шартлар аркасында җинаять җаваплылыгына тартылмый торган бүтән затларны файдалану юлы белән җинаять кылган зат җинаятьне башкаручы дип танылa.

3. Җинаять кылуны оештырган яисә аны башкаруга җитәкчелек иткән зат, шулай ук оешкан төркем яки җинаять берлеген (җинаять оешмасын) туплаган йә алар белән җитәкчелек иткән зат җинаятьне оештыручы дип танылa.

4. Башка затны күндерү, сатып алу, янау яисә бүтән ысул белән җинаять кылуга этәргән зат котыртучы дип таныла.

5. Киңәшләр, күрсәтмәләр, мәгълүмат, җинаять кылу чаралары яисә кораллары биреп йә тоткарлыкларны юкка чыгару юлы белән җинаять кылуга ярдәм иткән зат, шулай ук җинаятьчене, җинаять кылу чараларын яисә коралларын, җинаять эзләрен йә җинаять юлы белән табылган әйберләрне яшереп калырга алдан вәгъдә иткән зат, шулай ук шундый әйберләрне сатып алырга яисә сатарга алдан вәгъдә биргән зат ярдәмче дип таныла.

34 статья. Җинаятьтә катнашучыларның җаваплылыгы

1. Җинаятьтә катнашучыларның җаваплылыгы аларның һәркайсының җинаять кылуда фактта катнашу характеры һәм дәрәҗәсе белән билгеләнә.

2. Җинаятьне башкаруда катнашучылар, әлеге Кодексның 33 статьясына нигезләнмичә, бергәләп кылган җинаять өчен әлеге Кодексның Махсус өлешендәге статьясы буенча җавап бирәләр.

3. Оештыручы, котыртучы һәм ярдәмченең җинаять җаваплылыгы, әлеге Кодексның 33 статьясына нигезләнеп, җинаять кылган өчен җәза каралучы статья буенча барлыкка килә, моңа алар бер үк җинаятьне башкаруда катнашучылар булган очраклар керми.

4. Әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда махсус күрсәтелгән һәм шушы статьяда каралган җинаятьне кылуда катнашкан җинаять субъекты булмаган зат әлеге җинаять өчен җинаять җаваплылыгына аны оештыручы, котыртучы йә ярдәмче буларак тартыла.

5. Башкаручы үзенә бәйле булмаган шартлар аркасында җинаятьне ахыргача җиткермәгән очракта, калган катнашучылар җинаятькә әзерләнгән яисә җинаять кылуга омтылган өчен җинаять җаваплылыгына тартылалар. Үзенә бәйле булмаган шартлар аркасында башка затларны җинаять кылуга тарта алмаган зат та җинаять җаваплылыгына җинаятькә әзерләнгән өчен тартыла.

35 статья. Затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме, оешкан төркем яисә җинаять берлеге (җинаять оешмасы) тарафыннан җинаять кылу

1. Җинаять кылуда ике яисә аннан күбрәк башкаручы алдан килешмичә генә бергәләп катнашсалар, мондый җинаять затлар төркеме тарафыннан башкарылган җинаять дип таныла.

2. Җинаять кылуда затлар бергәләп җинаять кылу турында алдан килешеп катнашсалар, мондый җинаять алдан килешенгән затлар төркеме тарафыннан башкарылган җинаять дип таныла.

3. Җинаять бер яисә берничә җинаятьне кылу өчен алдан берләшкән затларның тотрыклы төркеме тарафыннан башкарылган булса, ул оешкан төркем тарафыннан башкарылган җинаять дип таныла.

4. Җинаять авыр яисә аеруча авыр җинаятьләр кылу өчен төзелгән һәм берләшеп оешкан төркем (оешма) йә шул ук максатларда төзелгән һәм оешкан төркемнәр берләшмәсе тарафыннан башкарылса, мондый җинаять җинаять берлеге (җинаять оешмасы) тарафыннан башкарылган җинаять дип таныла.

5. Оешкан төркемне яисә җинаять берлеген (җинаять оешмасын) төзегән зат йә аларга җитәкчелек итүче зат әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяларда каралган очракларда шуларны оештырган һәм аларга җитәкчелек иткән өчен, шулай ук алдан күздә тоткан килеш оешкан төркем яисә җинаять берлеге (җинаять оешмасы) кылган барлык җинаятьләр өчен җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш. Оешкан төркемдә яисә җинаять берлегендә (җинаять оешмасында) башка катнашучылар җинаять җаваплылыгына әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяларда каралган очракларда шуларда катнашкан өчен, шулай ук үзләре әзерләүдә яисә кылуда катнашкан җинаятьләр өчен җинаять җаваплылыгына тартылалар.

6. Әлеге Кодексның Махсус өлешендәге статьяларда каралмаган очракларда оешкан төркем төзү, нинди җинаятьләр кылу өчен төзелгән булса, шул җинаятьләрне кылуга әзерләнгән өчен билгеләнә торган җинаять җаваплылыгына китерә.

7. Затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем яисә җинаять берлеге (җинаять оешмасы) тарафыннан җинаять кылу әлеге Кодекста каралган нигездә һәм чикләрдә катырак җәза билгеләүгә китерә.

36 статья. Җинаять башкаручының эксцессы

Җинаять кылучының җинаятьтә башка катнашучыларның фикерен исәпкә алмыйча кылган җинаяте башкаручы эксцессы дип таныла. Башкаручы эксцессы өчен җинаятьтә башка катнашучылар җинаять җаваплылыгына тартылмый.

8 бүлек. Кылган гамәлдәге җинаятьчеллекне юкка чыгаручы шартлар

37 статья. Үз-үзеңне яклау

1. Үз-үзеңне яклап, ягъни шәхесне һәм сакланучы затның яисә башка затларның хокукларын, җәмгыятьнең яисә дәүләтнең закон белән саклана торган мәнфәгатьләрен җәмгыяви куркыныч янаулардан яклап, әгәр бу янау көч куллану, сакланучының яисә башка затның гомеренә карата йә шундый көч куллану белән куркыту рәвешендә булса, һөҗүм итүче затка зыян китерү җинаять дип саналмый.

2. Көч куллану, сакланучы затның яисә башка затның гомеренә куркыныч янау йә шундый көч куллану белән турыдан-туры куркыту рәвешендәге янаулардан яклау, әгәр бу очракта үз-үзеңне яклау тиешле чиктән артып китмәгән булса, ягъни янауның характерына һәм куркынычлылыгына туры килми торган алдан уйланып кылган гамәлләр булмаса, законлы дип таныла.

2.1. Сакланучы зат янауның көтелмәгән булуы аркасында һөҗүм итү дәрәҗәсен һәм аның куркынычлылык характерын объектив бәяли алмаса, сакланучы затның тиешле саклану гамәлләре үз-үзеңне яклауның чикләреннән артмаган дип таныла.

3. Һөнәри яисә башка махсус әзерлегенә һәм хезмәт урынына бәйсез рәвештә, барлык затлар бертигез дәрәҗәдә үз-үзен якларга хокуклы. Зат әлеге хокукка җәмгыяви куркыныч янаулардан качу мөмкинлегенә бәйсез рәвештә ия була яисә башка затларга яки хакимият органнарына ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы була.

38 статья. Җинаять кылган затны кулга алганда зыян китерү

1. Җинаять кылган затны хакимият органнарына китерү һәм аның яңа җинаятьләр кылу ихтималын булдырмый калу өчен кулга алганда зыян китерү, әгәр мондый затны башка чаралар белән кулга алу мөмкин булмаса һәм моның өчен кирәкле чараларны куллану билгеләнгән чиктән арттырылмаган булса, җинаять дип саналмый.

2. Кулга алынучы затка ул кылган җинаятьнең характерына һәм җәмгыяви куркынычлылык дәрәҗәсенә, кулга алу шартларына ачыктан-ачык туры килми торган, шартлар таләп итми торган һәм кирәк булмаган килеш чиктән тыш чаралар күрү белән зыян китерелсә, бу җинаять кылучы затны кулга алу өчен кирәкле чараларны билгеләнгән чиктән арттырып җибәрү дип таныла. Чаралар куллануны шулай арт-

тырып җибәрү бары тик аңлы рәвештә зыян китергән очракларда гына җинаять җаваплылыгына китерә.

39 статья. Иң чик зарурлык

1. Бик кирәк чакта, ягъни шәхескә һәм әлеге затның яисә башка затларның хокукларына, җәмгыятьнең яисә дәүләтнең закон белән саклануучы мәнфәгатьләренә турыдан-туры янаучы куркынычны бетерү өчен, әгәр бу куркынычны башка чаралар белән бетерү мөмкин булмаса һәм мондый чакта иң чик зарурлыкның чикләре арттырылмаган булса, җинаять законы белән саклануучы мәнфәгатьләргә зыян китерү җинаять дип танылмый.

2. Янаучы куркынычның характерына һәм дәрәҗәсенә һәм куркыныч бетерелгән шартларга ачыктан-ачык туры килми торган зыян китерү, әгәр күрсәтелгән мәнфәгатьләргә зыян шул ук дәрәҗәдә яисә булдырмый калган зыяннан шактый артыграк китерелгән булса, иң чик зарурлык чикләрен арттыру дип таныла. Мондый арттыру бары тик аңлы рәвештә зыян китергән очракларда гына җинаять җаваплылыгына китерә.

40 статья. Физик яисә психик мәҗбүр итү

1. Җинаять законы белән саклана торган мәнфәгатьләргә физик мәҗбүр итү нәтиҗәсендә зыян китерү, әгәр мондый мәҗбүр итү аркасында зат үз гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән идарә итә алмаса, җинаять дип танылмый.

2. Җинаять законы белән саклана торган мәнфәгатьләргә психик мәҗбүр итү нәтиҗәсендә, шулай ук физик мәҗбүр итү нәтиҗәсендә зыян китергән өчен җинаять җаваплылыгы турындагы мәсьәлә, әгәр шулай мәҗбүр итү аркасында зат үз гамәлләренә идарә итү мөмкинлеген саклап калса, әлеге Кодексның 39 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып хәл ителә.

41 статья. Нигезле рәвештә хәтәр гамәл кылу

1. Җәмгыяви файдалы максатка ирешү өчен нигезле рәвештә хәтәр гамәл кылганда җинаять законы белән саклана торган мәнфәгатьләргә зыян китерү җинаять дип танылмый.

2. Әгәр куелган максатка хәтәр гамәлләр кылуга бәйләнешсез гамәлләр белән (гамәлләрсез) ирешеп булмаса һәм хәтәр гамәл кылган зат җинаять законы белән саклана торган мәнфәгатьләргә зыян килүне булдырмый калу өчен җитәрлек чаралар күргән булса, хәтәр гамәл кылу нигезле дип таныла.

3. Хәтәр гамәл кылу күп кешеләр гомеренә куркыныч янауга, экологик һәлакәтләр яисә җәмгыяви бәла-казалар куркынычына ачыктан-ачык бәйле булса, ул нигезле дип танылмый.

42 статья. Боерыкны яисә күрсәтмәне үтәү

1. Җинаять законы белән саклана торган мәнфәгатьләргә үзе өчен мәҗбүри боерыкны яисә күрсәтмәне үтәү йөзеннән эш итүче зат тарафыннан зыян китерү җинаять дип танылмый. Шундый зыянны китергән өчен җинаять җаваплылыгына законсыз боерык яисә күрсәтмә биргән зат тартыла.

2. Күрәләтә законсыз боерыкны яисә күрсәтмәне үтәү йөзеннән аңлы рәвештә җинаять кылган зат гомуми нигезләрдә җинаять җаваплылыгына тартыла. Күрәләтә законсыз боерыкны яисә күрсәтмәне үтәмәү җинаять җаваплылыгына китерми.

III кисәк. Җәза

9 бүлек. Җәза төшенчәсе һәм максатлары. Җәза төрләре

43 статья. Җәза төшенчәсе һәм максатлары

1. Суд карары буенча билгеләнә торган дәүләти мәҗбүр итү чарасы җәза дип танылa. Җәза җинаять кылуда гаепле дип танылган затка карата кулланыла һәм бу затны хокукларыннан һәм ирекләреннән мәхрүм итү яисә чикләү рәвешендә әлеге Кодекста беркетелә.

2. Җәза социаль гаделлекне торгызу максатларында, шулай ук хөкем ителгән затны төзәтү һәм аның яңа җинаятьләр кылуын кисәтү максатларында кулланыла.

44 статья. Җәза төрләре

Түбәндәге җәза төрләре була:

а) штраф;

б) аерым вазифаларны биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү;

в) махсус, хәрби яисә мактаулы исемнәрдән, классны чиннан һәм дәүләт бүләкләреннән мәхрүм итү;

г) мәҗбүри эшләр;

д) төзәтү эшләре;

е) хәрби хезмәт буенча чикләү;

ж) *үз көчен югалтты;*

з) ирекне чикләү;

и) кулга алу;

к) дисциплинар хәрби частьта тоту;

л) билгеле бер срокка иректән мәхрүм итү;

м) гомерлеккә иректән мәхрүм итү;

н) үлем җәзасы.

45 статья. Төп һәм өстәмә җәза төрләре

1. Мәҗбүри эшләр, төзәтү эшләре, хәрби хезмәт буенча чикләү, ирекне чикләү, кулга алу, дисциплинар хәрби частьта тоту, билгеле бер срокка иректән мәхрүм итү, гомерлеккә ирекtән мәхрүм итү, үлем җәзасы бары тик төп җәза төрләре буларак кына кулланыла.

2. Штраф һәм билгеле бер вазифаларны биләү яисә билгеле бер эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү төп, шулай ук өстәмә җәза төрләре буларак та кулланыла.

3. Махсус, хәрби яисә мактаулы исемнән, класслы чиннан һәм дәүләт бүләкләреннән мәхрүм итү бары тик өстәмә җәза төрләре буларак кына кулланыла.

46 статья. Штраф

1. Әлеге Кодекста каралган чикләрдә билгеләнә торган акчалата түләтү җәзасы штраф була.

2. Штраф ике мең биш йөз сумнан бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике атнадан биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки башка кереме күләмендә билгеләнә. Биш йөз мең сум күләмнән алып билгеләнгән яисә хөкем ителгән затның өч елдан артык чордагы хезмәт хакы яки башка кереме күләмендәге штраф бары тик әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяларда аерым каралган очракларда авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен генә билгеләнергә мөмкин.

3. Штраф күләме, кылган җинаятьнең авырлыгын һәм хөкем ителгән затның, аның гаиләсенең мөлкәти хәлен исәпкә алып, шулай ук хөкем ителгән затның хезмәт хакы яисә башка керем алу мөмкинлеген исәпкә алып, суд тарафыннан билгеләнә. Шул ук шартларны исәпкә алып, суд штрафны өч елга кадәр өлешләп түләүне билгеләргә мөмкин.

4. Өстәмә җәза чарасы буларак штраф бары тик әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяларда каралган очракларда гына билгеләнергә мөмкин.

5. Төп җәза чарасы буларак билгеләнгән штрафны түләүдән явыз ният белән читләшкән очракта, ул әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда каралган санкция чикләрендә алмаштырыла.

47 статья. Аерым вазифаларны биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү

1. Аерым вазифаларны биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү дәүләт хезмәтендә, җирле үзидарә органнарында вазифалар биләүне йә аерым һөнәри һәм башка эшчәнлек белән шөгыльләнүне тыюдан гыйбарәт.

2. Аерым вазифаларны биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү төп җәза төре буларак бер елдан биш елга кадәр һәм өстәмә җәза төре буларак алты айдан өч елга кадәр билгеләнә.

3. Аерым вазифаларны биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү өстәмә җәза төре буларак һәм әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда каралмаган очракларда, әгәр кылган җинаятьнең характерын һәм җәмгыяви куркынычлылык дәрәҗәсен һәм гаепленең шәхесен исәпкә алып, суд гаеплене аерым вазифа биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан файдалана алмый дип таныса, тиешле җинаять өчен җәза буларак билгеләнергә мөмкин.

4. Әлеге җәза төре мәҗбүри эшләргә яки төзәтү эшләренә, шулай ук шартлы рәвештә хөкем иткәндә, өстәмә җәза чарасы буларак билгеләнгән очракта, аның срогы судның хөкем карары закон көченә кергән мизгелдән исәпләнә. Аерым вазифалар биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү ирекне чикләүгә, кулга алуга, дисциплинар хәрби частьта тотуга, иректән мәхрүм итүгә өстәмә җәза чарасы буларак билгеләнгән очракта, ул күрсәтелгән төп җәза төрләрен үтәүнең барлык вакытына кагыла, әмма аның срогы шушы җәза чаралары үтәлгән вакыттан исәпләнә.

48 статья. Махсус, хәрби яисә мактаулы исемнәрдән, класслы чиннан һәм дәүләт бүләкләреннән мәхрүм итү

Авыр яисә аеруча авыр җинаять кылган өчен хөкем иткәндә, гаепленең шәхесен исәпкә алып, суд аны махсус, хәрби яисә мактаулы исемнәрдән, класслы чиннан һәм дәүләт бүләкләреннән мәхрүм итәргә мөмкин.

49 статья. Мәҗбүри эшләр

1. Мәҗбүри эшләр хөкем ителгән затның төп эшеннән яисә укуыннан азат вакытта түләүсез иҗтимагый файдалы эшләр башкаруыннан гыйбарәт. Мәҗбүри эшләрнең төре һәм шул эшләр башкарыла торган объектлар, җинаять-башкару инспекцияләре белән килештереп, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

2. Мәҗбүри эшләр алтмыш сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр билгеләнә һәм көнгә иң күбе дүрт сәгать башкарыла.

3. Хөкем ителгән зат мәҗбүри эшләрне башкарудан явыз ният белән читләшкән очракта, ул эшләр ирекне чикләү, кулга алу яисә иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәзалар белән алмаштырыла. Мондый чакта хөкем ителгән зат үтәгән мәҗ-

бүри эшләр, ирекне чикләү, кулга алу яисә иректән мәхрүм итү срогын билгеләгәндә, бер көн ирекне чикләү, кулга алу яки иректән мәхрүм итү сигез сәгать мәҗбүри эшкә тиң булудан чыгып исәпләнә.

4. Беренче төркем инвалидлар дип танылган затларга, йөкле хатыннарга, өч яшькә кадәрге балалары булган хатын-кызларга, чакыру буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләргә, шулай ук гади һәм сержант составында хәрби вазифаларда контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләргә, әгәр алар судның хөкем карары чыгарылган вакытка чакыру буенча хезмәт узуның законда билгеләнгән срогын үтмәгән булсалар, мәҗбүри эшләр билгеләнми.

50 статья. Төзәтү эшләре

1. Төзәтү эшләре төп эш урыны булмаган хөкем ителгән затка билгеләнә һәм, төзәтү эшләре рәвешендәге җәзаны үтәтүче орган белән килештереп, җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә торган урыннарда, әмма хөкем ителгән затның яшәү урыны районында башкарыла.

2. Төзәтү эшләре ике айдан ике елга кадәр срокка билгеләнә.

3. Хөкем ителгән затның төзәтү эшләре буенча хезмәт хакыннан суд карары белән билгеләнгән күләмдә, биш проценттан егерме процентка кадәр чикләрдә, дәүләт керемен тотымнар алына.

4. Төзәтү эшләренә хөкем ителгән зат шул җәзаны узудан явыз ният белән читләшкән очракта, суд үтәлеп бетмәгән җәзаны, бер көн ирекне чикләү бер көн төзәтү эшләренә, бер көн кулга алу ике көн төзәтү эшләренә яисә бер көн иректән мәхрүм итү өч көн төзәтү эшләренә тиң итеп санап, ирекне чикләү, кулга алу яисә иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәзалар белән алмаштырырга мөмкин.

5. Беренче төркем инвалидлар дип танылган затларга, йөкле хатыннарга, өч яшькә кадәрге балалары булган хатын-кызларга, чакыру буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләргә, шулай ук гади һәм сержант составында хәрби вазифаларда контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләргә, әгәр алар судның хөкем карары чыгарылган вакытка чакыру буенча хезмәт узуның законда билгеләнгән срогын үтмәгән булсалар, төзәтү эшләре билгеләнми.

51 статья. Хәрби хезмәт буенча чикләү

1. Хәрби хезмәт буенча чикләү контракт буенча хәрби хезмәт узучы хөкем ителгән хәрби хезмәткәрләргә хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр кылган өчен әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяларда каралган очракларда өч ай-

дан ике елга кадәр билгеләнә, шулай ук контракт буенча хәрби хезмәт узучы хөкем ителгән хәрби хезмәткәрләргә әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяларда каралган төзәтү эшләре урынына билгеләнә.

2. Хәрби хезмәт буенча чикләүгә хөкем ителгән затның акчалата кеременнән судның хөкем карары белән билгеләнгән, әмма егерме проценттан артыграк булмаган күләмдә дәүләт кеременә тотымнар алына. Хөкем ителгән зат әлеге җәзаны узганда хезмәт урынында, хәрби дәрәҗәдә күтәрелә алмый, ә җәза чоры чираттагы хәрби дәрәҗәне бирү өчен тиешле эшләү вакытына (выслуга лет) исәпләнми.

52 статья. *Үз көчен югалтты.*

53 статья. Ирекне чикләү

1. Судның хөкем карары чыгарылган вакытка 18 яше тулган хөкем ителгән затны җәмгыятьтән аермыйча гына аның артыннан күзәтүне гамәлгә ашыру шартларында махсус учреждениедә тоту ирекне чикләү дип таныла.

2. Ирекне чикләү җәзасы түбәндәгеләргә билгеләнә:

а) белә торып кылган җинаятьләр өчен хөкем ителгән һәм моңа кадәр хөкем ителүе булмаган затларга — бер елдан өч елга кадәр;

б) саксызлык аркасында кылган җинаятьләр өчен хөкем ителгән затларга — бер елдан биш елга кадәр.

3. Мәҗбүри эшләр яисә төзәтү эшләре ирекне чикләүгә алыштырылган очракта, ул бер елдан кимрәк срокка билгеләнергә мөмкин.

4. Ирекне чикләүгә хөкем ителгән зат җәза узудан явыз ният белән читләшкән очракта, судның хөкем карары белән билгеләнгән ирекне чикләү срогы иректән мәхрүм итү җәзасына алмаштырыла. Мондый чакта ирекне чикләү җәзасын узу вакыты иректән мәхрүм итү срогына исәпләнә, бу бер көн иректән мәхрүм итү бер көн ирекне чикләүгә тиң булудан чыгып исәпләнә.

5. Ирекне чикләү беренче яисә икенче төркем инвалидлар дип танылган затларга, йөкле хатыннарга, ундүрт яшькә кадәрге балалары булган хатын-кызларга, илле биш яше тулган хатын-кызларга, алтмыш яше тулган ирләргә, шулай ук чакыру буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләргә билгеләнми.

54 статья. Кулга алу

1. Хөкем ителгән затны җәмгыятьтән катгый изоляцияләү шартларында тоту кулга алу дип таныла, һәм ул бер айдан

алты айга кадәр билгеләнә. Мәҗбүри эшләрне яисә төзәтү эшләрен кулга алуга алыштырган очракта, ул бер айдан кимрәк срокка билгеләнергә мөмкин.

2. Кулга алу суд карары чыгарылган вакытка уналты яше тулмаган затларга, шулай ук йөкле хатыннарга һәм үндүрт яшькә кадәрге балалары булган хатын-кызларга билгеләнми.

3. Хәрби хезмәткәрләр кулга алуны гауптвахтада узалар.

55 статья. Дисциплинар хәрби частьта тоту

1. Дисциплинар хәрби частьта тоту чакыру буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләргә, шулай ук гади һәм сержант составында хәрби вазифаларда контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләргә, әгәр алар судның хөкем карары чыгарылган вакытка чакыру буенча хезмәт узуның законда билгеләнгән срогын узмаган булсалар, билгеләнә. Бу җәза хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр кылган өчен әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяларда каралган очракларда өч айдан ике елга кадәр билгеләнә, шулай ук җинаятьнең характеры һәм гаепленең шәхесе ике елдан артык булмаган срокка иректән мәхрүм итү җәзасын шул ук срокка дисциплинар хәрби частьта тотуга алыштыру мөмкинлеген таныклаган очракларда билгеләнә.

2. Иректән мәхрүм итү урынына дисциплинар хәрби частьта тотканда дисциплинар хәрби частьта тоту срогы бер көн иректән мәхрүм итү бер көн дисциплинар хәрби частьта тотуга тиң булу исәбеннән чыгып билгеләнә.

56 статья. Билгеле бер срокка иректән мәхрүм итү

1. Хөкем ителгән затны колониягә-сөргенгә җибәрү, тәрбияләү колониясенә, дәвалау-төзәтү учреждениесенә, гомуми, каты һәм махсус режимдагы төзәтү колониясенә йә төрмәгә урнаштыру юлы белән җәмгыятьтән изоляцияләү иректән мәхрүм итү дип таныла.

2. Иректән мәхрүм итү ике айдан егерме елга кадәр билгеләнә.

3. *Үз көчен югалтты.*

4. Җинаятьләр җыелмасы буенча җәзалар билгеләнгәндә, иректән мәхрүм итү срокларын өлешчә яисә тулысынча үтәгән очракта, иректән мәхрүм итүнең максималь срогы егерме биш елдан артыграк була алмый, ә хөкем карарлары җыелмасы буенча утыз елдан артыграк була алмый.

57 статья. Гомерлеккә иректән мәхрүм итү

1. Гомерлеккә иректән мәхрүм итү бары тик кеше гомеренә янаган аеруча авыр җинаятьләр кылган өчен, шулай ук

җәмгыятькә каршы аеруча авыр җинаять кылган өчен билгеләнергә мөмкин.

2. Гомерлеккә иректән мәхрүм итү хатын-кызларга, шулай ук унсигез яше тулмаган килеш җинаять кылган затларга һәм судның хөкем карары чыгарылган вакытка алтмыш биш яше тулган ирләргә билгеләнми.

58 статья. Иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән затларга төзәтү учреждениесе рәвешен билгеләү

1. Иректән мәхрүм итүне узу җәзасы түбәндәгеләргә билгеләнә:

а) саксызлык аркасында кылган җинаятьләр өчен хөкем ителгән затларга, шулай ук аңлы рәвештә авыр булмаган һәм уртача авырлыктагы җинаятьләр кылган өчен иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән, элек иректән мәхрүм итү җәзасы узмаган затларга — колония-сөргеннәрдә. Җинаять кылу шартларын һәм гаепленең шәхесен исәпкә алып, суд әлеге затларга, кабул ителгән карарның дәлилләрен күрсәтеп, гомуми режимдагы төзәтү колонияләрендә җәза узуны билгеләргә мөмкин;

б) элек иректән мәхрүм итү җәзасына хөкем ителүе булмаган, авыр җинаятьләр кылган өчен иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән затларга, шулай ук авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр кылган өчен иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән хатын-кызларга, шул исәптән теләсә нинди рецидив төре булганда — гомуми режимдагы төзәтү колонияләрендә;

в) элек иректән мәхрүм итү җәзасына хөкем ителүе булмаган, аеруча авыр җинаятьләр кылган өчен иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән ир-атларга, шулай ук җинаятьләр рецидивы яисә куркыныч җинаятьләр рецидивы булганда, әгәр хөкем ителгән зат элек иректән мәхрүм итү җәзасын узган булса, — каты режимдагы төзәтү колонияләрендә;

г) гомерлеккә иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән ир-атларга, шулай ук аеруча куркыныч җинаятьләр рецидивы булганда — махсус режимдагы төзәтү колонияләрендә.

2. Аеруча авыр җинаятьләр кылган өчен биш елдан артыграк срокка иректән мәхрүм ителүгә хөкем ителгән ир-атларга, шулай ук аеруча куркыныч җинаятьләр рецидивы булганда, җәза узу срогының бер өлешенә төрмәдә узу билгеләнергә мөмкин, мондый чакта суд хөкем ителгән затны гаепләү карары закон көченә кергәнче сак астында тоту вакытын төрмәдә җәза узу срогына кертеп исәпли.

3. Судның хөкем карары чыгарылган вакытка унсигез яше тулмаган килеш иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән затларга җәза узу төзәтү колонияләрендә билгеләнә.

4. Төзәтү учреждениесе төрен үзгәртү Россия Федерациясенең җинаять-башкару законнары нигезендә суд тарафыннан башкарыла.

59 статья. Үлем җәзасы

1. Катгый җәза чарасы буларак үлем җәзасы бары тик кеше гомеренә янаган аеруча зур җинаятьләр өчен генә билгеләнергә мөмкин.

2. Үлем җәзасы хатын-кызларга, шулай ук унсигез яше тулмаган килеш җинаять кылган затларга һәм судның хөкем карары чыгарылган вакытка алтмыш биш яшь тулган ир-атларга билгеләнми.

3. Үлем җәзасы ярлыкау тәртибендә гомерлеккә иректән мәхрүм итү яисә егерме биш елга иректән мәхрүм итү җәзасы белән алыштырылырга мөмкин.

10 бүлек. Җәза билгеләү

60 статья. Җәза билгеләүнең гомуми башлангычлары

1. Җинаять кылуда гаепле дип танылган затка, әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда каралган чикләрдә һәм әлеге Кодексның Махсус өлешендәге нигезләмәләрне исәпкә алып, гадел хөкем билгеләнә. Кылган җинаять өчен каралган җәзаларның иң каты төре җиңелрәк җәза төре җәза максатларына ирешүне тәэмин итә алмаган очракта гына билгеләнә.

2. Кылган җинаять өчен әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяларда каралганнан катырак җәза җинаятьләр җыелмасы буенча һәм әлеге Кодексның 69 һәм 70 статьялары нигезендә чыгарылган хөкем карарлары җыелмасы буенча билгеләнергә мөмкин. Кылган җинаять өчен әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда каралганнан җиңелрәк җәза билгеләү өчен нигезләр шушы Кодексның 64 статьясы белән билгеләнә.

3. Җәза билгеләгәндә җинаятьнең характеры һәм җәмгыяви куркынычлылык дәрәҗәсе, гаепленең шәхесе, шул исәптән җәзаны җиңеләйтә һәм авырайта торган шартлар, шулай ук билгеләнгән җәзаның хөкем ителгән затны төзәтүгә һәм аның гаиләсенең тормыш шартларына тәэсир итүе исәпкә алына.

61 статья. Җәзаны җиңеләйтә торган шартлар

1. Түбәндәгеләр җәзаны җиңеләйтә торган шартлар дип танына:

а) очраклы барлыкка килгән шартлар аркасында беренче мәртәбә авыр булмаган җинаять кылу;

б) гаепленең балигъ яшьтә булмавы;

в) йөклелек;

г) гаепленең кече яшьтәге балалары булу;

д) авыр тормыш шартлары аркасында йә кайгыртучанлык күрсәтү йөзеннән җинаять кылу;

е) физик яисә психик мәҗбүр итү нәтиҗәсендә йә матди, хезмәткә яисә башка төрле бәйлелек аркасында җинаять кылу;

ж) үз-үзеңне яклауның, җинаять кылган затны тоткарлауның, нигезле хәтәр гамәл кылуның иң чик зарурлыгының, боерык яисә күрсәтмә үтәүнең законлы шартларын бозганда җинаять кылу;

з) зыян күрүченең үз-үзен тотышында җинаять кылуга сәбәп булган законсызлык яисә әхлаксызлык;

и) гаебен танып килү, җинаятьне ачуга, җинаятьтә башка катнашучыларны фаш итүгә һәм җинаять нәтиҗәсендә алынган мөлкәтне эзләүгә актив ярдәм итү;

к) җинаять кылганнан соң ук зыян күрүчегә медицина ярдәме һәм башка ярдәм күрсәтү, җинаять нәтиҗәсендә китерелгән мөлкәти зарарны һәм әхлакый зыянны ихтыяри рәвештә түләү, зыян күрүчегә китерелгән зыянны бетерүгә юнәлдерелгән башка гамәлләр.

2. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралмаган шартлар да җәза билгеләгәндә аны җиңеләйтә торган шартлар буларак исәпкә алынырга мөмкин.

3. Әгәр әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статья белән җәзаны җиңеләйтү шарты җинаять билгесе буларак каралса, ул шарт үзе җәза билгеләгәндә кабат исәпкә алынмый.

62 статья. Җәзаны җиңеләйтә торган шартлар булганда җәза билгеләү

Әлеге Кодексның 61 статьясы беренче өлешенең «и» һәм «к» пунктларында каралган җәза җиңеләйтә торган шартлар булганда һәм аны авырайта торган шартлар булмаганда, җәза срогы яисә күләме әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда каралган аеруча каты җәза төренең максималь срогының дүрттән өч өлешеннән яисә күләменнән артмаска тиеш.

63 статья. Җәзаны авырайта торган шартлар

1. Түбәндәгеләр җәзаны авырайта торган шартлар дип таныла:

а) җинаятьләр рецидивы;

б) җинаять кылу аркасында авыр нәтиҗәләр барлыкка килү;

в) затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме, оешкан төркем яисә җинаять бергәлеге (җинаять оешмасы) составында җинаять кылу;

г) җинаять кылуда аеруча актив роль;

д) психикасы какшаган йә исерек хәлдәге затларны, шулай ук җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәгән затларны җинаять кылуга җәлеп итү;

е) милли, раса, дини нәфрәт яисә дошманлык аркасында, башка затларның законлы гамәлләренә үч итеп, шулай ук башка җинаятьне яшерү яисә аны җиңеләйтү максатында җинаять кылу;

ж) затка яисә аның якыннарына карата шушы затның хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруына яисә иҗтимагый бурычын башкаруына бәйле рәвештә җинаять кылу;

з) йөклелеген белә торып хатын-кызга карата, шулай ук яшь балага, яклаучысыз яисә ярдәмчесез булган башка затка йә гаеплегә бәйле мөнәсәбәттә торучы затка карата җинаять кылу;

и) зыян күрүчегә карата аеруча рәхимсезлек, садизм күрсәтеп, аны мәсхәрәләп, шулай ук аны газаплап җинаять кылу;

к) корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч матдәләр, шартлый торган җайланмалар яисә аларны имитацияләүче җайланмалар, махсус әзерләнгән техник чаралар, агулы һәм радиоактив матдәләр, дарулар һәм башка химик-фармакологик препаратлар кулланып, шулай ук физик яисә психик мәҗбүр итеп җинаять кылу;

л) гадәттән тыш хәл, табигый бәла-каза яисә башка җәмгыяви бәла-каза шартларында, шулай ук массакүләм тәртипсезлекләр вакытында җинаять кылу;

м) гаепләнүченең хезмәт хәленә бәйле рәвештә яисә килешү буенча үзенә белдерелгән ышанычтан файдаланып җинаять кылу;

н) форма киеменнән яисә хакимият вәкиле документларыннан файдаланып җинаять кылу.

2. Әгәр җәзаны авырайту шарты әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда җинаять билгесе буларак каралса, ул җәза билгеләгәндә кабат исәпкә алына алмый.

64 статья. Кылган җинаять өчен каралганнан җиңелрәк җәза билгеләү

1. Җинаять максатларына һәм сәбәпләренә, гаепләнүченең роленә, җинаять кылган вакытта яисә аннан соң аның үз-үзен тотышына бәйле махсус шартлар һәм җинаятьнең җәмгыяви куркынычлылык дәрәҗәсен шактый киметә торган башка шартлар булганда, шулай ук төркемле җинаятьтә катнашучы әлеге җинаятьне ачуда актив ярдәм иткәндә, әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда каралган иң түбәнге чигеннән дә җиңелрәк җәза билгеләнергә мөмкин яисә суд шу-

шы статьяда каралганнан җиңелрәк җәза төрен билгеләргә яисә мәҗбүри җәза чарасы буларак каралган өстәмә җәза төрен кулланмаска мөмкин.

2. Махсус шартлар дип җәзаны җиңеләйтә торган аерым шартлар да, шулай ук шундый шартлар бергәлеге дә танылырга мөмкин.

65 статья. Присяжный утырышчыларның мәрхәмәтлелек күрсәтү турында вердикты булганда җәза бирү

1. Присяжный утырышчылар тарафыннан җинаять кылуда гаепле, әмма мәрхәмәтлелек күрсәтүгә лаек дип танылган затка җәза бирү срогы яисә күләме кылган җинаять өчен каралган иң каты җәза төренең максималь срогының яисә күләменең өчтән икесеннән артыграк була алмый. Әгәр әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда үлем җәзасы яисә гомерлеккә иректән мәхрүм итү каралган булса, бу җәза төрләре кулланылмый, ә җәза әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда каралган санкция чикләрендә билгеләнә.

2. *Үз көчен югалтты.*

3. Җинаятьләр җыелмасы буенча яисә хөкем карарлары җыелмасы буенча җәза билгеләгәндә, җәза төре, срогы яисә күләме әлеге Кодексның 69 һәм 70 статьяларында каралган кагыйдәләр буенча билгеләнә.

4. Присяжный утырышчылар вердикты белән җинаять кылуда гаепле, әмма мәрхәмәтлелек күрсәтүгә лаек дип танылган затка җәза бирүне билгеләгәндә, җәзаны авырайта торган шартлар исәпкә алынмый.

66 статья. Тәмамланмаган җинаять өчен җәза билгеләү

1. Тәмамланмаган җинаять өчен җәза билгеләгәндә, аны ахыргача җиткерергә комачаулаган шартлар исәпкә алына.

2. Җинаятькә әзерләнгән өчен җәза срогы яисә күләме әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда тәмамланган җинаять өчен каралган иң каты җәза төренең максималь срогының яисә күләменең яртысыннан артыграк була алмый.

3. Җинаять кылуга омтылган өчен җәза срогы яисә күләме тәмамланган җинаять өчен әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда каралган иң каты җәза төренең максималь срогының яисә күләменең дүрттән өченнән артыграк була алмый.

4. Җинаятькә әзерләнгән һәм җинаять кылуга омтылган өчен үлем җәзасы һәм гомерлеккә иректән мәхрүм итү җәзасы билгеләнми.

67 статья. Катнашып кылган җинаять өчен җәза билгеләү

1. Катнашып кылган җинаять өчен җәза билгеләгәндә, җинаятьнең характеры һәм затның фактта аны кылуда катнашу дәрәҗәсе, бу катнашуның җинаять максатына ирешүдәге әһәмияте, китерелгән яисә китерелергә мөмкин булган зыянның характерына һәм аның күләменә тәэсире исәпкә алына.

2. Катнашучыларның берәрсенең шәхесенә кагылышлы җәза җиңеләйтә яисә авырайта торган шартлар бары тик әлеге катнашучыга җәза билгеләгәндә генә исәпкә алына.

68 статья. Җинаятьләр рецидивы булганда җәза билгеләү

1. Җинаятьләр рецидивы, куркыныч җинаятьләр рецидивы яисә аеруча куркыныч җинаятьләр рецидивы очрагында җәза билгеләгәндә, элек кылган җинаятьләрнең характеры һәм җәмгыяви куркынычлылык дәрәҗәсе, моңа кадәрге җәзаның төзәтү тәэсирен җитәрлек булмауга китергән шартлар, шулай ук яңа кылган җинаятьләрнең характеры һәм җәмгыяви куркынычлылык дәрәҗәсе исәпкә алына.

2. Теләсә нинди төрдәге җинаятьләр рецидивы очрагында җәза срогы кылган җинаять өчен каралган иң каты җәза төренең максималь срогының өчтән береннән дә кимрәк була алмый, әмма ул әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьядагы санкция чикләрендә булырга тиеш.

3. Теләсә нинди җинаятьләр рецидивы булганда, әгәр суд тарафыннан әлеге Кодексның 61 статьясында каралган җиңеләйтә торган шартлар билгеләнгән булса, җәза срогы кылган җинаять өчен каралган иң каты җәза төренең максималь срогының өчтән бер өлешеннән кимрәк билгеләнергә мөмкин, әмма ул әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьядагы санкция чикләрендә булырга тиеш, ә әлеге Кодексның 64 статьясында каралган махсус шартлар булганда, әлеге җинаять өчен каралганнан җиңелрәк җәза билгеләнергә мөмкин.

69 статья. Җинаятьләр җыелмасы буенча җәза билгеләү

1. Җинаятьләр җыелмасы булганда, җәза һәр кылган җинаять өчен аерым билгеләнә.

2. Әгәр җыелма җинаятьләрнең барысы да авыр булмаган һәм уртача авырлыктагы җинаятьләр булса, соңгы җәза җиңелрәк җәзаны катырак җәзага алмаштыру юлы белән йә билгеләнгән җәзаларны өлешчә яисә тулысынча берләштерү юлы белән билгеләнә. Мондый чакта соңгы җәза кылган җинаятьләрдән иң авыр җинаять өчен каралган җәзаның максималь срогының яисә күләменең яртысыннан артыграк була алмый.

3. Әгәр җыелма җинаятьләрнең берсе генә авыр яисә аеру-

ча авыр җинаять булса да, соңгы җәза җәзаларны өлешчә яисә тулысынча берләштерү юлы белән билгеләнә. Мондый чакта иректән мәхрүм итү рәвешендәге соңгы җәза кылган җинаятьләр арасыннан иң авыр җинаять өчен каралган иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаның максималь срогының яртысыннан артыграк була алмый.

4. Җинаятьләр җыелмасы булганда, төп җәза төрләренә өстәмә җәза төрләре кушылырга мөмкин. Җәзаларны өлешчә яисә тулысынча берләштергәндә, соңгы өстәмә җәза әлеге Кодексның Гомуми өлешендә шушы төр җәза өчен каралган максималь сроктан яисә күләмнән артыграк була алмый.

5. Әгәр эш буенча суд тарафыннан хөкем карары чыгарылганнан соң, хөкем ителгән затның беренче эш буенча суд карары чыгарылганга кадәр кылган башка җинаятьтә гаепле булуы билгеләнсә, җәза шул ук кагыйдәләр буенча билгеләнә. Бу очракта соңгы җәзага беренче суд карары буенча узган җәза срогы кертеп исәпләнә.

70 статья. Хөкем карарлары җыелмасы буенча җәза билгеләү

1. Хөкем карарлары җыелмасы буенча җәза билгеләгәндә, соңгы суд карары буенча билгеләнгән җәзага алдагы суд карары буенча узып бетмәгән җәза өлешчә яисә тулысынча өстәлә.

2. Хөкем карарлары җыелмасы буенча соңгы җәза иректән мәхрүм итүгә караганда җиңелрәк җәза булган очракта, соңгы җәза әлеге Кодексның Гомуми өлешендә шушы төр җәза өчен каралган максималь сроктан яисә күләмнән артыграк була алмый.

3. Хөкем карарлары җыелмасы буенча бирелә торган иректән мәхрүм итү рәвешендәге соңгы җәза утыз елдан артыграк була алмый.

4. Хөкем карарлары җыелмасы буенча соңгы җәза яңа кылган җинаять өчен билгеләнгән җәзадан, шулай ук моңа кадәрге суд карары буенча узып бетмәгән җәза өлешеннән күбрәк булырга тиеш.

5. Хөкем карарлары җыелмасы буенча җәза билгеләгәндә, өстәмә җәза төрләрен кушу әлеге Кодексның 69 статьясы дүртенче өлешендә каралган кагыйдәләр буенча башкарыла.

71 статья. Җәзаларны берләштергәндә җәза срокларын билгеләү тәртибе

1. Җинаятьләр җыелмасы һәм хөкем карарлары җыелмасы буенча җәзаларны өлешчә яисә тулысынча берләштергәндә, түбәндәгеләр бер көн иректән мәхрүм итүгә тиң була:

а) бер көнгә кулга алу яисә дисциплинар хәрби частьта тоту;
б) ике көн ирекне чикләү;
в) өч көн төзәтү эшләре яисә хәрби хезмәт буенча чикләү;
г) сигез сәгать мәҗбүри эшләр.

2. Штраф йә аерым хезмәт вазифаларын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, махсус, хәрби яисә мактаулы исемнәрдән, классы чиннан һәм дәүләт бүләкләреннән мәхрүм итү аларны ирекне чикләү, кулга алу, дисциплинар хәрби частьта тоту, иректән мәхрүм итү белән берләштергәндә мөстәкыйль башкарыла.

72 статья. Җәза срокларын исәпләү һәм җәзаны исәпкә кертү

1. Аерым хезмәт вазифаларын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, төзәтү эшләре, хәрби хезмәттә чикләү, ирекне чикләү, кулга алу, дисциплинар хәрби частьта тоту, иректән мәхрүм итү сроклары — айлар һәм еллар белән, ә мәҗбүри эшләр сәгатьләр белән исәпләнә.

2. Җәзаны алыштырганда яисә әлеге статьяның беренче өлешендә каралган җәзаларны берләштергәндә, шулай ук җәзаны исәпкә керткәндә, җәза сроклары көннәр белән исәпләнергә мөмкин.

3. Судта караганчыга кадәр затны сак астында тоту вакыты бер көн бер көн итеп саналып — иректән мәхрүм итү, дисциплинар хәрби частьта тоту һәм кулга алу срокларына, бер көн ике көн итеп саналып — ирекне чикләү срогына, бер көн өч көн итеп саналып — төзәтү эшләре һәм хәрби хезмәт буенча чикләү срокларына, ә бер көн сак астында тоту сигез сәгать мәҗбүри эш итеп саналып, мәҗбүри эшләр срогына исәпләнә.

4. Судның хөкем карары закон көченә кергәнче затны сак астында тоту вакыты һәм Россия Федерациясе чикләреннән тыш кылган җинаять өчен судның хөкем карары белән билгеләнгән иректән мәхрүм итү җәзасын узу вакыты әлеге Кодексның 13 статьясы нигезендә затны тапшырган очракта бер көн бер көнгә исәпләнеп санала.

5. Судта караганчыга кадәр сак астында тотылучы хөкем ителгән затка төп җәза буларак штраф түләүне, билгеле бер хезмәт вазифасын биләү яисә билгеле бер эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү җәзасын билгеләгәндә, суд, сак астында тоту срогын исәпкә алып, билгеләнгән җәзаны җиңеләйтә яисә ул затны әлеге җәзаны узудан тулысынча азат итә.

73 статья. Шартлы хөкем итү

1. Төзәтү эшләре, хәрби хезмәт буенча чикләү, ирекне чикләү, дисциплинар хәрби частьта тоту яисә сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү җәзалары билгеләп, суд хөкем ителгән зат реаль рәвештә җәза узмыйча төзәлергә мөмкин дигән нәтиҗәгә килсә, ул билгеләнгән җәзаны шартлы җәза дип санарга дигән карар кабул итә.

2. Шартлы хөкем итү билгеләнгәндә, суд кылган җинаятьнең характерын һәм җәмгыяви куркынычлылык дәрәҗәсен, гаепленең шәхесен, шул исәптән җиңеләйтә һәм авырайта торган шартларны исәпкә ала.

3. Шартлы хөкем итү билгеләнгәндә, суд сынау срогын билгели, шартлы хөкем ителгән зат шушы срок дәвамында үз-үзен тотышы белән үзенең төзәлүен расларга тиеш. Бер елга кадәр иректән мәхрүм итү яисә җиңелрәк җәза төре билгеләнгән очракта, сынау срогы алты айдан да азрак һәм өч елдан да күбрәк булмаска тиеш, ә бер елдан артыгракка иректән мәхрүм итү җәзасы билгеләнгән очракта, алты айдан да азрак һәм биш елдан да күбрәк булмаска тиеш.

4. Шартлы хөкем иткәндә шулай ук өстәмә җәза төрләре дә билгеләнергә мөмкин.

5. Шартлы хөкем итүне билгеләп, суд шартлы хөкем ителгән затка билгеле бер вазифаларны үтәүне йөкләргә мөмкин: хөкем ителгән затны төзәтүне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган дәүләт органына хәбәр итмичә, даими яшәү урынын, эш, уку урыннарын алмаштырмаска, аерым урыннарга йөрмәскә, алкоголизмнан, наркоманиядән, токсикоманиядән яисә венерик авырулардан дәвалану курсы узарга, гаиләсенә матди ярдәм күрсәтергә. Суд шартлы хөкем ителгән затка төзәлергә ярдәм итәрлек башка вазифаларны үтәүне дә йөкләргә мөмкин.

6. Шартлы хөкем ителгән затның үз-үзен тотышын тикшереп торуны шуңа вәкаләтле махсуслаштырылган дәүләт органы гамәлгә ашыра, ә хәрби хезмәткәрләргә карата — хәрби частьларның һәм учреждениеләрнең командованиесе.

7. Сынау чорында суд шартлы хөкем ителгән зат өчен элек билгеләнгән вазифаларны хөкем ителгән затның үз-үзен тотышын тикшереп торучы орган күрсәтмәсе буенча тулысынча яисә өлешчә юкка чыгарырга йә өстәргә мөмкин.

74 статья. Шартлы хөкем итүне юкка чыгару яисә сынау срогын озайту

1. Әгәр шартлы хөкем ителгән зат сынау срогы узганчы үз-үзен тотышы белән үзенең төзәлүен расласа, суд шартлы хөкем ителгән затны тикшереп торучы орган күрсәтмәсе буенча

шартлы хөкем итүне юкка чыгару һәм хөкем ителгән затның хөкем ителүен бетерү турында карар чыгарырга мөмкин. Шартлы хөкем итү мондый чакта билгеләнгән сынау срогының кимендә яртысын узгач юкка чыгарылырга мөмкин.

2. Әгәр шартлы хөкем ителгән зат суд тарафыннан үзенә йөкләнгән вазифаларны үтәүдән читләшсә яисә җәмәгать тәртибен административ җәза билгеләнерлек итеп бозса, суд әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән орган күрсәтмәсе буенча сынау срогын озайтырга мөмкин, әмма ул бер елдан артыграк була алмый.

3. Шартлы хөкем ителгән зат суд тарафыннан үзенә йөкләнгән вазифаларны сынау срогы дәвамында даими рәвештә яисә явыз ният белән үтәмәгән очракта, суд әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән орган күрсәтмәсе буенча шартлы хөкем итүне юкка чыгару турында һәм суд карары белән билгеләнгән җәзаны үтәтү турында карар чыгарырга мөмкин.

4. Шартлы хөкем ителгән зат сынау срогы дәвамында саксызлык аркасында җинаять кылган йә аңлы рәвештә авыр булмаган җинаять кылган очракта, шартлы хөкем итүне юкка чыгару турындагы яисә аны саклап калу турындагы мәсьәлә суд тарафыннан хәл ителә.

5. Шартлы хөкем ителгән зат сынау срогы дәвамында аңлы рәвештә уртача авырлыкта җинаять, аңлы рәвештә авыр яисә аеруча авыр җинаять кылган очракта, суд шартлы хөкем итүне юкка чыгара һәм аңа әлеге Кодексның 70 статьясында каралган кагыйдәләр буенча җәза билгели. Әлеге статьяның дүртенче өлешендә каралган очракларда җәза шул ук кагыйдәләр буенча билгеләнә.

IV кисәк. Җинаять җаваплылыгыннан һәм җәзадан азат итү

11 бүлек. Җинаять җаваплылыгыннан азат итү

75 статья. Эшлекле тәүбә итүгә бәйле рәвештә җинаять җаваплылыгыннан азат итү

1. Беренче мәртәбә авыр булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаять кылган зат аны кылганнан соң ихтыяри рәвештә үзенең гаебен танып килсә, җинаятьне ачуга ярдәм итсә, китерелгән зыянны кире кайтаруга булышса яисә җинаять кылу нәтиҗәсендә китерелгән зарарны башкача бетерсә һәм эшлекле тәүбә итү нәтиҗәсендә җәмгыяви куркыныч булудан туктаса, ул җинаять җаваплылыгыннан азат ителергә мөмкин.

2. Башка категориядә җинаять кылган зат, әлеге статьяның беренче өлешендә каралган шартлар булганда, әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяларда аерым каралган очракларда гына җинаять җаваплылыгыннан азат ителергә мөмкин.

76 статья. Зыян күрүче белән килешүгә бәйле рәвештә җинаять җаваплылыгыннан азат итү

Беренче мәртәбә авыр булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаять кылган зат, зыян күрүче белән килешсә һәм зыян күрүчегә китергән зарарын бетерсә, җинаять җаваплылыгыннан азат ителергә мөмкин.

77 статья. *Үз көчен югалтты.*

78 статья. Җавапка тарту сроклары узуга бәйле рәвештә җинаять җаваплылыгыннан азат итү

1. Җинаять кылганнан соң түбәндәге сроклар узса, зат җинаять җаваплылыгыннан азат ителә:

а) авыр булмаган җинаять кылганнан соң ике ел узгач;

б) уртача авырлыкта җинаять кылганнан соң алты ел узгач;

в) авыр җинаять кылганнан соң ун ел узгач;

г) аеруча авыр җинаять кылганнан соң унбиш ел узгач.

2. Җавапка тарту сроклары җинаять кылган көннән башлап хөкем карары закон көченә кергән мизгелгә кадәр исәпләнә. Зат яңа җинаять кылган очракта, һәр җинаять буенча җавапка тарту сроклары мөстәкыйль исәпләнә.

3. Әгәр җинаять кылган зат тикшерүдән яисә судтан читләшсә, җавапка тарту срокларының узуы туктатып торыла. Бу очракта җавапка тарту срокларының дәвамы әлеге затны тоткарлау яисә аның үз гаебен танып килү мизгеленнән яңадан башлана.

4. Үлем җәзасы яисә гомерлеккә irектән мәхрүм итү җәзасы билгеләнә торган җинаять кылган затка карата җавапка тарту срокларын куллану турындагы мәсьәлә суд тарафыннан хәл ителә. Әгәр суд җавапка тарту срокларының узуына бәйле рәвештә әлеге затны җинаять җаваплылыгыннан азат итү мөмкин түгел дип тапса, үлем җәзасы һәм гомерлеккә иректән мәхрүм итү җәзасы кулланылмый.

5. Кешелек тынычлыгына һәм иминлегенә каршы әлеге Кодексның 353, 356, 357 һәм 358 статьяларында каралган җинаятьләрне кылган затларга карата җавапка тарту сроклары кулланылмый.

12 бүлек. Җәзадан азат итү

79 статья. Җәза узудан шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итү

1. Дисциплинар хәрби частьта тоту җәзасын яисә иректән мәхрүм итү җәзасын узучы зат, әгәр суд тарафыннан ул төзәлү өчен суд билгеләгән җәзаны тулысынча узуга мохтаҗ түгел дип танылса, шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителергә тиеш. Мондый чакта зат тулысынча яисә өлешчә өстәмә җәза төрен узудан азат ителергә мөмкин.

2. Шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итүне кулланып, суд хөкем ителгән затка суд тарафыннан әлеге Кодексның 73 статьясы бишенче өлешендә каралган вазифаларны йөкләргә мөмкин, ул аларны узып бетмәгән җәза чорында үтәргә тиеш.

3. Шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итү бары тик хөкем ителгән зат түбәндәге җәза срокларын фактта узганнан соң гына кулланылырга мөмкин:

а) авыр булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаять өчен билгеләнгән җәза срогының кимендә өчтән берен;

б) авыр җинаять өчен билгеләнгән җәза срогының кимендә яртысын;

в) әгәр шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итү әлеге статьяның җиденче өлешендә каралган нигезләр буенча юкка чыгарылган булса, аеруча авыр җинаять өчен билгеләнгән җәза срогының кимендә өчтән икесен, шулай ук элек шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителгән затка карата билгеләнгән җәза срогының өчтән икесен.

4. Хөкем ителгән затның иректән мәхрүм итү җәзасы фактта узган срогы алты айдан да ким булмаска тиеш.

5. Гомерлеккә иректән мәхрүм итү җәзасын узучы зат суд тарафыннан ул әлеге җәзаны алга таба узуга мохтаҗ түгел һәм иректән мәхрүм итү җәзасының кимендә егерме биш елын фактта узган дип танылса, ул шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителергә мөмкин. Иректән гомерлеккә мәхрүм итү җәзасын алга таба узудан шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итү бары тик хөкем ителгән затның узган өч ел дәвамында җәза узуның билгеләнгән тәртибен явыз ният белән бозуы булмаганда гына кулланыла. Гомерлеккә иректән мәхрүм итү җәзасын узу чорында яңа авыр яисә аеруча авыр җинаять кылган зат шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителми.

6. Шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителгән затның үз-үзен тотышын тикшереп торуны — шуңа вәкаләтле махсуслаштырылган дәүләт органы, ә хәрбиләргә карата хәрби частьларның һәм учреждениеләрнең командованиесе гамәлгә ашыра.

7. Әгәр җәзаның узып бетмичә калган өлешендә:

а) хөкем ителгән зат җәмәгать тәртибен бозса һәм аның өчен административ җәза билгеләнсә яисә ул шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителгәндә суд тарафыннан йөкләнгән вазифаларны үтәүдән явыз ният белән читләшсә, суд әлеге статьяның алтынчы өлешендә күрсәтелгән органнарның тәкъдиме буенча шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итүне юкка чыгару һәм узмыйча калган җәзаны үтәү турында карар кабул итәргә мөмкин;

б) хөкем ителгән зат саксызлык аркасында җинаять кылса, шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итүне юкка чыгару турындагы йә аны саклап калу турындагы мәсьәлә суд тарафыннан хәл ителә;

в) хөкем ителгән зат аңлы рәвештә җинаять кылса, суд аңа әлеге Кодексның 70 статьясында каралган кагыйдәләр буенча җәза билгели. Әгәр суд шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итүне юкка чыгарса, саксызлык аркасында җинаять кылган очракта җәза шул ук кагыйдәләр буенча билгеләнә.

80 статья. Узып бетмәгән җәза өлешен җиңелрәк җәза төренә алмаштыру

1. Ирекне чикләү, дисциплинар хәрби хезмәттә тоту яисә иректән мәхрүм итү җәзасын узучы затка суд, аның җәза узу чорында үз-үзен тотышын исәпкә алып, узып бетмичә калган җәза өлешен җиңелрәк җәза төренә алмаштырырга мөмкин. Мондый чакта зат өстәмә җәза төрен узудан тулысынча яисә өлешчә азат ителергә мөмкин.

2. Хөкем ителүче түбәндәге җинаятьләрне кылган өчен иректән мәхрүм итү җәзасының түбәндәге срокларын фактта узганнан соң, узып бетмәгән җәза өлеше җиңелрәк җәза төренә алмаштырылырга мөмкин:

авыр булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаять кылган өчен — җәза срогының кимендә өчтән берен;

авыр җинаять кылган өчен — җәза срогының кимендә яртысын;

аеруча авыр җинаять кылган өчен — җәза срогының кимендә өчтән икесен.

3. Узып бетмәгән җәза өлешен алмаштырганда, суд әлеге Кодексның 44 статьясында күрсәтелгән җәза төрләре нигезендә, әлеге Кодекста һәр җәза төре өчен каралган чикләрдә теләсә нинди җиңелрәк җәза төрен сайларга мөмкин.

80.1 статья. Шартлар үзгәрү аркасында җәзадан азат итү

Беренче мәртәбә авыр булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаять кылган зат, әгәр шартлар үзгәрү аркасында бу

затның яисә ул кылган җинаятьнең җәмгыяви куркыныч булуы тукталган дип билгеләнсә, җәзадан суд тарафыннан азат ителә.

81 статья. Чирләү аркасында җәзадан азат итү

1. Җинаять кылганнан соң психикасы үз гамәлләренең (гамәл кылмауларының) фактик характерын һәм җәмгыяви куркынычлылыгын аңлау йә аларга җитәкчелек итү мөмкинлегеннән мәхрүм итәрлек итеп какшаган зат җәзадан азат ителә, ә җәза узучы зат аны алга таба узудан азат ителә. Мондый затларга суд медицина характерындагы мәҗбүри чаралар билгеләргә мөмкин.

2. Җинаять кылганнан соң җәза узуга тоткарлый торган башка төрле авыр чир белән авырган зат җәза узудан суд тарафыннан азат ителергә мөмкин.

3. Кулга алынган йә дисциплинар хәрби хезмәттә җәза узучы хәрби хезмәткәрләр аларны хәрби хезмәткә яраксыз итә торган чир белән авырган очракта гына җәзаны алга таба узудан азат ителәләр. Узып бетмәгән җәза җиңелрәк җәза төренә алмаштырылырга мөмкин.

4. Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә күрсәтелгән затлар сәламәтләнгән очракта, әгәр әлеге Кодексның 78 һәм 83 статьяларында каралган җавапка тарту сроклары узмаган булса, җинаять җаваплылыгына һәм җәзага тартылырга мөмкин.

82 статья. Йөкле хатыннарга һәм кечкенә балалары булган хатын-кызларга җәза узуны кичектерү

1. Хөкем ителгән йөкле хатыннарга һәм ундүрт яшькә кадәрге балалары булган хатын-кызларга, шәхескә каршы авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен биш елдан артыграк срокка иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгәннәрдән тыш, суд җәзаны реаль рәвештә узуны баласы ундүрт яшькә җиткәнче кичектерергә мөмкин.

2. Әгәр әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән хөкем ителгән хатын-кыз баласыннан баш тартса яисә үзенә карата җәза узу кичектерелгән хөкем ителгән хатын-кызның үз-үзен тотышын тикшереп торучы орган тарафыннан игълан ителгән кисәтүдән соң да баласын тәрбияләүдән читләшүен дәвам итсә, суд шушы орган күрсәтмәсе буенча җәза узуны кичектерүне юкка чыгарырга һәм хөкем ителгән затны судның хөкем карары нигезендә билгеләнгән урынга җәза узу өчен җибәрергә мөмкин.

3. Баласына ундүрт яшь тулганнан соң, суд хөкем ителгән хатын-кызны җәза узудан яисә җәзаның калган өлешен узу-

дан азат итә йә җәзаның калган өлешен җиңелрәк җәза төренә алмаштыра.

4. Әгәр хөкем ителгән хатын-кыз җәза узуны кичектерү чорында яңа җинаять кылса, суд аңа җәзаны әлеге Кодексның 70 статьясында каралган кагыйдәләр буенча билгели.

83 статья. Судның хөкем карарының җавапка тарту срогы чыгуга бәйле рәвештә җәза узудан азат итү

1. Җинаять кылган өчен хөкем ителгән зат, әгәр судның хөкем карары закон көченә кергән көненнән түбәндәге срокларда үтәлмәгән булса, җәза узудан азат ителә:

а) авыр булмаган җинаять өчен хөкем ителгәндә — ике ел;

б) уртача авырлыктагы җинаять өчен хөкем ителгәндә — алты ел;

в) авыр җинаять өчен хөкем ителгәндә — ун ел;

г) аеруча авыр җинаять өчен хөкем ителгәндә — унбиш ел.

2. Әгәр хөкем ителгән зат җәза узудан читләшсә, җавапка тарту срокларының узуы туктатып торыла. Мондый чакта җавапка тарту срокларының дәвамлылыгы хөкем ителгән затны тоткарлаган яисә ул гаебен танып килгән вакыттан яңадан башлана. Хөкем ителгән зат җәза узудан читләшкән вакытка җавапка тартуның узган сроклары исәпкә кертелә.

3. Үлем җәзасына яисә гомерлеккә иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән затка карата җавапка тарту срокларының чыгуын куллану турындагы мәсьәлә суд тарафыннан хәл ителә. Әгәр суд җавапка тарту срокларының чыгуын куллану мөмкин түгел дип санаса, бу җәза төрләре билгеле бер срокка иректән мәхрүм итүгә алмаштырыла.

4. Кешелек тынычлыгына һәм иминлегенә каршы әлеге Кодексның 353, 356, 357 һәм 358 статьяларында каралган җинаятьләр кылган өчен хөкем ителгән затларга җавапка тарту срокларының чыгуы кулланылмый.

13 бүлек. Амнистия. Ярлыкау. Хөкем ителү

84 статья. Амнистия

1. Амнистия индивидуаль билгеле булмаган затлар даирәсенә карата Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы тарафыннан игълан ителә.

2. Җинаять кылган затлар амнистия турындагы акт белән җинаять җаваплылыгыннан азат ителергә мөмкин. Җинаятьләр кылган өчен хөкем ителгән затлар җәзадан азат ителергә мөмкин, йә аларга билгеләнгән җәза кыскартылырга яисә җиңелрәк җәза төренә алмаштырылырга мөмкин, йә мондый зат-

лар өстәмә җәза төреннән азат ителергә мөмкин. Җәза узган затларның хөкем ителгәнлеге амнистия турындагы акт белән юкка чыгарылырга мөмкин.

85 статья. Ярлыкау

1. Ярлыкау индивидуаль билгеле бер затка карата Россия Федерациясе Президенты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Җинаять өчен хөкем ителгән зат ярлыкау акты белән җәза узуны алга таба дәвам итүдән азат ителергә мөмкин йә аңа билгеләнгән җәза кыскартылырга яисә җиңелрәк җәза төренә алмаштырылырга мөмкин. Җәза узган затның хөкем ителгәнлеге ярлыкау акты белән юкка чыгарылырга мөмкин.

86 статья. Хөкем ителү

1. Җинаять кылган өчен хөкем ителгән зат судның хөкем карары закон көченә кергән көннән башлап хөкем ителгәнлек юкка чыгарылган яисә кире алынган мизгелгә кадәр хөкем ителгән дип санала. Әлеге Кодекс нигезендә хөкем ителгәнлек җинаятьләр рецидивы булганда һәм җәза билгеләгәндә исәпкә алына.

2. Җәзадан азат ителгән зат хөкем ителмәгән дип санала.

3. Хөкем ителгәнлек түбәндәге очракларда юкка чыгарыла:

а) шартлы рәвештә хөкем ителгән затларга карата – сынау срогы узгач;

б) иректән мәхрүм итүгә караганда җиңелрәк җәза төрләренә хөкем ителгән затларга карата — җәза узып яисә үтәп кайтканнан соң бер ел узгач;

в) авыр булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаятьләр өчен иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән затларга карата — җәза узып кайтканнан соң өч ел узгач;

г) авыр җинаятьләр өчен иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән затларга карата — җәза узып кайтканнан соң алты ел узгач;

д) аеруча авыр җинаятьләр кылган өчен хөкем ителгән затларга карата — җәза узып кайтканнан соң сигез ел узгач.

4. Әгәр хөкем ителгән зат законда билгеләнгән тәртиптә җәза узудан вакытыннан алда азат ителсә яисә узып бетмәгән җәза өлеше җиңелрәк җәза төренә алмаштырылган булса, хөкем ителгәнлекне юкка чыгару срогы төп һәм өстәмә җәза төрләрен узудан азат итү мизгеленнән фактта узган җәза срогын кертеп исәпләнә.

5. Әгәр хөкем ителгән зат җәза узганнан соң үзен тәртипле тотса, суд хөкем ителгәнлекне юкка чыгару срогы узганга кадәр аның үтенечнамәсе буенча хөкем ителгәнлекне кире алырга мөмкин.

6. Хөкем ителгәнлекне юкка чыгару яисә кире алу хөкем ителгәнлеккә бәйле барлык хокукый нәтиҗәләрне юкка чыгара.

V кисәк. Балигъ булмаган затларның җинаять җаваплылыгы

14 бүлек. Балигъ булмаган затларның җинаять җаваплылыгы һәм аларга җәза үзенчәлекләре

87 статья. Балигъ булмаган затларның җинаять җаваплылыгы

1. Җинаять кылган вакытка ундүрт яше тулган, әмма унсигез яше тулмаган затлар балигъ булмаган затлар дип таныла.

2. Җинаятьләр кылган балигъ булмаган затларга тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чаралар кулланылырга мөмкин йә аларга җәза билгеләнергә мөмкин, ә суд тарафыннан җәзадан азат ителгәндә шулай ук мәгариф идарәсе органының ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениесенә урнаштырылырга мөмкин.

88 статья. Балигъ булмаган затларга билгеләнүче җәза төрләре

1. Балигъ булмаган затларга билгеләнә торган җәза төрләре түбәндәгеләр була:

а) штраф;

б) аерым бер эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү;

в) мәҗбүри эшләр;

г) төзәтү эшләре;

д) кулга алу;

е) билгеле бер срокка иректән мәхрүм итү.

2. Штраф балигъ булмаган хөкем ителгән затның мөстәкыйль хезмәт хакы яисә түләү алынырлык мөлкәте булганда, шулай ук алар булмаганда да билгеләнә. Балигъ булмаган хөкем ителгән затка билгеләнгән штраф суд карары буенча аның ата-анасыннан яисә башка законлы вәкилләреннән аларның ризалыгы белән алынырга мөмкин. Штраф бер мең сумнан илле мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике атнадан алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки башка кереме күләмендә билгеләнә.

3. Мәҗбүри эшләр кырык сәгатьтән йөз алтмыш сәгатькә кадәр билгеләнә, алар балигъ булмаган затлар өчен яраклы эшләр башкарудан гыйбарәт һәм укудан яисә төп эштән азат вакытта башкарыла. Унбиш яшькә кадәрге затлар тарафыннан әлеге җәза төрен үтәүнең дәвамлылыгы — көнгә ике сәгатьтән, ә унбиш яшьтән уналты яшькә кадәрге затлар тарафыннан көнгә өч сәгатьтән артмаска тиеш.

4. Төзәтү эшләре балигъ булмаган яшьтәге хөкем ителгән затларга бер елга кадәр билгеләнә.

5. Кулга алу балигъ булмаган яшьтәге, судның хөкем карары чыгарылган мизгелгә уналты яше тулган хөкем ителгән затларга бер айдан дүрт айга кадәр билгеләнә.

6. Иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәза балигъ булмаган килеш хөкем ителгән, уналты яше тулганчы җинаять кылган затларга алты елдан артык булмаган срокка билгеләнә. Аеруча авыр җинаять кылган шул ук категориядәге балигъ булмаган затларга, шулай ук башка балигъ булмаган килеш хөкем ителгән затларга җәза ун елдан артык булмаган срокка билгеләнә һәм тәрбияләү колонияләрендә узыла. Иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәза авыр булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаятьне беренче мәртәбә кылган уналты яше тулмаган, балигъ булмаган килеш хөкем ителгән затка, шулай ук авыр булмаган җинаятьне беренче мәртәбә кылган балигъ булмаган башка хөкем ителгән затларга билгеләнә алмый.

6.1. Балигъ булмаган килеш хөкем ителгән затка авыр яисә аеруча авыр җинаять кылган өчен иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаны билгеләгәндә, әлеге Кодексның Махсус өлешендәге тиешле статьяда каралган җәзаның иң түбән чиге яртылаш кыскартыла.

6.2. Әгәр шартлы рәвештә хөкем итү билгеләнгән балигъ булмаган килеш хөкем ителгән зат сынау чорында авыр булмаган яңа җинаять кылса, суд, эшнең торышын һәм гаепленең шәхесен исәпкә алып, яңа сынау чоры билгеләп һәм әлеге Кодексның 73 статьясы бишенче өлешендә каралган аерым вазифаларны үтәүне йөкләп, шартлы рәвештә хөкем итү турында кабат карар кабул итәргә мөмкин.

7. Балигъ булмаган килеш хөкем ителгән зат белән эш иткәндә, суд җәза үтәтүче органга аның шәхесенең аерым үзенчәлекләрен истә тоту турында күрсәтмә бирергә мөмкин.

89 статья. Балигъ булмаган затка җәза билгеләү

1. Балигъ булмаган затка җәза билгеләгәндә, әлеге Кодексның 60 статьясында каралган шартлардан тыш, аның тормыш һәм тәрбия шартлары, психик үсеш дәрәҗәсе, башка шәхес үзенчәлекләре, шулай ук аңа үзеннән өлкәнрәк яшьтәге затларның тәэсире исәпкә алына.

2. Балигъ булмаган яшь, җиңеләйтә торган шарт буларак, җәзаны җиңеләйтә һәм авырайта торган башка шартлар белән берлектә исәпкә алына.

90 статья. Тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чаралар куллану

1. Авыр булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаять кыл-

ган балигъ булмаган зат, әгәр тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чаралар куллану юлы белән аны төзәтү мөмкин дип танылса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителергә мөмкин.

2. Балигъ булмаган затка тәрбияви йогынтылы түбәндәге мәҗбүри чаралар билгеләнергә мөмкин:

а) кисәтү;

б) ата-аналар яисә аларны алмаштыручы башка затлар йә махсуслаштырылган дәүләт органы күзәтчелегенә тапшыру;

в) китерелгән зыянны төзәтү вазифасын йөкләү;

г) балигъ булмаган затның ялын чикләү һәм үз-үзен тотышына аерым таләпләр кую.

3. Балигъ булмаган затка бер үк вакытта тәрбияви йогынтылы берничә мәҗбүри чара билгеләнергә мөмкин. Әлеге статьяның икенче өлешендәге «б» һәм «г» пунктларында каралган тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чараларны куллану срогы авыр булмаган җинаять кылганда — бер айдан ике елга кадәр һәм уртача авырлыктагы җинаять кылганда алты айдан өч елга кадәр билгеләнә.

4. Балигъ булмаган зат тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чараны даими рәвештә үтәмәгән очракта, бу чара махсуслаштырылган дәүләт органы күрсәтмәсе буенча юкка чыгарыла һәм материаллар балигъ булмаган затны җинаять җаваплылыгына тарту өчен җибәрелә.

91 статья. Тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чараларның асылы

1. Кисәтү балигъ булмаган затка аның гамәл кылуы белән китерелгән зыянны һәм әлеге Кодекста каралган җинаятьләрне кабат кылу нәтиҗәләрен аңлатудан гыйбарәт.

2. Күзәтчелек итүгә тапшыру ата-аналарына яисә аларны алмаштыручы затларга йә махсуслаштырылган дәүләт органына балигъ булмаган затка тәрбияви йогынты ясау һәм аның үз-үзен тотышын тикшереп тору вазифаларын йөкләүдән гыйбарәт.

3. Китерелгән зыянны төзәтү вазифасы балигъ булмаган затның мөлкәти хәлен һәм аның тиешле хезмәт күнекмәләре барлыгын исәпкә алып йөкләнә.

4. Балигъ булмаган затның ялын чикләү һәм аның үз-үзен тотышына аерым таләпләр кую билгеле бер урыннарга йөрүне, ял итүнең аерым рәвешләреннән, шул исәптән механик транспорт чарасы белән идарә итүгә бәйле рәвешләреннән файдалануны тыюны, тәүлекнең билгеле бер вакытыннан соң өйдән тыш булуны чикләүне, махсуслаштырылган дәүләт органы рөхсәтеннән башка бүтән җиргә чыгып китүне чикләүне

күздә тотарга мөмкин. Балигъ булмаган затка шулай ук махсуслаштырылган дәүләт органы ярдәме белән мәгариф учреждениесенә кире кайту йә эшкә урнашу таләбе дә куелырга мөмкин. Бу исемлекне, шуның белән тәмамламыйча, дәвам итәргә дә мөмкин.

92 статья. Балигъ булмаган затларны җәзадан азат итү

1. Авыр булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаять кылган өчен хөкем ителгән балигъ булмаган затны суд, әлеге Кодексның 90 статьясы икенче өлешендә каралган тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чаралар кулланып, җәзадан азат итәргә мөмкин.

2. Уртача авырлыктагы җинаять, шулай ук авыр җинаять кылган өчен хөкем ителгән балигъ булмаган зат җәзадан суд тарафыннан азат ителергә һәм мәгариф идарәсе органының ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениесенә урнаштырылырга мөмкин. Ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учрежденисенә урнаштыру махсус тәрбияләү, укыту шартларына мохтаҗ һәм махсус педагогик якын килүне таләп итүче балигъ булмаган затны төзәтү максатларында тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чара буларак кулланыла. Балигъ булмаган зат мондый учреждениегә унсигез яше тулганчы, әмма иң күбе өч елга урнаштырылырга мөмкин.

3. Балигъ булмаган затны ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениесендә тоту, әгәр суд балигъ булмаган зат шушы чараны куллануны дәвам итүгә мохтаҗ түгел дип таныса, суд тарафыннан билгеләнгән вакыт узганчы ук туктатыла.

4. Балигъ булмаган затны ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениесендә тоту вакытын озайту бары тик балигъ булмаган затның үтенечнамәсе буенча аңа гомуми белем һәм һөнәри әзерлек алуны төгәлләү өчен кирәк булган очракта гына рөхсәт ителә.

5. Әлеге Кодексның 111 статьясы беренче һәм икенче өлешләрендә, 117 статьясы икенче өлешендә, 122 статьясы өченче өлешендә, 126 статьясында, 127 статьясы өченче өлешендә, 131 статьясы икенче өлешендә, 132 статьясы икенче өлешендә, 158 статьясы дүртенче өлешендә, 161 статьясы икенче өлешендә, 162 статьясы беренче һәм икенче өлешләрендә, 163 статьясы икенче өлешендә, 205 статьясы беренче өлешендә, 205.1 статьясы беренче өлешендә, 206 статьясы беренче өлешендә, 208 статьясында, 210 статьясы икенче өлешендә, 211 статьясы беренче өлешендә, 223 статьясы икенче һәм өченче өлешләрендә, 226 статьясы беренче һәм икенче өлешләрендә, 228.1 статьясы беренче өлешендә, 229 статьясы беренче һәм

икенче өлешләрендә каралган җинаятьләрне кылган балигъ булмаган затлар әлеге статьяның икенче өлешендә каралган тәртиптә җәзадан азат ителмиләр.

93 статья. Җәза узудан шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итү

Җәза узудан шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итү балигъ булмаган яшьтә җинаять кылган, иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән затларга карата түбәндәге җәза срокларын фактта узганнан соң кулланылырга мөмкин:

а) авыр булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаять йә авыр җинаять өчен суд тарафыннан билгеләнгән җәза срогының кимендә өчтән берен;

б) *үз көчен югалтты;*

в) аеруча авыр җинаять өчен суд тарафыннан билгеләнгән җәза срогының кимендә өчтән икесен.

94 статья. Җавапка тарту сроклары

Әлеге Кодексның 78 һәм 83 статьяларында каралган җавапка тарту сроклары балигъ булмаган затларны җинаять җаваплылыгыннан яисә җәза узудан азат иткәндә яртылаш кыскартыла.

95 статья. Хөкем ителүне юкка чыгару сроклары

Унсигез яше тулганчы җинаять кылган затлар өчен әлеге Кодексның 86 статьясы өченче өлешендә каралган хөкем ителүне юкка чыгару сроклары кыскартыла һәм түбәндәгеләргә тигез була:

а) авыр булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаять өчен иректән мәхрүм итү җәзасын узганнан соң — бер елга;

б) авыр яисә аеруча авыр җинаять өчен иректән мәхрүм итү җәзасын узганнан соң — өч елга.

96 статья. Әлеге бүлек нигезләмәләрен унсигез яшьтән егерме яшькә кадәрге затларга карата куллану

Аерым очракларда, кылган гамәлнең характерын һәм шәхесне исәпкә алып, суд әлеге бүлек нигезләмәләрен унсигез яшьтән егерме яшькә кадәр җинаять кылган затларга карата кулланырга мөмкин, аларны мәгариф идарәсе органының ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениесенә йә тәрбияләү колониясенә урнаштыру моңа керми.

VI кисәк. Медицина характерындагы мәҗбүри чаралар

15 бүлек. Медицина характерындагы мәҗбүри чаралар

97 статья. Медицина характерындагы мәҗбүри чараларны куллану нигезләре

1. Медицина характерындагы мәҗбүри чараларны суд түбәндәге затларга билгеләргә мөмкин:

а) әлеге Кодексның Махсус өлешендәге статьяларда каралган гамәлләрне үз акылында булмаган килеш башкаручыларга;

б) психикасы җинаять кылганнан соң җәза билгеләү яисә җәза узу мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп какшаган затларга;

в) җинаять кылган һәм психикасы үз акылына зыян китермәслек итеп какшаган затларга;

г) *үз көчен югалтты.*

2. Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән затларга медицина характерындагы мәҗбүри чаралар бары тик аларның психикасы какшау башка җитди зыян китерергә мөмкин булганда йә үзе өчен һәм башка затлар өчен куркыныч тудырганда гына билгеләнә.

3. Медицина характерындагы мәҗбүри чараларны үтәтү тәртибе Россия Федерациясенең җинаять-башкару законнары һәм башка федераль законнар белән билгеләнә.

4. Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән һәм үзләренең психик халәте буенча куркыныч тудырмый торган затларга карата суд бу затларны дәвалау турындагы мәсьәләне хәл итү яисә аларны сәламәтлек турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә социаль тәэминатның психоневрологик учреждениеләренә җибәрү турындагы мәсьәләне хәл итү өчен тиешле материалларны сәламәтлек саклау органнарына тапшырырга мөмкин.

98 статья. Медицина характерындагы мәҗбүри чараларны куллану максатлары

Медицина характерындагы мәҗбүри чараларны куллану максатлары әлеге Кодексның 97 статьясы беренче өлешендә күрсәтелгән затларны дәвалаудан яисә аларның психик халәтен яхшыртудан, шулай ук аларның әлеге Кодексның Махсус өлешендәге статьяларда каралган яңа гамәлләрне кылмауларын кисәтүдән гыйбарәт.

99 статья. Медицина характерындагы мәҗбүри чараларның төрләре

1. Суд медицина характерындагы мәҗбүри чараларның түбәндәге төрләрен билгеләргә мөмкин:

а) амбулатор мәҗбүри күзәтү һәм психиатр-табибта дәвалау;

б) гомуми типтагы психиатрия стационарында мәҗбүри дәвалау;

в) махсуслаштырылган типтагы психиатрия стационарында мәҗбүри дәвалау;

г) махсуслаштырылган типтагы психиатрия стационарында интенсив күзәтү алып барып мәҗбүри дәвалау.

2. Үз акылында килеш кылган җинаятьләр өчен хөкем ителгән, әмма акылына зыян китермәслек итеп какшаган психикасын дәвалауга мохтаҗ затларга суд, җәза белән беррәттән, амбулатор мәҗбүри күзәтү һәм психиатр-табибта дәвалану рәвешендә медицина характерындагы мәҗбүри чара билгеләргә мөмкин.

100 статья. Амбулатор мәҗбүри күзәтү һәм психиатр-табибта дәвалану

Амбулатор мәҗбүри күзәтү һәм психиатр-табибта дәвалану, әгәр зат үзенең психик халәте буенча психиатрия стационарына урнаштыруга мохтаҗ булмаса, әлеге Кодексның 97 статьясында каралган нигезләр буенча билгеләнергә мөмкин.

101 статья. Психиатрия стационарында мәҗбүри дәвалау

1. Психиатрия стационарында мәҗбүри дәвалау, әгәр затның психикасы какшау үзенчәлеге бары тик психиатрия стационарында дәвалау, карау, тоту һәм күзәтү шартларын таләп итә торган булса, әлеге Кодексның 97 статьясында каралган нигезләр буенча билгеләнергә мөмкин.

2. Гомуми типтагы психиатрия стационарында мәҗбүри дәвалау үзенең психик халәте буенча стационар дәвалануга һәм күзәтүгә мохтаҗ, әмма интенсив күзәтүне таләп итми торган затка карата билгеләнергә мөмкин.

3. Махсуслаштырылган типтагы психиатрия стационарында мәҗбүри дәвалау үзенең психик халәте буенча даими күзәтеп торуны таләп итә торган затка карата билгеләнергә мөмкин.

4. Махсуслаштырылган типтагы психиатрия стационарында интенсив күзәтү алып барып мәҗбүри дәвалау үзенең психик халәте буенча үзенә яисә башка затларга аеруча куркыныч тудыра һәм даими һәм интенсив күзәтүне таләп итә торган затка карата билгеләнергә мөмкин.

102 статья. Медицина характерындагы мәҗбүри чаралар куллануны озайту, үзгәртү һәм туктату

1. Медицина характерындагы мәҗбүри чаралар куллануны озайту, үзгәртү һәм туктату мәҗбүри дәвалауны гамәлгә ашыручы учреждениенең администрациясе күрсәтмәсе буенча, психиатр-табиблар комиссиясе бәяләмәсе нигезендә суд тарафыннан башкарыла.

2. Медицина характерындагы мәҗбүри чара билгеләнә торган зат мондый чараны куллануны туктату яисә үзгәртү турында судка күрсәтмә кертү өчен нигезләрнең барлыгы хакындагы мәсьәләне хәл итү өчен алты айга кимендә бер мәртәбә психиатр-табиблар комиссиясенең таныклавын узарга тиеш. Мондый затны таныклау дәвалаучы табиб инициативасы белән, әгәр дәвалау барышында ул медицина характерындагы мәҗбүри чараны үзгәртү йә аны куллануны туктату зарурлыгы турындагы нәтиҗәгә килсә, уздырыла, шулай ук затның үзенең, аның законлы вәкиленең һәм (яисә) якын туганының үтенечнамәсе буенча уздырыла. Үтенечнамә, соңгы таныклау вакытына бәйсез рәвештә, мәҗбүри дәвалауны гамәлгә ашыручы учреждение администрациясе аша бирелә. Медицина характерындагы мәҗбүри чараны куллануны туктату яисә үзгәртү өчен нигезләр булмаганда, мәҗбүри дәвалауны гамәлгә ашыручы учреждение администрациясе судка мәҗбүри дәвалауны озайту өчен бәяләмә тапшыра. Мәҗбүри дәвалауны беренче озайту дәвалау башланганнан соң алты ай узгач башкарылырга мөмкин, мәҗбүри дәвалауны шуннан соңгы озайту ел саен башкарыла.

3. Медицина характерындагы мәҗбүри чараны үзгәртү яисә туктату затның психик халәтенә карата, элек билгеләнгән чараны куллану зарурлыгы юкка чыккан очракта йә медицина характерындагы башка мәҗбүри чара билгеләү зарурлыгы барлыкка килгән очракта суд тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Психиатрия стационарында мәҗбүри дәвалауны куллану туктатылган очракта, суд мәҗбүри дәваланучы затка карата булган кирәкле материалларны аны дәвалау яисә сәламәтлек саклау турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә социаль тәэминатның психоневрологик учреждениесенә җибәрү мәсьәләсен хәл итү өчен сәламәтлек саклау органнарына тапшырырга мөмкин.

103 статья. Медицина характерындагы мәҗбүри чаралар куллану вакытын исәпкә кертү

Җинаять кылганнан соң, җәза билгеләгәндә яисә аны үтәүне яңадан башлаганда психикасы какшаган затны дәвалап чы-

гарган очракта, психиатрия стационарында затка карата мәҗбүри дәвалау чарасы кулланылган вакыт, психиатрия стационарында булган бер көн бер көн иректән мәхрүм итүгә тиң саналып, җәза срогына исәпләнә.

104 статья. Җәза узуга өстәлгән медицина характерындагы мәҗбүри чаралар

1. Әлеге Кодексның 99 статьясы икенче өлешендә каралган очракларда медицина характерындагы мәҗбүри чаралар иректән мәхрүм итү җәзасын узу урынында, ә башка җәза чараларына хөкем ителгән затларга карата амбулатор психиатрия ярдәмен күрсәтүче сәламәтлек саклау органнары учреждениеләрендә башкарыла.

2. Хөкем ителгән затның психик халәте стационар дәвалауны таләп итәрлек итеп үзгәргәндә, хөкем ителгән затны психиатрия стационарына яисә башка дәвалау учреждениесенә урнаштыру сәламәтлек саклау турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм нигезләрдә башкарыла.

3. Күрсәтелгән учреждениеләрдә булган вакыт җәза узу срогына кертеп исәпләнә. Хөкем ителгән затны мондый учреждениеләрдә алга таба дәвалау зарурлыгы юкка чыкканда, аны бу учреждениеләрдән чыгару сәламәтлек саклау турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

4. Җәза узуга өстәлгән медицина характерындагы мәҗбүри чара куллануны туктату җәза үтәтүче орган күрсәтмәсе буенча, психиатр-табиблар комиссиясе бәяләмәсе нигезендә суд тарафыннан башкарыла.

МАХСУС ӨЛЕШ

VII кисәк. Шәхескә каршы җинаятьләр

16 бүлек. Гомергә һәм сәламәтлеккә каршы җинаятьләр

105 статья. Үтерү

1. Үтергән, ягъни аңлы рәвештә башка кешене үлемгә китергән өчен —

алты елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Түбәндәгечә үтергән өчен:

а) ике яисә аннан күбрәк затларны;

б) затның хезмәт эшчәнлегенә яисә иҗтимагый бурычын үтәвенә бәйле рәвештә, аңа яисә аның якыннарына карата;

в) затны, аның ярдәмгә мохтаҗ хәлдә булуын белә торып, шулай ук кеше урлауга йә тотык итеп алуга бәйле рәвештә;

г) йөкле булуын белә торып, хатын-кызны;

д) аеруча рәхимсезлек күрсәтеп;

е) гомумкуркыныч ысул белән;

ж) затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем тарафыннан;

з) астыртын ният белән яисә яллау буенча, шулай ук талауга, куркытуга яисә бандитлыкка бәйле;

и) хулиганлык максатларыннан чыгып;

к) башка җинаятьне яшереп калдыру яисә аны җиңеләйтү максаты белән, шулай ук көчләү яисә сексуаль характердагы көч кулланып;

л) милли, раса, дини нәфрәт яисә дошманлык йә үч алу мотивы буенча;

м) зыян күрүченең әгъзаларыннан яисә тукымаларыннан файдалану максатларында;

н) *үз көчен югалтты* —

сигез елдан егерме елга кадәр irектән мәхрүм итү, йә гомерлеккә иректән мәхрүм итү, йә үлем җәзасы рәвешендә җәза бирелә.

106 статья. Ана кешенең яңа туган баласын үтерүе

Ана бала тудырган вакытта яисә тудырганнан соң ук баласын үтергән өчен, шулай ук ана яңа туган баласын психикасына зыян килгән шартларда яисә психикасы үз акылына зыян китермәслек итеп какшаган хәлдә үтергән өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

107 статья. Аффект хәлендә булганда үтерү

1. Зыян күрүче тарафыннан көч куллану, мәсхәрәләү яисә хурлау йә зыян күрүченең законсыз яисә әхлаксыз башка төрле гамәлләре (гамәл кылмаулары), шулай ук зыян күрүченең даими рәвештә законсыз яисә әхлаксыз кылган гамәлләренә бәйле психикасына озак вакытка зыян килгәндә кинәт кенә барлыкка килгән көчле рухи дулкынлану (аффект) хәлендә үтергән өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү яисә шул ук срокка иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Аффект хәлендә ике яисә аннан күбрәк затны үтергән өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

108 статья. Үз-үзеңне яклау чикләрен арттырып җибәргәндә йә җинаять кылган затны тоткарлау өчен кирәкле чаралар куллануны арттырып җибәргәндә үтерү

1. Үз-үзеңне яклау чикләрен арттырып җибәргәндә үтергән өчен —

ике елга кадәр ирекне чикләү яисә шул ук срокка irектән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Җинаять кылган затны тоткарлау өчен кирәкле чаралар куллануны арттырып җибәргәндә үтергән өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү яисә шул ук срокка иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

109 статья. Саксызлык аркасында үлемгә китерү

1. Саксызлык аркасында үлемгә китергән өчен —

ике елга кадәр ирекне чикләү яисә шул ук срокка иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Затның үз һөнәри вазифаларын тиешенчә башкармавы нәтиҗәсендәге саксызлык аркасында үлемгә китергән өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү йә шул ук срокка ирекне чикләү рәвешендә җәза бирелә.

3. Саксызлык аркасында ике яисә аннан күбрәк затларның үлеменә китергән өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү йә шул ук срокка ирекне чикләү рәвешендә җәза бирелә.

110 статья. Үз-үзен үтерүгә җиткерү

Янаулар, рәхимсез мөгамәлә яисә зыян күрүченең кешелек абруен даими рәвештә кимсетү юллары белән затны үз-үзен үтерүгә яисә үз-үзен үтерергә омтылуга җиткергән өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү яисә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

111 статья. Аңлы рәвештә сәламәтлеккә зур зыян китерү

1. Кеше гомере өчен куркыныч булган яисә сукыраюны, телдән калуны, чукраклануны йә нинди дә булса әгъзаны яисә шул әгъзаның функцияләрен югалтуны, йөклелекнең өзелүен, психиканың какшавын, наркомания йә токсикомания белән чирләүне китереп чыгарырлык, яисә битнең төзәтеп булмаслык ямьсезләнүен, яисә хезмәткә гомуми сәләтлелекне кимендә өчтән бергә киметүгә яисә белә торып һөнәри хезмәткә

сәләтлелекне тулысынча югалтуга китерерлек итеп аңлы рәвештә сәламәтлеккә зур зыян ясаган өчен —

ике елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) затның хезмәт эшчәнлегенә яисә иҗтимагый бурычын үтәвенә бәйле рәвештә, аңа яисә аның якыннарына карата;

б) зыян күрүчегә аеруча рәхимсезлек күрсәтеп, аны мәсхәрәләп яисә газаплап, шулай ук, гаеплегә мәгълүм була торып, ярдәмгә мохтаҗ булган затка карата;

в) гомумкуркыныч ысул белән;

г) яллау буенча;

д) хулиганлык максатларыннан чыгып;

е) милли, раса, дини нәфрәт яисә дошманлык мотивы буенча;

ж) зыян күрүченең әгъзаларыннан яисә тукымаларыннан файдалану максатларында —

өч елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләр өчен, әгәр алар түбәндәгечә башкарылса:

а) затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем тарафыннан;

б) ике яисә аннан күбрәк затларга карата;

в) *үз көчен югалтты* —

биш елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Әлеге статьяның беренче, икенче яисә өченче өлешләрендә каралган, саксызлык аркасында зыян күрүченең үлеменә китергән гамәлләр өчен —

биш елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

112 статья. Аңлы рәвештә сәламәтлеккә уртача авырлыкта зыян китерү

1. Кеше гомере өчен куркыныч булмаслык һәм әлеге Кодексның 111 статьясында күрсәтелгән нәтиҗәләрне китереп чыгармаслык, әмма сәламәтлеккә озак вакытка зыян китергән яисә хезмәткә гомуми сәләтлелекне кимендә өчтән бергә киметерлек итеп, аңлы рәвештә сәламәтлеккә зыян ясаган өчен —

өч айдан алты айга кадәр кулга алу яисә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) ике яисә аннан күбрәк затларга карата;

б) затның хезмәт эшчәнлегенә яисә иҗтимагый бурычын үтәвенә бәйле рәвештә, аңа яисә аның якыннарына карата;

в) зыян күрүчегә рәхимсезлек күрсәтеп, аны мәсхәрәләп яисә газаплап, шулай ук, гаеплегә мәгълүм була торып, ярдәмгә мохтаҗ булган затка карата;

г) затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем тарафыннан;

д) хулиганлык максатларыннан чыгып;

е) милли, раса, дини нәфрәт яисә дошманлык мотивы буенча;

ж) *үз көчен югалтты* —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

113 статья. Аффект хәлендә сәламәтлеккә зур яисә уртача авырлыкта зыян китерү

Зыян күрүче тарафыннан көч куллану, мәсхәрәләү яисә хурлау йә зыян күрүченең законсыз яисә әхлаксыз башка төрле гамәлләре (гамәл кылмаулары), шулай ук зыян күрүченең даими рәвештә законсыз яисә әхлаксыз кылган гамәлләренә бәйле психикасына озак вакытка зыян килгәндә кинәт кенә барлыкка килгән көчле рухи дулкынлану (аффект) хәлендә сәламәтлеккә зур яисә уртача авырлыкта зыян китергән өчен —

ике елга кадәр ирекне чикләү яисә шул ук срокка иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

114 статья. Үз-үзеңне яклау чикләрен арттырып җибәргәндә йә җинаять кылган затны тоткарлау өчен кирәкле чаралар куллануны арттырып җибәргәндә сәламәтлеккә зур яисә уртача авырлыкта зыян китерү

1. Үз-үзеңне яклау чикләрен арттырып җибәргәндә сәламәтлеккә аңлы рәвештә зур зыян китергән өчен —

ике елга кадәр ирекне чикләү яисә бер елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Җинаять кылган затны тоткарлау өчен кирәкле чаралар куллануны арттырып җибәргәндә сәламәтлеккә аңлы рәвештә зур яисә уртача авырлыкта зыян китергән өчен —

ике елга кадәр ирекне чикләү яисә шул ук срокка иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

115 статья. Сәламәтлеккә аңлы рәвештә җиңелчә зыян китерү

1. Сәламәтлеккә аны кыска вакытка какшатырлык яисә хезмәткә гомуми сәләтлелекне азрак киметүгә китерерлек итеп аңлы рәвештә җиңелчә зыян ясаган өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре,

йә ике айдан дүрт айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Хулиганлык максатларыннан чыгып, шул ук гамәлләрне кылган өчен —

йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айдан бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

116 статья. Кыйнаулар

1. Физик авырту барлыкка китергән, әмма әлеге Кодексның 115 статьясында күрсәтелгән нәтиҗәләргә китермәгән кыйнаулар яисә көч кулланып кылган башка гамәлләр өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Хулиганлык максатларыннан чыгып, шул ук гамәлләрне кылган өчен —

йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айдан бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

117 статья. Җәфалау

1. Даими рәвештә кыйнау йә көч кулланып кылган башка гамәлләр аша физик яисә психик борчулар тудырган өчен, әгәр алар әлеге Кодексның 111 һәм 112 статьяларында күрсәтелгән нәтиҗәләргә китермәсә, —

өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) ике яисә аннан күбрәк затларга карата;

б) затның хезмәт эшчәнлегенә яисә иҗтимагый бурычын үтәвенә бәйле рәвештә, аңа яисә аның якыннарына карата;

в) йөкле булуын белә торып, хатын-кызга карата;

г) белә торып балигъ булмаган затка яисә ярдәмгә мохтаҗ булган йә гаеплегә матди яисә башка бәйлелектә торган затка, шулай ук урланган йә тотык итеп алынган затка карата;

д) газаплаулар юлы белән;

е) затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем тарафыннан;

ж) яллау буенча;

з) милли, раса, дини нәфрәт яисә дошманлык мотивы буенча —

өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Шушы Кодексның әлеге статьясында һәм башка статьяларында газаплаулар дигәндә, күрсәтмәләр бирүгә яисә кеше ихтыярына каршы башка гамәлләргә мәҗбүр итү максатларында, шулай ук җәзалау максатларында йә башка максатларда физик яисә әхлакый борчулар китерү аңлашыла.

118 статья. Саксызлык аркасында сәламәтлеккә зур зыян китерү

1. Саксызлык аркасында сәламәтлеккә зур зыян китергән өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Зат үзенең һөнәри вазифаларын үтәмәү аркасында кылган шул ук гамәл өчен —

дүрт елга кадәр ирекне чикләү йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, бер елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. *Үз көчен югалтты.*

4. *Үз көчен югалтты.*

119 статья. Үтерү яисә сәламәтлеккә зур зыян китерү белән янау

Үтерү яисә сәламәтлеккә зур зыян китерү белән янаган өчен, әгәр бу янауны гамәлгә ашырудан куркырлык нигезләр булса, —

ике елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

120 статья. Трансплантацияләү өчен кеше әгъзаларын яисә тукымаларын алырга мәҗбүр итү

1. Көч кулланып йә аны куллану белән янап, трансплантацияләү өчен кеше әгъзаларын яисә тукымаларын алырга мәҗбүр иткән өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Белә торып ярдәмгә мохтаҗ булган йә гаеплегә матди яисә башка бәйлелектә торган затка карата кылган шул ук гамәл өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елдан биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

121 статья. Венерик авыру йоктыру

1. Үзендә венерик авыруның булганын белә торып, аны башка затка йоктырган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Ике яисә аннан күбрәк затларга карата йә белә торып балигъ булмаган затка карата кылган шул ук гамәл өчен —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

122 статья. ВИЧ-инфекция йоктыру

1. Белә торып башка затны ВИЧ-инфекция йоктыру куркынычы астына куйган өчен —

өч елга кадәр иректе чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә бер елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Үзендә ВИЧ-инфекциянең барлыгын белә торып, аны башка затка йоктырган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Ике яисә аннан күбрәк затларга карата йә белә торып балигъ булмаган затка карата әлеге статьяның икенче өлешендә каралган гамәлне кылган өчен —

сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Үзенең һөнәри вазифаларын тиешенчә башкармау нәтиҗәсендә бүтән затка ВИЧ-инфекция йоктырган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне кылган зат, ВИЧ-инфекция йок-

тыру куркынычы астына куелган яисә йоктырган башка зат беренче затта шул авыруның булуы турында вакытында кисәтелгән һәм йоктыру куркынычын тудырган гамәлләрне кылырга ихтыяри килешкән очракта, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

123 статья. Законсыз аборт ясау

1. Тиешле профильдә югары медицина белеме булмаган зат аборт ясаган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

2. *Үз көчен югалтты.*

3. Шул ук гамәл өчен, әгәр ул саксызлык аркасында зыян күрүченең үлеменә йә аның сәламәтлегенә зур зыян китерсә, —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

124 статья. Авыруга ярдәм күрсәтмәү

1. Авыруга закон яисә махсус кагыйдә нигезендә ярдәм итәргә тиешле зат мөһим сәбәпләрсез ярдәм күрсәтмәгән өчен, әгәр бу саксызлык аркасында авыру сәламәтлегенә уртача авырлыкта зыян китерсә, —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике айдан дүрт айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәл өчен, әгәр ул саксызлык аркасында авыруның үлеменә яисә аның сәламәтлегенә зур зыян китерсә, —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

125 статья. Куркыныч астында калдыру

Гомере яисә сәламәтлеге өчен куркыныч хәлдә һәм яшь, карт булуы аркасында, авыру сәбәпле яисә үзенең ярдәмгә мохтаҗ булуы аркасында үз-үзен саклау чараларын күрү мөмкинлегеннән мәхрүм булган затны белә торып ярдәмсез калдырган өчен, әгәр гаепле затның бу затка ярдәм итү мөмкинлеге һәм ул

аны кайгыртырга тиеш булган булса йә ул үзе затны аның гомере яисә сәламәтлеге өчен куркыныч хәлдә калдырса, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу, йә бер елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

17 бүлек. Шәхеснең ирегенә, намусына һәм абруена каршы җинаятьләр

126 статья. Кеше урлау

1. Кеше урлаган өчен –

дүрт елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме тарафыннан;

б) *үз көчен югалтты;*

в) кеше гомере яисә сәламәтлеге өчен куркыныч көч кулланып йә шундый көч куллану белән янап;

г) корал яисә корал буларак файдаланылучы предметлар кулланып;

д) белә торып балигъ булмаган затка карата;

е) белә торып йөкле хатын-кызга карата;

ж) ике яисә аннан күбрәк затларга карата;

з) астыртын ниятләр белән —

алты елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне кылган өчен, әгәр алар:

а) оешкан төркем тарафыннан башкарылса;

б) *үз көчен югалтты;*

в) саксызлык аркасында бу гамәлләр зыян күрүченең үлеменә яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә —

сигез елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Урланган затны ихтыяри рәвештә азат иткән зат, әгәр аның гамәлләрендә башка җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

127 статья. Законсыз рәвештә иректән мәхрүм итү

1. Урлауга бәйле булмаган килеш кешене законсыз рәвештә иректән мәхрүм иткән өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме тарафыннан;

б) *үз көчен югалтты;*

в) кеше гомере яисә сәламәтлеге өчен куркыныч көч кулланып;

г) корал яисә корал буларак файдаланылучы башка предмет кулланып;

д) белә торып балигъ булмаган затка карата;

е) белә торып йөкле хатын-кызга карата;

ж) ике яисә аннан күбрәк затларга карата —

өч елдан биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләр өчен, әгәр аларны оешкан төркем кылган булса йә саксызлык аркасында бу гамәлләр зыян күрүченең үлеменә яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

дүрт елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

127.1 статья. Кешеләр белән сәүдә итү

1. Кешеләр белән сәүдә иткән, ягъни кешене эксплуатацияләү максатларында сатып алган-сатып җибәргән йә аны вербовкалаган, башка җиргә күчергән, тапшырган, яшергән яисә алган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Түбәндәгечә кылган шул ук гамәл өчен:

а) ике яисә аннан күбрәк затларга карата;

б) белә торып балигъ булмаган затка карата;

в) зат ул гамәлне хезмәт урыныннан файдаланып кылса;

г) зыян күрүчене Россия Федерациясе Дәүләт чигеннән уздырып яисә, чиктән узгач, аны законсыз тоткарлап;

д) ялган документлар кулланып, шулай ук зыян күрүченең шәхесен таныклаучы документларын тартып алып, яшереп йә юкка чыгарып;

е) көч кулланып яисә аны куллану белән янап;

ж) зыян күрүченең әгъзаларын яисә тукымаларын алу максатларында —

өч елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләр өчен, әгәр алар:

а) саксызлык аркасында бу гамәлләр зыян күрүченең үле-

менә китерсә, сәламәтлегенә зур зыян салса яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә;

б) күп кешеләр гомере һәм сәламәтлеге өчен куркыныч юл белән кылынса;

в) оешкан төркем тарафыннан кылынса —

сигез елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмәләр. 1. Әлеге статьяның беренче өлешендә яисә икенче өлешенең «а» пунктында каралган гамәлләрне беренче мәртәбә кылган һәм зыян күрүчене ихтыяри рәвештә коткарган һәм кылган җинаятьне ачарга ярдәм иткән зат, әгәр аның гамәлләрендә башка җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

2. Әлеге статьяда кешене эксплуатацияләү дигәндә фахишәлек белән шөгыльләнүне башка затлар тарафыннан файдалану һәм сексуаль эксплуатацияләүнең башка рәвешләре, коллык хезмәте (хезмәт күрсәтүләре), тоткын хәлендә булуы аңлашыла.

127.2 статья. Коллык хезмәтеннән файдалану

1.Үзенә карата милек хокукына хас вәкаләтләр гамәлгә ашырыла торган кешенең хезмәтеннән файдаланган өчен, ул зат үзенә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында эшләр башкарудан (хезмәт күрсәтүдән) баш тарта алмаган очракта, —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне түбәндәгечә кылган өчен:

а) ике яисә аннан күбрәк затларга карата;

б) белә торып балигъ булмаган затка карата;

в) зат ул гамәлне хезмәт урыныннан файдаланып кылса;

г) шантаж, көч кулланып яисә аны куллану белән янап;

д) зыян күрүченең шәхесен таныклаучы документларын тартып алып, яшереп йә юкка чыгарып —

өч елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләр саксызлык аркасында үлемгә китерсә, зыян күрүченең сәламәтлегенә зур зыян салса яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә йә оешкан төркем кылса —

сигез елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

128 статья. Психиатрия стационарына законсыз урнаштыру

1. Психиатрия стационарына законсыз урнаштырган өчен —

өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәл өчен, әгәр аны зат хезмәт урыныннан фай-

даланып кылса йә саксызлык аркасында ул гамәл зыян күрүченең үлеменә яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым бер эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

129 статья. Яла ягу

1. Яла яккан, ягъни башка затның намусына һәм абруена тап төшерерлек яки аның репутациясен бозарлык итеп, белә торып ялган белешмәләр тараткан өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

2. Ачык чыгышта, ачык демонстрацияләнүче әсәрдә яисә массакүләм мәгълүмат чараларында яла яккан өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

3. Затны авыр яисә аеруча авыр җинаять кылуда гаепләп яла яккан өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

130 статья. Хурлау

1. Әдәпсез рәвештә хурлаган, ягъни башка затның намусына һәм абруена тап төшергән өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

2. Ачык чыгышта, ачык демонстрацияләнүче әсәрдә яисә массакүләм мәгълүмат чараларында хурлаган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

18 бүлек. Шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенес ирегенә каршы җинаятьләр

131 статья. Көчләү

1. Көчләгән, ягъни зыян күрүче хатын-кызга яки башка затларга карата көч кулланып яисә аны куллану белән янап йә зыян күрүче хатын-кызның каршылык күрсәтә алмаслык хәлдә булуыннан файдаланып, җенси мөнәсәбәткә кергән өчен —

өч елдан алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Көчләүне түбәндәгечә кылган өчен:

а) *үз көчен югалтты;*

б) затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем тарафыннан;

в) зыян күрүче хатын-кызга яисә башка затларга карата үтерү белән янап яисә аларның сәламәтлегенә зур зыян салып, шулай ук аеруча рәхимсезлек күрсәтеп;

г) зыян күрүче хатын-кызга венерик авыру йоктырып;

д) белә торып балигъ булмаган кыз баланы көчләгән өчен —

дүрт елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Көчләү:

а) саксызлык аркасында бу гамәл зыян күрүче хатын-кызның үлеменә китерсә;

б) саксызлык аркасында бу гамәл зыян күрүче хатын-кызның сәламәтлегенә зур зыян салса, ВИЧ-инфекция йоктыруга яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә;

в) белә торып ундүрт яше тулмаган кыз баланы көчләгән өчен —

сигез елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

132 статья. Сексуаль характердагы көч куллану гамәлләре

1. Зыян күрүче ир-атка (хатын-кызга) яисә башка затларга карата көч кулланып яки аны куллану белән янап йә зыян күрүче ир-атның (хатын-кызның) каршы тора алмаслык хәлдә булуыннан файдаланып, ир-ат ир-ат белән (мужеложство), хатын-кыз хатын-кыз белән (лесбиянлык) сексуаль мөнәсәбәткә кергән яисә сексуаль характердагы башка гамәлләр кылган өчен —

өч елдан алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) *үз көчен югалтты;*

б) затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем тарафыннан;

в) зыян күрүче ир-атка (хатын-кызга) яисә башка затларга карата үтерү белән янап яисә аларның сәламәтлегенә зур зыян салып, шулай ук аеруча рәхимсезлек күрсәтеп;

г) зыян күрүче ир-атка (хатын-кызга) венерик авыру йоктырып;

д) белә торып балигъ булмаган ир баланы (кыз баланы) көчләгән өчен —

дүрт елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләр:

а) саксызлык аркасында алар зыян күрүче ир-атның (хатын-кызның) үлеменә китерсә;

б) саксызлык аркасында алар зыян күрүче ир-атның (хатын-кызның) сәламәтлегенә зур зыян китерсә, ВИЧ-инфекция йоктыруга яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә;

в) белә торып ундүрт яше тулмаган затка карата гамәл кылынса —

сигез елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

133 статья. Сексуаль характердагы гамәлләр кылуга мәҗбүр итү

Зыян күрүче ир-атны (хатын-кызны) шантаж юлы белән, мөлкәтен юкка чыгару, бозу яисә тартып алу белән куркытып, йә матди яки башкача бәйлелек белән куркытып, җенси мөнәсәбәткә керергә, ир-ат ир-ат белән, хатын-кыз хатын-кыз белән сексуаль мөнәсәбәткә керергә яисә сексуаль характердагы башка гамәлләр кылуга мәҗбүр иткән өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә бер елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

134 статья. Уналты яше тулмаган зат белән җенси мөнәсәбәткә керү һәм сексуаль характердагы башка гамәлләр кылу

Унсигез яше тулган зат белә торып уналты яше тулмаган зат белән җенси мөнәсәбәткә кергән, ир-ат ир-ат белән яисә хатын-кыз хатын-кыз белән сексуаль мөнәсәбәткә кергән яисә гамәлләр кылган өчен —

өч елга кадәр иректе чикләү яисә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

135 статья. Бозыклык гамәлләре кылу

Унсигез яше тулган зат белә торып уналты яше тулмаган затка карата көч кулланмыйча гына бозыклык гамәлләре кылган өчен —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр ирекне чикләү, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

19 бүлек. Кеше һәм гражданның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә каршы җинаятьләр

136 статья. Кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре тигезлеген бозу

1. Дискриминацияләгән, ягъни кеше һәм гражданның җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәти хәленә һәм хезмәт урынына, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, кайсы иҗтимагый берләшмәгә яисә нинди социаль төркемнәргә каравына бәйле рәвештә, аның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылган шул ук гамәлләр өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз егерме сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

137 статья. Хосусый тормыш кагылгысызлыгын бозу

1. Затның шәхси яисә гаилә серен тәшкил итә торган хосусый тормышы турындагы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка законсыз рәвештә җыйган яисә тараткан йә бу белешмәләрне ачык чыгышта, ачык демонстрацияләнүче әсәрдә яисә массакүләм мәгълүмат чараларында тараткан өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кере-

ме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә дүрт айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылган шул ук гамәлләр өчен –

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елдан биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

138 статья. Хатлар язышу, телефоннан сөйләшү, почта, телеграф яисә башкача хәбәрләшү серен бозу

1. Гражданнарның хатлар язышу, телефоннан сөйләшү, почта, телеграф яисә башкача хәбәрләшү серен бозган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

2. Затның хезмәт урыныннан яисә яшерен рәвештә мәгълүмат алу өчен билгеләнгән махсус техник чаралардан файдаланып кылган шул ук гамәлләр өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елдан биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә ике айдан дүрт айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

3. Яшерен рәвештә мәгълүмат алу өчен билгеләнгән махсус техник чараларны законсыз җитештергән, саткан яисә сату максатларында алган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

139 статья. Торак кагылгысызлыгын бозу

1. Зат яши торган торакка аның ихтыярына каршы килеп кергән өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән зат-

ның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне көч кулланып яисә аны куллану белән янап кылган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елга кадәр ректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендәге гамәлләрне зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылган өчен —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елдан биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә ике айдан дүрт айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге Кодексның шушы статьясында, шулай ук башка статьяларында торак дигәндә, торак һәм торакка карамаган биналары булган индивидуаль торак йорт, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, торак фондына кертелгән һәм даими яисә вакытлыча яшәү өчен яраклы торак бинасы, шулай ук торак фондына кертелмәгән, әмма вакытлыча яшәү өчен билгеләнгән башка бина яисә корылма аңлашыла.

140 статья. Гражданга мәгълүмат бирүдән баш тарту

Урындагы зат билгеләнгән тәртиптә тупланган, турыдантуры гражданның хокукына һәм ирегенә кагылышлы документларны һәм материалларны бирүдән законсыз баш тарткан, йә гражданга тулы булмаган яисә белә торып ялган мәгълүмат биргән өчен, әгәр бу гамәлләр гражданнарның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә зыян китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елдан биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

141 статья. Сайлау хокукларын гамәлгә ашыруга яисә сайлау комиссияләренең эшенә комачаулык итү

1. Гражданның үз сайлау хокукларын яисә референдумда катнашу хокукын ирекле гамәлгә ашыруга комачаулык ит-

кән, тавыш бирү серен бозган, шулай ук сайлау комиссияләренең, референдум комиссияләренең эшенә, йә сайлау комиссиясе, референдум комиссиясе әгъзасының үз вазифаларын башкаруга бәйле эшчәнлегенә комачаулык иткән өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) сатып алу, алдау, мәҗбүр итү юлы белән, көч кулланып йә аны куллану белән янап;

б) зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып;

в) алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем тарафыннан —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Хезмәт вазифасыннан яисә хезмәт урыныннан файдаланып, сайлау комиссиясенең, референдум комиссиясенең законнарда билгеләнгән вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда аның карарларына тәэсир итү максатында тыкшынган, аерым алганда, урындагы зат кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәү, сайлаучылар, референдумда катнашучылар тавышларын санау мәсьәләләре буенча һәм бары тик сайлау комиссиясе, референдум комиссиясе компетенциясенә генә кергән башка мәсьәләләр буенча таләп куйган яисә күрсәтмә биргән өчен, шулай ук Россия Федерациясенең «Сайлаулар» Дәүләт автоматлаштырылган системасы эшенә законсыз тыкшынган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

141.1 статья. Кандидатның, сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының сайлау кампаниясен финанслау, референдум уздыру буенча инициатив төркемнең, референдумда катнашучыларның бүтән төркеменең эшчәнлек тәртибен бозу

1. Кандидатка, сайлау берләшмәсенә, тиешле сайлау фондын читләтеп, сайлауларда билгеле бер нәтиҗәгә ирешү максат-

ларында зур күләмнәрдә акчалар биргән яки сайлау фондларына күчерелмәгән зур күләмнәрдәге акчаларны сайлауларда аерым бер нәтиҗәгә ирешү максатларында тоткан, яисә кандидатка, сайлау берләшмәсенә, тиешле сайлау фонды акчаларын компенсацияләмичә, сайлауларда билгеле бер нәтиҗәгә ирешү максатларында зур күләмнәрдә матди байлыклар биргән, яисә сайлауларга турыдан-туры яки читләтелгән рәвештә бәйле булган һәм сайлауларда билгеле бер нәтиҗәгә ирешүгә юнәлдерелгән түләүле эшләр башкаруны, товарлар сатуны, түләүле хезмәтләр күрсәтүне, тиешле сайлау фондыннан түләмичә яки нигезсез рәвештә түбән төшерелгән бәяләр буенча тиешле сайлау фондыннан зур күләмнәрдә түләп, гамәлгә ашырган, яисә референдум уздыру буенча инициатив төркемгә, референдумда катнашучыларның бүтән төркеменә, тиешле референдум фондын читләтеп, референдумда билгеле бер нәтиҗәгә ирешү максатларында зур күләмнәрдә акчалар биргән яки референдум фондларына күчерелмәгән зур күләмдәге акчаларны референдумда билгеле бер нәтиҗәгә ирешү максатларында тоткан, яисә референдум уздыру буенча инициатив төркемгә, референдумда катнашучыларның бүтән төркеменә, тиешле референдум фонды акчаларын компенсацияләмичә, референдумда билгеле бер нәтиҗәгә ирешү максатларында зур күләмнәрдә матди байлыклар биргән, яисә референдумга турыдан-туры яисә читләтелгән рәвештә бәйле булган һәм референдум уздыру инициативасын күрсәтүгә юнәлдерелгән түләүле эшләр башкаруны, товарлар сатуны, түләүле хезмәтләр күрсәтүне, тиешле референдум фондыннан түләмичә яки нигезсез рәвештә түбән төшерелгән бәяләр буенча тиешле референдум фондыннан зур күләмнәрдә түләп, гамәлгә ашырган, шулай ук сайлау фондына, референдум фондына ялган затлар аша зур күләмнәрдә иганәләр керткән өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә бер елга кадәр irектән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Кандидатның, сайлау берләшмәсенең сайлау кампаниясен уздыру өчен кандидат, аның финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле, сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле сайлау кампаниясен уздыру өчен, тиешле сайлау фонды акчаларыннан тыш, зур күләмнәрдә финанс (матди) ярдәмнән файдаланган өчен, референдум уздыру инициативасын күрсәтү, референдумда билгеле бер нәтиҗәгә ирешү өчен референдум уздыру буенча инициатив төркемнең, референдумда катнашучыларның

башка төркеменең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле, тиешле референдум фонды акчаларыннан тыш, зур күләмнәрдә финанс (матди) ярдәмнән файдаланган өчен, шулай ук сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнарда тыелган һәм махсус сайлау счетына, референдум фондының махсус счетына күчерелгән зур күләмнәрдәге иганәләрне тоткан өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда зур күләмдә дигәндә тиешле кандидатның, сайлау берләшмәсенең барлык сайлау фонды, референдум фонды акчаларының әлеге статьяда каралган гамәлләрне кылу мизгеленә сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнарда билгеләнгән иң чик суммасының уннан береннән артып киткән акчалата сумманың күләме, мөлкәт хакы яисә мөлкәти характердагы табыш аңлашыла, әмма ул бер миллионнан да ким булмаска тиеш.

142 статья. Сайлау документларын, референдум документларын фальсификацияләү

1. Сайлау документларын, референдум документларын фальсификацияләгән өчен, әгәр бу гамәлне сайлау комиссиясе әгъзасы, референдум комиссиясе әгъзасы, сайлау берләшмәсенең, сайлаучылар төркеменең, референдум уздыру буенча инициатив төркемнең, референдумда катнашучыларның башка төркеменең вәкаләтле вәкиле, шулай ук кандидат яисә ул вәкаләт биргән вәкил кылган булса, —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Сайлаучыларның, референдумда катнашучыларның кандидатны, сайлау берләшмәсе кандидатларының исемлеген, референдум уздыру инициативасын хуплаган имзаларын ясаган өчен яисә алдан килешенгән затлар төркеме яки оешкан төркем тарафыннан җыелган йә сатып, мәҗбүриләп, көч кулланып яисә аны куллану белән янап, шулай ук мөлкәтне юкка чыгарып яисә аны юкка чыгару белән янап, йә гражданнарның яисә оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен йә җәмгыятьнең яисә дәүләтнең закон белән саклана торган мәнфәгатьлә-

рен җитди бозуга китереп җыелган ясалма имзаларны (имза кәгазьләрен) белә торып таныклаган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елдан биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Сайлау бюллетеньнәрен, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен законсыз әзерләгән, шулай ук законсыз әзерләнгән сайлау бюллетеньнәрен, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен саклаган йә башка җиргә күчергән өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

142.1 статья. Тавыш бирү йомгакларын фальсификацияләү

Тавыш бирүдә файдаланылган бюллетеньнәргә исәпкә алынмаган бюллетеньнәрне кушкан йә сайлаучылар, референдумда катнашучылар турында белә торып ялган белешмәләр биргән, йә, актив сайлау хокукына, референдумда катнашу хокукына ия булмаган затларны яисә уйдырма затларны кертеп, сайлаучылар, референдумда катнашучылар исемлекләрен белә торып дөрес төземәгән өчен, йә сайлаучылар, референдумда катнашучылар исемлекләрендә сайлаучыларның, референдумда катнашучыларның имзаларын фальсификацияләгән, йә сайлаучыларның, референдумда катнашучыларның тамгалары куелган дөрес бюллетеньнәрне алмаштырган, йә бюллетеньнәрне сайлаучыларның, референдумда катнашучыларның ихтыяр белдерүен билгеләү мөмкинлеге булмаслык итеп бозган, йә бюллетеньнәрне законсыз юк иткән, йә сайлаучыларның, референдумда катнашучыларның тавышларын белә торып дөрес санамаган өчен, йә сайлау комиссиясе, референдум комиссиясе әгъзалары тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә тавышларны санаганчы яисә тавыш бирү йомгакларын билгеләгәнче имза салган өчен, йә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне белә торып дөрес төземәгән (тавыш бирү йомгакларына туры килмәслек итеп төзегән), йә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетәмәгә аны тутырганнан соң законсыз рәвештә үзгәрешләр керткән өчен, йә тавыш бирү йомгакларын, сайлаулар, референдум нәтиҗәләрен белә торып дөрес билгеләмәгән өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт ха-

кы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

143 статья. Хезмәтне саклау кагыйдәләрен бозу

1. Техника хәвефсезлеге кагыйдәләрен яисә хезмәтне саклауның башка кагыйдәләрен шуларны үтәү буенча җаваплы зат бозган өчен, әгәр бу саксызлык аркасында кеше сәламәтлегенә зур зыян салса, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә бер елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне саксызлык аркасында кеше үлеменә китерерлек итеп кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

144 статья. Журналистларның законлы профессиональ эшчәнлегенә комачаулау

1. Журналистларның законлы профессиональ эшчәнлегенә аларны мәгълүмат таратуга йә аны таратудан баш тартуга мәҗбүр итү юлы белән комачаулаган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

2. Зат хезмәт урыныннан файдаланып кылган шул ук гамәлләр өчен —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

145 статья. Йөкле хатын-кызны яисә өч яшькә кадәрге балалары булган хатын-кызны эшкә алудан нигезсез баш тарту яисә нигезсез эштән азат итү

Хатын-кызны йөкле булганга күрә эшкә алудан нигезсез баш тарткан яисә эштән нигезсез азат иткән өчен, шулай ук өч яшькә кадәрге балалары булган хатын-кызны эшкә алудан нигезсез баш тарткан яисә эштән нигезсез азат иткән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза бирелә.

145.1 статья. Хезмәт хакын, пенсияләрне, стипендияләрне, пособияләрне һәм башка түләүләрне түләмәү

1. Хезмәт хакын, пенсияләрне, стипендияләрне, пособияләрне һәм законда билгеләнгән башка түләүләрне барлык милек рәвешләрендәге предприятие, учреждение яисә оешма җитәкчесе астыртын ният белән яисә башка шәхси кызыксыну аркасында ике айдан артык түләмәгән өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне авыр нәтиҗәләргә китерерлек итеп кылган өчен —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

146 статья. Авторлык хокукларын һәм катнаш хокукларны бозу

1. Авторлыкны үзләштергән (плагиат) өчен, әгәр бу гамәл авторга яисә башка хокук иясенә зур зыян китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Авторлык хокукы яисә катнаш хокуклар объектларыннан законсыз файдаланган, шулай ук сату максатларында әсәрләрнең яисә фонограммаларның контрафакт нөсхәләрен зур күләмдә юнәткән, саклаган, ташыган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның икенче өлешендә каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) *үз көчен югалтты;*

б) алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем;

в) аеруча зур күләмдә;

г) зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылган өчен —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда каралган гамәлләр, әгәр әсәрләр яисә фонограммалар нөсхәләренең хакы йә авторлык хокукы һәм катнаш хокуклар объектларыннан файдалану хокукларының хакы илле мең сумнан артып китсә, – зур күләмдә кылынган, ә ике йөз илле мең сумнан артып китсә, аеруча зур күләмдә кылынган дип танылa.

147 статья. Уйлап табу һәм патентлык хокукларын бозу

1. Уйлап табудан, файдалы модельдән яисә сәнәга үрнәгеннән законсыз файдаланган, уйлап табуның, файдалы модельнең яисә сәнәга үрнәгенең асылын, алар турында белешмәләр рәсми басылып чыкканчы, автор яисә уйлап табучы ризалыгыннан башка фаш иткән, авторлыкны үзләштергән яисә соавторлыкка мәҗбүр иткән өчен, әгәр бу гамәлләр зур зыян китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

148 статья. Вөҗдан һәм дин тоту иреге хокукын гамәлгә ашыруга комачаулык итү

Дини оешмаларның эшчәнлегенә яисә дини йолаларны үтәүгә законсыз комачаулык иткән өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

149 статья. Җыелыш, митинг, демонстрация, урам йөрешләрен, пикетлауларны уздыруга яисә аларда катнашуга комачаулык итү

Җыелыш, митинг, демонстрация, урам йөрешләрен, пикетлауларны уздыруга яисә аларда катнашуга законсыз комачаулык иткән йә аларда катнашуга мәҗбүр иткән өчен, әгәр бу гамәлләрне урындагы зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып йә көч кулланып яисә аны куллану белән янап кылса, —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

20 бүлек. Гаиләгә һәм балигъ булмаган затларга каршы җинаятьләр

150 статья. Балигъ булмаган затны җинаять кылуга җәлеп итү

1. Унсигез яше тулган зат балигъ булмаган затны вәгъдәләр бирү, алдау, янау юллары яисә башка ысуллар белән җинаять кылуга җәлеп иткән өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне ата-анасы, педагог йә балигъ булмаган затны тәрбияләү вазифасы закон белән йөкләнгән башка зат кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне көч кулланып яисә аны куллану белән янап кылган өчен —

ике елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Балигъ булмаган затны җинаять төркеменә җәлеп итүгә йә авыр яисә аеруча авыр җинаять кылуга җәлеп итүгә бәйле әлеге статьяның беренче, икенче яисә өченче өлешләрендә каралган гамәлләрне кылган өчен —

биш елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

151 статья. Балигъ булмаган затны җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү

1. Унсигез яше тулган зат балигъ булмаган затны даими рәвештә спиртлы эчемлекләр, баш миңгерәткеч матдәләр куллануга, сукбайлыкка яисә соранып йөрүгә мәҗбүр иткән өчен —

йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне ата-анасы, педагог йә балигъ булмаган затны тәрбияләү вазифасы закон белән йөкләнгән башка зат кылган өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне көч кулланып яисә аны куллану белән янап кылган өчен —

алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Яшәү чыганагын югалту яисә яшәү урыны булмау аркасында авыр тормыш шартлары барлыкка килү нәтиҗәсендә ата-анасы балигъ булмаган затны сукбайлыкка җәлеп итү очракларына әлеге статьяның гамәли көче кагылмый.

152 статья. *Үз көчен югалтты.*

153 статья. Бала алыштыру

Усал ният яисә башка астыртын ниятләр белән баланы алыштырган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

154 статья. Законсыз уллыкка (кызлыкка) алу

Балаларны уллыкка (кызлыкка) алу буенча, аларны опекага (попечительлеккә), гаиләләргә тәрбияләүгә тапшыру буенча берничә тапкыр яисә астыртын ниятләр белән законсыз кылган гамәлләр өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

155 статья. Уллыкка (кызлыкка) алу серен фаш итү

Уллыкка (кызлыкка) алу фактын хезмәт яисә профессиональ сер итеп сакларга тиешле зат йә бүтән зат усал яисә башка астыртын ниятләр белән уллыкка (кызлыкка) алу серен уллыкка (кызлыкка) алучының ихтыярына каршы килеп фаш иткән өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, дүрт айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

156 статья. Балигъ булмаган затны тәрбияләү вазифаларын үтәмәү

Ата-анасы яисә тәрбияләү вазифалары йөкләнгән башка зат, шулай ук педагог яисә мәгариф, тәрбияләү, дәвалау учреждениесе йә балигъ булмаган затны күзәтүне гамәлгә ашырырга тиешле башка учреждение хезмәткәре балигъ булмаган затны тәрбияләү вазифаларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен, әгәр бу гамәл балигъ булмаган затка карата рәхимсезлек күрсәтеп башкарылса, —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч елга кадәр ирекне чикләү рәвешендә җәза бирелә.

157 статья. Балаларны яисә хезмәткә сәләтсез ата-аналарны тоту өчен акчалар түләүдән явыз ният белән читләшү

1. Балигъ булмаган балаларны, шулай ук унсигез яше тулган хезмәткә сәләтсез балаларны тоту өчен суд карары буенча акча түләүдән ата-анасы явыз ният белән читләшкән өчен —

йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Хезмәткә сәләтсез ата-аналарын тотуга суд карары буенча акча түләүдән балигъ яшьтәге хезмәткә сәләтле балалар явыз ният белән читләшкән өчен —

йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

VIII кисәк. Икътисад өлкәсендә җинаятьләр

21 бүлек. Милеккә каршы җинаятьләр

158 статья. Караклык

1. Караклык, ягъни яшерен рәвештә чит мөлкәтне урлаган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айдан бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике айдан дүрт айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Караклыкны түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) бинага йә әйбер саклана торган башка урынга законсыз үтеп кереп;

в) гражданга шактый зыян китереп;

г) зыян күрүченең киеменнән, сумкасыннан яисә кулындагы башка йөгеннән урлаган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Караклыкны торакка законсыз үтеп кереп йә зур күләмдә кылган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ике елдан алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Караклыкны түбәндәгечә кылган өчен:

а) оешкан төркем;

б) аеруча зур күләмдә —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмәләр. 1. Әлеге Кодекс статьяларында урлау дигәндә чит мөлкәтне астыртын ният белән законсыз бушлай тартып алу һәм (яисә) гаепленең яки милекчегә яисә шушы мөл-

кәт хуҗасына зыян китерүче башка затларның файдасына алу аңлашыла.

2. Әлеге бүлек статьяларында гражданга шактый зыян китерү аның мөлкәти хәлен исәпкә алып билгеләнә, әмма ул ике мең биш йөз сумнан кимрәк булмаска тиеш.

3. Әлеге бүлек статьяларында бина дигәндә вакытлыча кешеләр яшәү өчен яисә җитештерү яки башка хезмәт максатларында матди байлыкларны урнаштыру өчен билгеләнгән барлык милек рәвешләрендәге төзелмәләр һәм корылмалар аңлашыла.

Әлеге бүлек статьяларында әйбер саклана торган урын дигәндә торак корылмаларыннан аерым торучы, тирәсе әйләндереп алынган йә техник чаралар белән җиһазландырылган яисә башка саклау чаралары белән тәэмин ителгән һәм матди байлыкларны даими яисә вакытлыча саклау өчен билгеләнгән барлык милек рәвешләрендәге хуҗалык биналары, территория участоклары, магистраль торбаүткәргечләр, башка корылмалар аңлашыла.

4. Әлеге бүлек статьяларында зур күләмдә дигәндә — ике йөз илле мең сумнан артып киткән, ә аеруча зур күләмдә дигәндә бер миллион сумнан артып киткән мөлкәт хакы аңлашыла.

159 статья. Мошенниклык

1. Мошенниклык, ягъни алдау яисә ышанычка керү юлы белән чит мөлкәтне урлаган яисә чит мөлкәткә хокуклар алган өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айдан бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике айдан дүрт айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Мошенниклыкны алдан килешенгән затлар төркеме, шулай ук гражданга шактый зыян китереп кылган өчен —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Мошенниклыкны зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып, шулай ук зур күләмдә кылган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт

хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, ун мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ике елдан алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Мошенниклыкны оешкан төркем йә аеруча зур күләмдә кылган өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

160 статья. Үзләштерү яисә өскә чыгару (растрата)

1. Үзләштергән яисә өскә чыгарган (растрата ясаган) өчен, ягъни гаепле зат карамагындагы чит мөлкәтне урлаган өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне алдан килешенгән затлар төркеме, шулай ук гражданга шактый зыян китереп кылган өчен —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә биш елга кадәр ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Шул ук гамәлләрне зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып, шулай ук зур күләмдә кылган өчен —

йөз меңнән биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә, ун мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ике елдан алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Әлеге статьяның беренче, икенче һәм өченче өлешләрендә каралган гамәлләрне оешкан төркем йә аеруча зур күләмдә кылган өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

161 статья. Талау

1. Талаган, ягъни чит мөлкәтне ачыктан-ачык урлаган өчен — бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Талауны түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) *үз көчен югалтты;*

в) торакка, бинага йә әйбер саклана торган башка урынга законсыз үтеп кереп;

г) кеше гомеренә яисә сәламәтлегенә куркыныч булмаган көч кулланып йә шундый көч куллану белән янап;

д) зур күләмдә кылган өчен —

ун мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ике елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Талауны түбәндәгечә кылган өчен:

а) оешкан төркем;

б) аеруча зур күләмдә;

в) *үз көчен югалтты* —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, алты елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

162 статья. Юлбасарлык

1. Юлбасарлык, ягъни чит мөлкәтне урлау максатларында, кеше гомеренә яисә сәламәтлегенә куркыныч булган көч кулланып йә андый көчне куллану белән янап һөҗүм иткән өчен —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, өч елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Юлбасарлыкны алдан килешенгән затлар төркеме, шулай ук корал яисә корал буларак файдаланылучы башка предметлар кулланып кылган өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Юлбасарлыкны торакка, бинага йә әйбер саклана торган башка урынга законсыз үтеп кереп яисә зур күләмдә кылган өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Юлбасарлыкны түбәндәгечә кылган өчен:

а) оешкан төркем;

б) мөлкәткә хуҗа булу максатларында аеруча зур күләмдә;

в) зыян күрүченең сәламәтлегенә зур зыян салып кылган өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, сигез елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

163 статья. Куркытып алу

1. Куркытып алган, ягъни көч куллану белән, йә чит мөлкәтне юкка чыгару яисә зарарлау белән куркытып, шулай ук зыян күрүчене яисә аның якыннарын хурлыкка калдыра торган белешмәләрне, йә зыян күрүченең яисә аның якыннарының хокукларына яки законлы мәнфәгатьләренә җитди зарар китерергә мөмкин булган башка белешмәләрне тарату белән куркытып, чит мөлкәтне яисә мөлкәткә хокукны тапшыруны яисә мөлкәти характердагы башка гамәлләр кылуны таләп иткән өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Куркытып алуны түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) *үз көчен югалтты;*

в) көч кулланып;

г) зур күләмдә —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Куркытып алуны түбәндәгечә кылган өчен:

а) оешкан төркем;

б) аеруча зур күләмдә мөлкәт алу максатларында;

в) зыян күрүченең сәламәтлегенә зур зыян салып;

г) *үз көчен югалтты* —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме

күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

164 статья. Аерым кыйммәткә ия предметларны урлау

1. Аерым тарихи, фәнни, сәнгати яисә мәдәни кыйммәткә ия предметларны яисә документларны урлаган өчен, урлау ысулына бәйсез рәвештә —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, алты елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем;

б) *үз көчен югалтты;*

в) әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән предметларның яисә документларның юкка чыгуына, бозылуына яисә җимерелүенә китереп —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, сигез елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

165 статья. Алдау яисә ышанычка керү юлы белән мөлкәти зарар китерү

1. Алдау яисә ышанычка керү юлы белән милекчегә яисә башка мөлкәт хуҗасына урламыйча гына мөлкәти зарар китергән өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә дүрт айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне алдан килешенгән затлар төркеме йә зур күләмдә кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) оешкан төркем;

б) аеруча зур зыян китереп;
в) *үз көчен югалтты* —
сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

166 статья. Урлау максатыннан башка гына законсыз рәвештә автомобильгә яисә башка транспорт чарасына хуҗа булу

1. Урлау максатыннан башка гына законсыз рәвештә автомобильгә яисә башка транспорт чарасына хуҗа булган (куып киткән) өчен —
йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.
2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:
а) алдан килешенгән затлар төркеме;
б) *үз көчен югалтты;*
в) кеше гомере яисә сәламәтлеге өчен куркыныч булмаган көч кулланып йә андый көчне куллану белән янап —
ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.
3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне оешкан төркем йә аеруча зур зыян китереп кылган өчен —
биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.
4. Әлеге статьяның беренче, икенче яисә өченче өлешләрендә каралган гамәлләрне кеше гомеренә яисә сәламәтлегенә куркыныч булган көч кулланып йә андый көч куллану белән янап кылган өчен —
алты елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

167 статья. Мөлкәтне аңлы рәвештә юкка чыгару яисә зарарлау

1. Чит мөлкәтне аңлы рәвештә юкка чыгарган яисә зарарлаган өчен, әгәр бу гамәлләр шактый зыян китерсә, —
кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр

мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне, хулиганлык максатыннан чыгып, ут төртү, шартлату юлы белән яисә гомумкуркыныч башка ысул белән йә саксызлык аркасында кеше үлеменә яки башка авыр нәтиҗәләргә китереп кылган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

168 статья. Саксызлык аркасында мөлкәтне юкка чыгару яисә зарарлау

Ут белән яисә аеруча куркыныч башка чыганаклар белән сак эш итмәү аркасында чит мөлкәтне зур күләмдә юкка чыгарган яисә зарарлаган өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә бер елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

22 бүлек. Икътисади эшчәнлек өлкәсендә җинаятьләр

169 статья. Законлы эшкуарлык эшчәнлегенә яисә башка эшчәнлеккә комачаулау

1. Индивидуаль эшкуарны яисә юридик затны дәүләт теркәвеннән законсыз баш тарткан йә аларны теркәүдән читләшкән өчен, аерым эшчәнлекне гамәлгә ашыруга махсус рөхсәт (лицензия) бирүдән законсыз баш тарткан йә аны бирүдән читләшкән өчен, оештыру-хокукый рәвешенә бәйле индивидуаль эшкуарның яисә юридик затның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләгән, шулай ук индивидуаль эшкуарның яисә юридик затның мөстәкыйльлеген законсыз чикләгән йә аларның эшчәнлегенә башкача законсыз тыкшынган өчен, әгәр бу гамәлләрне урындагы зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылса, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне закон көченә кергән суд актын бозып, шулай ук зур зыян китереп кылган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге бүлек статьяларында, 174, 174.1, 178, 185, 185.1, 193, 194, 198, 199 һәм 199.1 статьяларыннан тыш, зур күләмдә, зур зыян, зур күләмле керем йә бурыч дигәндә — ике йөз илле мең сумнан артып киткән, аеруча зур күләмле дигәндә бер миллион сум күләмендәге хак, зыян, керем йә бурыч танылa.

170 статья. Җир белән законсыз алыш-бирешләрне теркәү

Җир белән законсыз алыш-бирешләрне белә торып теркәгән, Дәүләт җир кадастрының исәпкә алу күрсәткечләрен бозган, шулай ук җир өчен түләү күләмнәрен аңлы рәвештә киметкән өчен, әгәр бу гамәлләрне урындагы зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып астыртын ният яисә башка шәхси кызыксынучанлык белән кылса, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза бирелә.

171 статья. Законсыз эшкуарлык эшчәнлеге

1. Теркәлүсез яисә теркәлү кагыйдәләрен бозып эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырган, шулай ук юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алучы органга белә торып ялган белешмәләр тапшырган өчен, йә эшкуарлык эшчәнлеген рөхсәтнең (лицензиянең) булуы мәҗбүри очракларда махсус рөхсәтсез (лицензиясез) яисә лицензия таләпләрен һәм шартларын бозып башкарган өчен, әгәр бу гамәл гражданнарга, оешмаларга яисә дәүләткә зур зыян китерсә йә зур күләмдә керем алуга китерсә, —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:
а) оешкан төркем;
б) аеруча зур күләмдә керем алып;
в) *үз көчен югалтты* —
йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. *Үз көчен югалтты.*

171.1 статья. Маркировкаланмаган товарларны һәм продукцияне җитештерү, юнәтү, саклау, ташу яисә сату

1. Ясалмалыктан якланган акциз җыемы маркалары белән, махсус маркалар яисә тәңгәллек тамгалары белән катгый рәвештә маркировкаланырга тиешле маркировкаланмаган товарларны һәм продукцияне сату максатларында зур күләмдә җитештергән, юнәткән, саклаган, ташыган яисә саткан өчен —
ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.
2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:
а) оешкан төркем;
б) *үз көчен югалтты*;
в) аеруча зур күләмдә —
йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ике елдан алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. *Үз көчен югалтты.*

172 статья. Законсыз банк эшчәнлеге

1. Банк эшчәнлеген (банк операцияләрен) теркәлүсез яисә рөхсәтнең (лицензиянең) булуы мәҗбүри очракларда махсус рөхсәтсез (лицензиясез) яисә лицензия таләпләрен һәм шартларын бозып башкарган өчен, әгәр бу гамәл гражданнарга, оеш-

маларга яисә дәүләткә зур зыян китерсә йә зур күләмдә керем алуга китерсә, —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) оешкан төркем;

б) аеруча зур күләмдә керем алып;

в) *үз көчен югалтты* —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

173 статья. Ялган эшкуарлык эшчәнлеге

Ялган эшкуарлык өчен, ягъни эшкуарлык яисә банк эшчәнлеген гамәлгә ашыру нияте булмаган, кредитлар алу, салымнардан азат итү, башка мөлкәти табыш алу максаты белән коммерция оешмасы төзегән яисә гражданнарга, оешмаларга яки дәүләткә зур зыян китерүче тыелган эшчәнлекне яшереп калган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

174 статья. Җинаять юлы белән башка затлар тарафыннан юнәтелгән акчаларны яисә башка мөлкәтне легальләштерү

1. Башка затлар тарафыннан җинаять юлы белән юнәтелгәнен белә торып, акчаларга яисә башка мөлкәткә (әлеге Кодексның 193, 194, 198, 199, 199.1 һәм 199.2 статьяларында каралган җинаятьләрдән тыш) законлы хуҗа булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү максатларында, алар белән финанс операцияләре һәм башка алыш-биреш гамәлләре кылган өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салу рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне зур күләмдә кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның икенче өлешендә каралган гамәлне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылса —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, дүрт елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Әлеге статьяның икенче яисә өченче өлешләрендә каралган гамәлләрне оешкан төркем кылса —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда, шулай ук әлеге Кодексның 174.1 статьясында зур күләмдә финанс операцияләре һәм башка акчалата алыш-биреш гамәлләре яисә бүтән мөлкәт белән алыш-биреш гамәлләре дигәндә бер миллионнан артыграк суммага башкарылган финанс операцияләре һәм башка акчалата алыш-биреш гамәлләре яисә бүтән мөлкәт белән алыш-биреш гамәлләре таныла.

174.1 статья. Зат тарафыннан җинаять кылып юнәтелгән акчаларны яисә бүтән мөлкәтне легальләштерү

1. Зат тарафыннан җинаять кылып юнәтелгән акчалар һәм башка мөлкәт белән (әлеге Кодексның 193, 194, 198, 199, 199.1 һәм 199.2 статьяларында каралган җинаятьләрдән тыш) финанс операцияләре һәм башка алыш-биреш гамәлләре кылынган өчен, йә шул акчаларны яисә бүтән мөлкәтне эшкуарлык яки башка икътисади эшчәнлекне гамәлгә ашыруда файдаланган өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салу рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне зур күләмдә кылган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, йөз мең сумга

кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның икенче өлешендә каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылса —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, дүрт елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Әлеге статьяның икенче яисә өченче өлешләрендә каралган гамәлләрне оешкан төркем кылган өчен –

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ун елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

175 статья. Җинаять юлы белән табылганын белә торып, мөлкәтне алу яисә сату

1. Җинаять юлы белән табылганын белә торып, мөлкәтне алдан вәгъдә итмичә алган яисә саткан өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) автомобильгә яисә башка мөлкәткә карата зур күләмдә;

в) *үз көчен югалтты* —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне оешкан төркем яисә зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

176 статья. Законсыз кредит алу

1. Индивидуаль эшкуар яисә оешма җитәкчесе банкка яисә башка кредиторга индивидуаль эшкуарның яки оешманың хуҗалык хәле йә финанс хәле турында күрәләтә ялган белешмәләр бирү юлы белән кредит алган йә кредит алуның ташламалы шартларыннан файдаланган өчен, әгәр бу гамәл зур зыян китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Максатчан дәүләт кредитын законсыз алган, шулай ук аны турыдан-туры билгеләнеше буенча файдаланмаган өчен, әгәр бу гамәлләр гражданнарга, оешмаларга яисә дәүләткә зур зыян китерсә, —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елдан биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

177 статья. Кредит бурычын түләүдән явыз ният белән читләшү

Оешма җитәкчесе яисә граждан тиешле суд акты закон көченә кергәннән соң зур күләмдә кредит бурычын түләүдән яисә кыйммәтле кәгазьләр түләүдән явыз ният белән читләшкән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. *Үз көчен югалтты.*

178 статья. Конкуренцияне булдырмау, чикләү яисә бетерү

1. Монополия куйган югары яисә монополия куйган түбән бәяләрне билгеләү яисә хуплау, базарны бүлешү, базарга үтеп керүне чикләү, андагы башка икътисади эшчәнлек субъектларын бетерү, бердәм бәяләрне билгеләү яисә хуплау юлы белән конкуренцияне булдырмаган, чикләгән яисә бетергән өчен, әгәр бу гамәлләр зур зыян китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга

алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып йә алдан килешенгән затлар төркеме кылса —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне көч кулланып яисә аны куллану белән янап, шулай ук чит мөлкәтне юкка чыгарып яисә зарарлап, йә, куркытып алу билгеләреннән башка, аны юкка чыгару яисә зарарлау белән янап кылган өчен, йә шуларны оешкан төркем кылган өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда зур зыян дип бер миллион сумнан артыграк күләмдәге зыян танылa.

179 статья. Алыш-биреш гамәлләрен кылуга яисә аны кылудан баш тартуга мәҗбүр итү

1. Көч куллануны, чит мөлкәтне юкка чыгаруны яисә зарарлауны, шулай ук зыян күрүченең яисә аның якыннарының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә җитди зыян китерергә мөмкин булган белешмәләр таратуны янап, куркытып алу билгеләреннән башка, алыш-биреш гамәлләрен кылуга яисә аны кылудан баш тартуга мәҗбүр иткән өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) *үз көчен югалтты;*

б) көч кулланып;

в) оешкан төркем —

биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

180 статья. Товар тамгасын законсыз файдалану

1. Чит товар тамгасыннан, хезмәт күрсәтү тамгасыннан, товар җитештергән урынның исеменнән яисә бер төрдәге товарлар өчен шуларга охшаш билгеләрдән законсыз файдалан-

ган өчен, әгәр бу гамәл берничә мәртәбә башкарылган булса яисә зур зыян китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

2. Россия Федерациясендә теркәлмәгән товар тамгасына карата кисәтү маркировкасыннан яисә товар җитештерелгән урын исеменнән законсыз файдаланган өчен, әгәр бу гамәл берничә мәртәбә башкарылган булса яисә зур зыян китерсә, —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне алдан килешенгән оешкан төркем кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

181 статья. Дәүләт пробалары келәймәләрен әзерләү һәм файдалану кагыйдәләрен бозу

1. Дәүләт пробасы келәймәсен астыртын ният белән яисә башка шәхси кызыксынучанлык күрсәтеп санкциясез әзерләгән, саткан яисә файдаланган, шулай ук ялган үрнәкләрен әзерләгән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне оешкан төркем кылган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

182 статья. *Үз көчен югалтты.*

183 статья. Коммерция, салым яисә банк серен тәшкил итүче белешмәләрне законсыз алу һәм фаш итү

1. Документлар урлау, сатып алу яисә янау юлы белән, шулай ук башка законсыз ысул белән коммерция, салым яисә банк серен тәшкил итүче белешмәләрне җыйган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер айдан алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Коммерция, салым яисә банк серен тәшкил итүче белешмәләрне, аларның хуҗасының ризалыгыннан башка, әлеге сер ышандырылган яисә аңа хезмәте яисә эше буенча мәгълүм булган зат законсыз фаш иткән яисә файдаланган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Шул ук гамәлләрне зур зыян китереп яисә астыртын кызыксынучанлык күрсәтеп кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Әлеге статьяның икенче яисә өченче өлешләрендә каралган гамәлләр авыр нәтиҗәләргә китерсә —

ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

184 статья. Һөнәри спорт ярышларында һәм тамашалы коммерция конкурсларында катнашучыларны һәм оештыручыларны сатып алу

1. Һөнәри спорт ярышларындагы спортчыларны, спорт судьяларын, тренерларны, командалар җитәкчеләрен һәм башка катнашучыларны яисә оештыручыларны, шулай ук тамашалы коммерция конкурсларын оештыручыларны һәм жюри әгъзаларын шул ярышларның яисә конкурсларның нәтиҗәләренә тәэсир итү максатларында сатып алган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айдан бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне оешкан төркем кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Спортчылар күрсәтелгән ярышларның нәтиҗәләренә

йогынты ясау максатларында тапшырылган акчаларны, кыйммәтле кәгазьләрне яисә башка мөлкәтне законсыз алган өчен, шулай ук аларга шул ук максатларда бирелгән мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүдән законсыз файдаланган өчен —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

4. Спорт судьялары, тренерлар, команда җитәкчеләре һәм һөнәри спорт ярышларында башка катнашучылар яисә оештыручылар, шулай ук тамашалы коммерция конкурсларын оештыручылар яисә аларның жюри әгъзалары әлеге статьяның өченче өлешендә күрсәтелгән максатларда акчалар, кыйммәтле кәгазьләр яисә башка мөлкәтне законсыз алган өчен, мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләрдән законсыз файдаланган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

185 статья. Кыйммәтле кәгазьләрне эмиссияләгәндә явыз ният белән файдалану

1. Кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясе проспектына күрәләтә дөрес булмаган мәгълүмат керткән, эмиссия проспектында күрәләтә дөрес булмаган мәгълүматны яисә кыйммәтле кәгазьләр чыгару йомгаклары турындагы хисапны раслаган, шулай ук дәүләт теркәве узмаган эмиссияле кыйммәтле кәгазьләрне урнаштырган өчен, әгәр бу гамәлләр гражданнарга, оешмаларга яисә дәүләткә зур зыян китерсә, —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем кылган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге Кодексның 185 һәм 185.1 статьяларында каралган бер миллион сумнан артыграк зыян зур зыян дип танылa.

185.1 статья. Инвесторга яисә контроль органына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән кыйммәтле кәгазьләр турында мәгълүмат бирүдән явыз ният белән читләшү

Эмитент турында, аның финанс-хуҗалык эшчәнлеге һәм кыйммәтле кәгазьләр турында, кыйммәтле кәгазьләр белән алыш-биреш итүләр һәм бүтән гамәлләр турында белешмәләрне үз эченә алган мәгълүмат белән инвесторны яисә контроль органын тәэмин итәргә тиешле зат күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән явызларча читләшкән йә аны белә торып тулысынча бирмәгән яисә ялган мәгълүмат биргән өчен, әгәр бу гамәлләр гражданнарга, оешмаларга яки дәүләткә зур зыян китерсә, —

өч мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

186 статья. Ялган акчалар яисә кыйммәтле кәгазьләр әзерләү яки сату

1. Россия Федерациясе Үзәк банкының ялган банк билетларын, металл акчаларын, дәүләтнең кыйммәтле кәгазьләрен яисә Россия Федерациясе валютасында йә чит ил валютасында бүтән кыйммәтле кәгазьләрне яки чит ил валютасында кыйммәтле кәгазьләрне сату максатларында әзерләгән яки саткан өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Зур күләмдә кылган шул ук гамәлләр өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елдан уникe елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче статьяларында каралган гамәлләрне оешкан төркем кылган өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, сигез елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

187 статья. Ялган кредит йә исәп-хисап карталарын һәм бүтән түләү документларын әзерләү яисә сату

1. Ялган кредит йә исәп-хисап карталарын, шулай ук кыйммәтле кәгазьләр булып тормаган бүтән түләү документларын сату максатларында әзерләгән яисә саткан өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, ике елдан алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ул гамәлләрне оешкан төркем кылган өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, дүрт елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

188 статья. Контрабанда

1. Контрабанда, ягъни Россия Федерациясе таможня чиге аша, әлеге статьяның икенче өлешендә күрсәтелгәннәрдән тыш, таможня контроленнән башка яисә аннан яшерен рәвештә йә таможня тәңгәллеге документларыннан яки чараларыннан ялган юллар белән файдаланып, йә декларация тутырылмауга яки тиешенчә тутырылмауга бәйле товарларны яисә бүтән предметларны зур күләмдә үткәргән өчен —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Россия Федерациясе таможня чиге аша наркотик чаралар, психотроп, көчле тәэсир итә торган, агулы, агулаучы, шартлаткыч, радиоактив матдәләр, радиация чыганаклары, атомтөш материаллары, утлы ату коралы, шартлату җайланмалары, хәрби кирәк-яраклар, күпләп юк итү кораллары, аны ташу чаралары, башка коралларны, башка хәрби техниканы, шулай ук күпләп юк итү коралын, аны ташу чараларын, башка коралларны, башка хәрби техниканы төзегәндә файдаланыла торган һәм Россия Федерациясе таможня чиге аша үткәрүнең махсус кагыйдәләре билгеләнгән материаллар һәм җайланмалар, Россия Федерациясе таможня чиге аша үткәрүнең махсус кагыйдәләре билгеләнгән стратегик яктан әһәмиятле чимал товарларын яисә мәдәни хәзинәләрне үткәргән өчен, әгәр бу гамәл таможня контроленнән башка яисә аннан яшерен рәвештә, йә таможня тәңгәллеге документларыннан яисә таможня чараларыннан ялган юллар белән файдаланып башкарылса, йә декларация тутырылмауга яки тиешенчә тутырылмауга бәйле булса, —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, өч елдан җиде елга кадәр ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) *үз көчен югалтты;*

б) урындагы зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып;

в) таможня контролен башкарган затка карата көч кулланып —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Әлеге статьяның беренче, икенче яисә өченче статьяларында каралган гамәлләрне оешкан төркем кылган өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

189 статья. Күпләп юк итү коралы ясауда, коралլануда һәм хәрби техника ясауда кулланылырга мөмкин булган чималны, материалларны, җайланманы, технологияләрне, фәнни-техник мәгълүматны читкә законсыз чыгару яисә тапшыру, эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) законсыз башкару

1. Тышкы икътисади эшчәнлекне гамәлгә ашыру хокукына ия зат чит ил оешмасына яисә аның вәкиленә чималны, материалларны, җайланманы, технологияләрне, фәнни-техник мәгълүматны читкә законсыз чыгарган яисә тапшырган өчен, әлеге зат эшләрне чит ил оешмасына яисә аның вәкиленә законсыз башкарган йә коралларны һәм хәрби техниканы ясаганда файдаланырга мөмкин булган һәм экспорт контроле билгеләнгән хезмәтләрне күрсәтелгән зат белә торып законсыз күрсәткән өчен (әлеге Кодексның 188 һәм 275 статьяларында каралган җинаять билгеләре булмаганда) —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннары биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне алдан килешенгән затлар төркеме кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү хокукыннан яи-

сә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, биш елга кадәр irектән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган, оешкан төркем йә тышкы икътисади эшчәнлек алып бару хокукы бирелгән зат белә торып күпләп юк итү коралы ясаганда, аны ташу чараларын төзегәндә файдалану ихтималы булган һәм экспорт контроле билгеләнгән чималга, материалларга, җайланмага, технологияләргә, фәнни-техник мәгълүматка, эшләргә (хезмәт күрсәтүләргә) карата кылган гамәлләр өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда тышкы икътисади эшчәнлек башкару хокукы бирелгән зат дип Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән һәм Россия Федерациясе территориясендә даими урнашкан юридик зат җитәкчесе, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә даими яшәү урыны булган һәм Россия Федерациясе территориясендә индивидуаль эшкуар буларак теркәлгән физик зат аңлашыла.

190 статья. Россия Федерациясе территориясенә Россия Федерациясе һәм чит ил халыкларының сәнгати, тарихи һәм археологик казаныш предметларын кире кайтармау

Россия Федерациясе халыкларының һәм чит ил халыкларының Россия Федерациясеннән читкә чыгарылган сәнгати, тарихи һәм археологик казаныш предметларын Россия Федерациясе территориясенә билгеләнгән вакытта кире кайтармаган өчен, әгәр мондый кайтару Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри булып торса, —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яисә бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

191 статья. Кыйммәтле металларның, табигый кыйммәтле ташларның яисә энҗенең законсыз әйләнеше

1. Кыйммәтле металларга, табигый кыйммәтле ташларга йә энҗегә бәйле алыш-бирешләрне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән кагыйдәләрне бозып башкарган, шулай ук кыйммәтле металларны, табигый кыйммәтле ташларны яисә энҗене, ювелир, көнкүреш әйберләреннән һәм мондый әйберләрнең ватыкларыннан тыш, теләсә нинди рәвештә, халәттә законсыз саклаган, ташыган яисә җибәргән өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр штраф яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) *үз көчен югалтты;*

б) зур күләмдә;

в) оешкан төркем, алдан килешенгән затлар төркеме —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. *Үз көчен югалтты.*

192 статья. Дәүләткә кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар тапшыру кагыйдәләрен бозу

Җир астыннан чыгарылган, икенчел чималдан алынган, шулай ук чыгарылган яисә табылган кыйммәтле металларны яисә кыйммәтле ташларны аффинажга мәҗбүри тапшырудан яисә дәүләткә мәҗбүри сатудан читләшкән өчен, әгәр бу гамәл зур күләмдә башкарылса, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. *Үз көчен югалтты.*

193 статья. Чит ил валютасын чит илдән кире кайтармау

Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясенең вәкаләтле банк счетларына һичшиксез күчерелергә тиешле чит ил валютасын оешма җитәкчесе зур күләмдә чит илдән кире кайтармаган өчен —

өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда каралган гамәл, әгәр кире кайтарылмаган сумма чит ил валютасында биш миллион сумнан артса, зур күләмдә кылган гамәл дип таныла.

194 статья. Оешмадан яисә физик заттан алына торган таможня түләүләрен түләүдән читләшү

1. Оешмадан яисә физик заттан зур күләмдә алына торган таможня түләүләрен түләүдән читләшкән өчен —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт ха-

кы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) *үз көчен югалтты;*

в) *үз көчен югалтты;*

г) аеруча зур күләмдә —

йөз меңнән биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым вазифалар биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яки аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Түләнмәгән таможня түләүләре суммасы биш йөз мең сумнан артып китсә, таможня түләүләрен зур күләмдә түләүдән читләшү дип, ә бер миллион биш йөз мең сумнан артып китсә, аеруча зур күләмдә түләүдән читләшү дип танылa.

195 статья. Бөлгенлек вакытында кылган законсыз гамәлләр

1. Мөлкәтне, мөлкәти хокукларны яисә мөлкәти йөкләмәләрне, мөлкәт турындагы, аның күләме, урнашкан урыны турындагы белешмәләрне йә мөлкәт турындагы, мөлкәти хокуклар яисә мөлкәти йөкләмәләр турындагы башка мәгълүматны яшергән, мөлкәтне бүтән затларга биләүгә тапшырган, мөлкәтне аерып алган яисә юкка чыгарган, шулай ук юридик затның яисә индивидуаль эшкуарның икътисади эшчәнлеген чагылдыра торган бухгалтерлык һәм башка исәпләү документларын яшереп калган, юкка чыгарган, фальсификацияләгән өчен, әгәр әлеге гамәлләр бөлгенлек билгеләре булганда кылынса һәм зур зыян салса, —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яки хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып яисә аннан башка, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Юридик зат җитәкчесе яисә аның гамәлгә куючысы (катнашучы) йә индивидуаль эшкуар бүтән кредиторларга белә торып зыян салып, аерым кредиторларның мөлкәти таләпләрен бурычлы юридик зат мөлкәте исәбеннән законсыз канәгатьләндергән өчен, әгәр бу гамәл бөлгенлек билгеләре булганда кылынса һәм зур зыян салса, —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә ике айдан дүрт айга кадәр кулга алу, йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем

ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып яисә аннан башка, бер елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Арбитраж идарәче йә кредит оешмасының вакытлы администрациясе эшчәнлегенә законсыз рәвештә каршылык күрсәткән өчен, шул исәптән юридик зат һәм кредит оешмасы җитәкчесе вазифалары арбитраж идарәчегә яисә кредит оешмасының вакытлы администрациясе җитәкчесенә йөкләнгән очракларда арбитраж идарәчегә йә кредит оешмасының вакытлы администрациясенә үзләренә йөкләнгән вазифаларны үтәү өчен кирәкле документларны яисә мөлкәтне тапшырудан читләшкән яисә баш тарткан өчен, әгәр бу гамәлләр (гамәл кылмау) зур зыян салса, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

196 статья. Алдан ниятләп бөлгенлеккә төшү

Алдан ниятләп бөлгенлеккә төшкән, ягъни юридик зат җитәкчесе яисә гамәлгә куючысы (катнашучы) йә индивидуаль эшкуар акча йөкләмәләре буенча кредиторларның таләпләрен юридик зат җитәкчесенең яисә гамәлгә куючысының йә индивидуаль эшкуарның тулысынча канәгатьләндерү һәм мәҗбүри түләүләрне гамәлгә ашыру йөкләмәсен белә торып үти алмаслык итеп гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) өчен, әгәр бу гамәлләр (гамәл кылмау) зур зыян салса, —

ике йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, ике йөз мең сумга кадәр яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып яисә аннан башка, алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

197 статья. Фиктив бөлгенлек

Фиктив бөлгенлек, ягъни юридик зат җитәкчесе яисә гамәлгә куючысы (катнашучы) әлеге юридик затның бөлгенлеккә төшүе турында, шулай ук индивидуаль эшкуар үзенең бөлгенлеккә төшүе турында белә торып ялган гавами белдерү ясаган өчен, әгәр бу гамәл зур зыян салса, —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт ха-

кы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып яисә аннан башка, алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

198 статья. Физик заттан салымнар һәм (яисә) җыемнар түләүдән читләшү

1. Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә мәҗбүри тапшырылырга тиешле салым декларациясен яисә башка документларны тапшырмау юлы белән йә салым декларациясенә яисә шундый документларга белә торып ялган белешмәләр кертү юлы белән физик зат зур күләмле салымнарын һәм (яисә) җыемнарын түләүдән читләшкән өчен —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки башка кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә бер елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шушы ук гамәлләрне аеруча зур күләмдә кылган өчен —

ике йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда эре күләмдә дигәндә, өч финанс елы буена салымнар һәм (яисә) җыемнарның рәттән йөз мең сумнан артык булган суммасы аңлашыла, монда салымнарның һәм (яисә) җыемнарның түләнмәгән өлеше түләнергә тиешле салымнарның һәм (яисә) җыемнарның 10 процентыннан артык булуы йә өч йөз мең сумнан артык булуы шарт, ә аеруча зур күләмдә дигәндә, өч финанс елы буе рәттән биш йөз мең сумнан артык сумма аңлашыла, монда салымнарның һәм (яисә) җыемнарның түләнмәгән өлеше түләнергә тиешле салымнарның һәм (яисә) җыемнарның 20 процентыннан артык булуы йә бер миллион биш йөз мең сумнан артык булуы шарт.

199 статья. Оешмалардан салымнар һәм (яисә) җыемнар түләүдән читләшү

1. Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә мәҗбүри тапшырылырга тиешле салым декларациясен яисә башка документларны тапшырмау юлы белән йә салым декларациясенә яисә шундый документларга белә торып ялган белешмәләр кертү юлы белән оешмадан

зур күләмле салымнарын һәм (яисә) җыемнарын түләүдән читләшкән өчен —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки башка кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр irектән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне түбәндәгечә кылган өчен —

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) аеруча зур күләмдә —

ике йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Бу Кодексның әлеге статьясында, шулай ук 199.1 статьясында эре күләмдә дигәндә өч финанс елы буена салымнар һәм (яисә) җыемнарның рәттән биш йөз мең сумнан артык булган суммасы аңлашыла, монда салымнарның һәм (яисә) җыемнарның түләнмәгән өлеше түләнергә тиешле салымнарның һәм (яисә) җыемнарның 10 процентыннан артык булуы йә бер миллион биш йөз мең сумнан артык булуы шарт, ә аеруча зур күләмдә дигәндә, өч финанс елы буе рәттән ике миллион биш йөз мең сумнан артык сумма аңлашыла, монда салымнарның һәм (яисә) җыемнарның түләнмәгән өлеше түләнергә тиешле салымнарның һәм (яисә) җыемнарның 20 процентыннан артык булуы йә җиде миллион биш йөз мең сумнан артык булуы шарт.

199.1 статья. Салым агенты вазифаларын үтәмәү

1. Шәхси мәнфәгатьләрдә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салым түләүчеләрдән тотылырга һәм тиешле бюджетка (бюджеттан тыш фондка) күчерелергә тиешле салымнар һәм (яисә) җыемнарны зур күләмдә түләү, тоту яисә күчерү буенча салым агенты вазифаларын үтәмәгән өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне аеруча зур күләмдә кылган өчен —

ике йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елдан биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

199.2 статья. Оешманың яисә индивидуаль эшкуарның салымнар һәм (яисә) җыемнар түләнергә тиешле акчаларын йә мөлкәтен яшереп калу

Салымнар һәм (яисә) җыемнар турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә оешма милекчесе яисә җитәкчесе йә әлеге оешмада идарә вазифаларын башкаручы зат яки индивидуаль эшкуар салымнар һәм (яисә) җыемнар буенча недоимка алынырга тиешле акчаларны йә мөлкәтне зур күләмдә яшереп калган өчен —

ике йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

200 статья. *Үз көчен югалтты.*

23 бүлек. Коммерция оешмаларында һәм башка оешмаларда хезмәт мәнфәгатьләренә каршы җинаятьләр

201 статья. Вәкаләтләрдән явыз нияттә файдалану

1. Коммерция оешмаларында яисә башка оешмада идарә вазифаларын башкаручы зат үз вәкаләтләрен әлеге оешманың законлы мәнфәгатьләренә каршы һәм үзе өчен яисә башка затлар өчен файда һәм өстенлекләр күрү йә башка затларга зыян китерү максатларында файдаланган өчен, әгәр бу гамәл гражданнарның яисә оешмаларның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә йә җәмгыятьнең яисә дәүләтнең закон белән саклана торган мәнфәгатьләренә сизелерлек зыян китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр

төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәл өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмәләр. 1. Бу Кодексның әлеге бүлек статьяларында, шулай ук 196 статьясында коммерция оешмаларында яисә башка оешмада идарә итү вазифаларын башкаручы зат дигәндә милек рәвешләренә карамастан коммерция оешмасында, шулай ук дәүләт органы, җирле үзидарә органы, дәүләт яисә муниципаль учреждение булып тормаган коммерциягә карамаган оешмада оештыру-боеру яисә административ-хуҗалык вазифаларын башкаруга даими, вакытлыча йә махсус вәкаләт бирелгән зат аңлашыла.

2. Әгәр әлеге статьяда йә бу бүлекнең бүтән статьяларында каралган гамәлләр дәүләт яки муниципаль предприятие булып тормаган коммерция оешмасы мәнфәгатьләренә генә зыян китерсә, җинаять эше буенча эзәрлекләү әлеге оешма гаризасы буенча яисә аның ризалыгы белән гамәлгә ашырыла.

3. Әгәр әлеге статьяда йә бу бүлекнең бүтән статьяларында каралган гамәлләр башка оешмалар, шулай ук гражданнар, җәмгыять яисә дәүләт мәнфәгатьләренә зыян китерсә, җинаять эше буенча эзәрлекләү гомуми нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

202 статья. Хосусый нотариуслар һәм аудиторлар тарафыннан вәкаләтләрне явыз ниуттә файдалану

1. Хосусый нотариус яисә хосусый аудитор вәкаләтләреннән үз эшчәнлеге бурычларына каршы килеп һәм үзе яисә башка затлар өчен файда һәм өстенлекләр күрү максатларында йә башка затларга зыян китерү максатында файдаланган өчен, әгәр бу гамәл гражданнарның яисә оешмаларның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә йә җәмгыятьнең яисә дәүләтнең закон нигезендә саклана торган мәнфәгатьләренә сизелерлек зыян китерсә, —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Әлеге гамәлләрне белә торып балигъ булмаган яисә хокукый сәләтсез затка карата кылган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

203 статья. Детектив хезмәтләр яисә хосусый сак хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен арттырып кулланулары

1. Детектив хезмәт яисә хосусый сак җитәкчесе яисә хезмәткәре үзләренә лицензия нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз эшчәнлеге бурычларына каршы килеп арттырып кулланган өчен, әгәр әлеге гамәлне көч кулланып яисә көч куллану белән янап кылса, —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәл өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

204 статья. Коммерциячел сатып алу

1. Коммерция оешмасында яисә бүтән оешмада идарә итү вазифаларын башкаручы затка акча, кыйммәтле кәгазьләр, бүтән мөлкәтне законсыз тапшырган, шулай ук әлеге затның били торган хезмәт вазифасына бәйле рәвештә бирүче мәнфәгатьләрендә кылган гамәлләр (гамәл кылмаулар) өчен мөлкәти характердагы законсыз хезмәтләр күрсәткән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәрге чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә ике елга кадәр ирекне чикләү, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Коммерция оешмасында яисә башка оешмада идарә итү вазифаларын башкаручы зат акча, кыйммәтле кәгазьләр, бүтән мөлкәтне законсыз алган, шулай ук әлеге затның били торган хезмәт урынына бәйле рәвештә бирүче мәнфәгатьләрендә гамәлләр кылган (гамәл кылмаулар) өчен мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләрдән законсыз файдаланган өчен —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Әлеге статьяның өченче өлешендә каралган гамәлләрне:

а) алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем кылса;

б) *үз көчен югалтты;*

в) куркытып алуга бәйле булса —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне кылган зат, аңа карата куркытып алу алымы кулланылса яисә бу зат акчага сатылу турында җинаять эше кузгатырга хокуклы органга ихтыяри хәбәр итсә, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

IX кисәк. Җәмәгать иминлегенә һәм җәмәгать тәртибенә каршы җинаятьләр

24 бүлек. Җәмәгать иминлегенә каршы җинаятьләр

205 статья. Террорчылык

1. Террорчылык, ягъни кешеләр өчен үлем куркынычы тудыра торган шартлау, яндыру һәм башка гамәлләр кылган, мөлкәткә сизелерлек зыян йә бүтән иҗтимагый куркыныч зыян китергән өчен, әгәр әлеге гамәлләр җәмәгать иминлеген бозу, халыкны куркыту йә хакимият органнары тарафыннан карарлар кабул итүгә йогынты ясауга китерсә, шулай ук әлеге гамәлләрне шул ук максатларда кылу куркынычы янаса, —

сигез елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:
а) алдан килешенгән затлар төркеме;
б) *үз көчен югалтты;*
в) утлы корал кулланып —
ун елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләр өчен, әгәр аларны оешкан төркем кылса йә саксызлык аркасында кеше үлеменә яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә, шулай ук атом энергиясеннән файдалану объектларына йә атом-төш материалларыннан, радиоактив матдәләрдән яисә радиоактив нурланыш чыганакларыннан файдалану объектларына янауга бәйле булса, —
унбиш елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү яисә гомерлеккә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Террорчылык актын әзерләүдә катнашкан зат, әгәр хакимият органнарын вакытында кисәтү аша яисә бүтән ысул белән террорчылык актын булдырмый калуга ярдәм итсә һәм әлеге зат гамәлләрендә бүтән җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

205.1 статья. Террорчылык характерындагы җинаятьләр кылуга җәлеп итү яисә аларны кылуга башкача булышу

1. Затны әлеге Кодексның 205, 206, 208, 211, 277 һәм 360 статьяларында каралган җинаятьләрне кылуга җәлеп иткән яисә затны террор оешмасы эшчәнлегендә катнашуга этәргән, затны күрсәтелгән җинаятьләрне кылу максатларында коралландырган йә өйрәткән, шулай ук террорчылык актын йә террор оешмасын финанслаган өчен —
дүрт елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылган өчен —
бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда каралган җинаятьне кылган зат, әгәр хакимият органнарын ихтыяри рәвештә вакытында кисәтү аша яисә бүтән ысул белән террорчылык актын булдырмый калуга йә әлеге статьяда күрсәтелгән террор характерындагы җинаятькә чик куюга ярдәм итсә һәм әлеге зат гамәлләрендә бүтән җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

206 статья. Тотык алу

1. Дәүләтне, оешманы яисә гражданны нинди дә булса гамәл кылырга яисә тотыкны азат итү шарты буларак нинди дә булса гамәл кылудан тоткарларга мәҗбүр итү максатларында затны тотык сыйфатында алган яисә тотып торган өчен —

биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) *үз көчен югалтты;*

в) гомер һәм сәламәтлек өчен куркыныч көч кулланып;

г) корал яисә корал буларак файдаланыла торган предметлар кулланып;

д) белә торып балигъ булмаган затка карата;

е) гаепле зат белә торып йөкле булган хатын-кызга карата;

ж) ике яисә аннан күбрәк затка карата;

з) астырын ният максатында яисә ялланып —

алты елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешендә каралган гамәлләр өчен, әгәр аларны оешкан төркем кылса йә саксызлык аркасында кеше үлеменә яисә бүтән авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

сигез елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Ихтыяри рәвештә яисә хакимият таләбе буенча тотыкны азат иткән зат, әгәр ул кылган гамәлләрдә бүтән җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

207 статья. Террорчылык акты турында белә торып ялган хәбәр итү

Әзерләнә торган шартлату, яндыру яисә кешеләргә үлем куркынычы, мөлкәткә сизелерлек зыян салу йә башка җәмгыяви куркыныч зыян салуга китерә торган гамәлләр турында белә торып ялган хәбәр иткән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

208 статья. Законсыз коралды формирование оештыру яисә анда катнашу

1. Федераль законда каралмаган коралды формирование (бер-

ләшмә, отряд, дружина яисә башка төркем) төзегән өчен, шулай ук мондый формирование белән җитәкчелек иткән өчен —

ике елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Федераль законда каралмаган хәрби формированиедә катнашкан өчен —

өч елга кадәр иректән мәхрүм итү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Законсыз хәрби формированиедә катнашуын ихтыяри рәвештә туктаткан һәм коралын тапшырган зат, әгәр ул кылган гамәлләрдә бүтән җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

209 статья. Бандитчылык

1. Гражданнарга яисә оешмаларга һөҗүм итү максатларында коралланган тотрыклы төркем (банда) төзегән өчен, шулай ук шундый төркемгә (бандага) җитәкчелек иткән өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ун елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Коралланган тотрыклы төркемдә (бандада) яисә алар башкарган һөҗүмнәрдә катнашкан өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, сигез елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне зат үзенең хезмәт вазифасыннан файдаланып кылган өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, унике елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

210 статья. Җинаятьчел җәмгыять (җинаятьчел оешма) оештыру

1. Авыр яисә аеруча авыр җинаятьләр кылу өчен җинаятьчел җәмгыять (җинаятьчел оешма) төзегән, шулай ук мондый җәмгыятькә (оешмага) яисә аңа керә торган структур бүлекчәләргә җитәкчелек иткән өчен, шулай ук авыр яисә аеруча авыр җинаятьләр кылу өчен планнар кору һәм шартлар булдыру максатларында оешкан төркемнәрнең оештыручылары, җитәкчеләре яисә бүтән вәкилләре берләшмәсен төзегән өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Җинаятьчел җәмгыятьтә (җинаятьчел оешмада) йә оешкан төркемнәрнең оештыручылары, җитәкчеләре яисә башка вәкилләре берләшмәсендә катнашкан өчен —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, өч елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне зат үзенең хезмәт вазифасыннан файдаланып кылган өчен —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ун елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Җинаятьчел җәмгыятьтә (җинаятьчел оешмада) яисә аңа керә торган структур бүлекчәдә йә оешкан төркемнәрнең оештыручылары, җитәкчеләре яки башка вәкилләре берләшмәсендә катнашуын ихтыяри рәвештә туктаткан һәм әлеге җинаятьне ачуга яисә булдырмый калуга актив ярдәм иткән зат, әгәр ул кылган гамәлләрдә башка җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

211 статья. Һава яисә су транспорты судносын йә тимер юл хәрәкәте составын куып алып китү

1. Һава яисә су транспорты судносын йә тимер юл хәрәкәте составын куып алып киткән өчен, шулай ук мондый судноны яисә составны куып алып китү максатларында тоткан өчен —

дүрт елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) *үз көчен югалтты;*

в) гомер яисә сәламәтлек өчен куркыныч көч кулланып йә мондый көч куллану белән янап;

г) корал яисә корал сыйфатында файдаланыла торган предметлар кулланып —

җиде елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләр өчен, әгәр аларны оешкан төркем кылса йә

саксызлык аркасында алар кеше үлеменә яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

сигез елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

212 статья. Массакүләм тәртипсезлекләр

1. Көч куллану, җимерү, яндыру, мөлкәтне юкка чыгару юлы белән, утлы корал, шартлаткыч матдәләр яисә шартлаткыч җайланмалар кулланып, шулай ук хакимият вәкиленә коралны каршылык күрсәтеп массакүләм тәртипсезлекләр оештырган өчен —

дүрт елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган массакүләм тәртипсезлекләрдә катнашкан өчен —

өч елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Хакимият вәкилләренең законлы таләпләренә актив буйсынмауга һәм массакүләм тәртипсезлекләргә өндәгән өчен, шулай ук гражданнарга карата көч куллануга өндәгән өчен —

ике елга кадәр ирекне чикләү, йә ике айдан дүрт айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

213 статья. Хулиганлык

1. Хулиганлык, ягъни җәмгыятькә ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәтә торган, корал яисә корал буларак файдаланыла торган предметларны кулланып, җәмәгать тәртибен тупас бозган өчен —

йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем йә хакимият вәкиленә яки җәмәгать тәртибен саклау вазифаларын башкаручы яисә җәмәгать тәртибен бозуны булдырмаучы затка каршылык күрсәтүгә бәйле рәвештә кылган өчен —

җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

214 статья. Вандализм

Вандализм, ягъни биналарны яисә бүтән корылмаларны мәсхәрәләгән, җәмәгать транспортында яисә башка җәмәгать урыннарында мөлкәт бозган өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән зат-

ның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айдан бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

215 статья. Атом энергетикасы объектларында куркынычсызлык кагыйдәләрен бозу

1. Атом энергетикасы объектларын урнаштырганда, проектлаганда, төзегәндә һәм эксплуатацияләгәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр ул кеше үлеменә яисә әйләнә-тирә мохитне радиоактив зарарлауга китерерлек булса, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр irектән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне саксызлык аркасында кеше сәламәтлегенә зур зыян салуга яисә кеше үлеменә йә әйләнә-тирә мохитне радиоактив зарарлауга китереп кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Саксызлык аркасында ике яисә аннан да күбрәк затның үлеменә китергән гамәл кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

215.1 статья. Электр энергиясен бирүне туктату яисә чикләү йә башка яшәеш чыганакларын өзү

1. Урындагы затлар тарафыннан, шулай ук коммерция яисә бүтән оешмада идарә итү вазифаларын башкаручы зат тарафыннан кулланучыларга электр энергиясен бирүне законсыз туктаткан яисә чикләгән йә башка яшәеш чыганакларын өзгән өчен, әгәр ул саксызлык аркасында зур зыян, сәламәтлеккә зур зыян салуга яисә башка төрле авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәлләр кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

215.2 статья. Яшәеш объектларын яраксыз хәлгә җиткерү

1. Энергетика, электр элемтәсе, торак һәм коммуналь хуҗалыгы объектларын яисә башка яшәеш объектларын җимергән, зарарлаган яисә бүтән ысуллар белән файдалану өчен яраксыз хәлгә җиткергән өчен, әгәр гамәлләр астыртын ният яки хулиганлык максатларында кылынса, —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә бер елдан өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шундый ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) *үз көчен югалтты;*

в) зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, өч елдан биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне саксызлык аркасында кеше үлеменә китереп кылган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

216 статья. Тау, төзелеш эшләрен яисә башка эшләрне алып барганда куркынычсызлык кагыйдәләрен бозу

1. Тау, төзелеш эшләрен яисә башка эшләрне алып барганда куркынычсызлык кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр алар саксызлык аркасында кеше сәламәтлеген нык какшатуга йә зур зыян салуга китерсә, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр иректе чикләү йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлне саксызлык аркасында ике яисә аннан да күбрәк затның үлеменә китереп кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, җиде елга кадәр ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге бүлек статьяларында зур зыян дип биш йөз мең сумнан артык суммадагы зыян таныла.

217 статья. Шартлау куркынычы булган объектларда куркынычсызлык кагыйдәләрен бозу

1. Шартлау куркынычы булган объектларда яисә шартлау куркынычы булган цехларда куркынычсызлык кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр ул кеше үлеменә йә зур зыян салуга китерсә, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч елга кадәр иректе чикләү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр иректе чикләү йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлне саксызлык аркасында ике яисә аннан да күбрәк затның үлеменә китереп кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, җиде елга кадәр ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

218 статья. Шартлаткыч, тиз кабынучан матдәләрне һәм пиротехника әйберләрен исәпкә алу, саклау, ташу һәм файдалану кагыйдәләрен бозу

Шартлаткыч, тиз кабынучан матдәләрне һәм пиротехника әйберләрен исәпкә алу, саклау, ташу һәм файдалану кагыйдәләрен бозган өчен, шулай ук әлеге матдәләрне почта аша яисә багаж итеп законсыз рәвештә җибәргән өчен, әгәр әлеге гамәлләр саксызлык аркасында кеше сәламәтлегенә зур зыян салуга яисә үлеменә китерсә, —

биш елга кадәр ирекне чикләү йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

219 статья. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу

1. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү вазифасы йөкләнгән зат янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр ул саксызлык аркасында кешенең сәламәтлегенә зур зыян салуга китерсә, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр ирекне чикләү йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган, саксызлык аркасында ике яисә аннан да күбрәк затның үлеменә китергән гамәл өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

220 статья. Атом-төш материаллары яисә радиоактив матдәләр белән законсыз эш итү

1. Атом-төш материалларын яисә радиоактив матдәләрне законсыз юнәткән, саклаган, кулланган, тапшырган яисә җимергән өчен —

ике елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә яисә башка авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәлләр өчен —

биш елга кадәр ирекне чикләү яисә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлләрне саксызлык аркасында ике яисә аннан да күбрәк затның үлеменә китереп кылган өчен —

җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

221 статья. Атом-төш материалларын яисә радиоактив матдәләрне урлау йә куркытып алу

1. Атом-төш материалларын яисә радиоактив матдәләрне урлаган йә куркытып алган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) *үз көчен югалтты;*

в) зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып;

г) гомер яисә сәламәтлек өчен куркыныч булмаган көч кулланып йә мондый көч куллану белән янап —

дүрт елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче статьяларында каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) оешкан төркем;

б) гомер яисә сәламәтлек өчен куркыныч көч кулланып йә мондый көч куллану белән янап;

в) *үз көчен югалтты* —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. *Үз көчен югалтты.*

222 статья. Коралны, аның төп өлешләрен, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне яисә шартлаткыч җайланмаларны законсыз юнәтү, тапшыру, сату, саклау, ташу яисә йөртү

1. Утлы коралны (гражданнарның шома көпшәле коралыннан, аның төп өлешләре һәм аңа сугыш-кирәк яракларыннан тыш), аның төп өлешләрен, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне яисә шартлаткыч җайланмаларны законсыз юнәткән, тапшырган, саткан, саклаган, ташыган яисә йөрткән өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, дүрт елга кадәр ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне алдан килешенгән затлар төркеме кылган өчен —

ике елдан алты елга кадәр ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне оешкан төркем кылган өчен —

биш елдан сигез елга кадәр ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Газлы коралны, салкын коралны, шул исәптән ыргыту коралын законсыз саткан өчен —

йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ике елга кадәр ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда күрсәтелгән предметларны ихтыяри рәвештә тапшырган зат, әгәр аның гамәлләрендә башка җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә. Әлеге Кодексның бу статьясында һәм 223 статьясында күрсәтелгән предметларны затны тоткарлаганда, шулай ук аларны ачыклау һәм тартып алу буенча тикшерү гамәлләрен башкарганда тартып алу бу предметларны ихтыяри тапшыру дип таныла алмый.

223 статья. Коралны законсыз әзерләү

1. Утлы ату коралын, аның җыелма детальләрен, шулай ук сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне яисә шартлаткыч җайланмаларны законсыз әзерләгән яисә ремонтлаган өчен —

ике елдан дүрт елга кадәр ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне алдан килешенгән затлар төркеме кылган өчен —

ике елдан алты елга кадәр ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне оешкан төркем кылган өчен —

биш елдан сигез елга кадәр ирекtән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Газлы коралны, салкын коралны, шул исәптән ыргыту коралын законсыз әзерләгән өчен —

йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда күрсәтелгән предметларны ихтыяри тапшырган зат, әгәр аның гамәлләрендә башка җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

224 статья. Утлы ату коралын саксыз рәвештә саклау

Утлы ату коралын башка зат файдаланырдай шартлар тудырырлык итеп игътибарсыз саклаган өчен, әгәр бу авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр ирекне чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

225 статья. Коралны, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне һәм шартлаткыч җайланмаларны саклау йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәү

1. Утлы ату коралын, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне яисә шартлаткыч җайланмаларны саклау йөкләнгән зат үз вазифаларын тиешенчә үтәмәгән өчен, әгәр бу аларның урлануына яисә юкка чыгуына йә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Атом-төш, химик яисә күпләп юк итү коралының башка төрләрен йә күпләп юк итү коралын ясаганда файдаланырга мөмкин булган материалларны яисә җиһазларны саклау йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәгән өчен, әгәр бу авыр нәтиҗәләргә китерсә йә аларны булдыруны янаса, —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

226 статья. Коралны, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне һәм шартлаткыч җайланмаларны урлау йә куркытып алу

1. Утлы ату коралын, аның җыелма детальләрен, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне яисә шартлаткыч җайланмаларны урлаган йә куркытып алган өчен —

өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Атом-төш, химик яисә күпләп юк итү коралының башка төрләрен, шулай ук күпләп юк итү коралын ясаганда файдаланырга мөмкин булган материалларны яисә җиһазларны урлаган йә куркытып алган өчен —

биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) *үз көчен югалтты;*

в) зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып;

г) гомер яисә сәламәтлек өчен куркыныч булмаган көч кулланып йә шундый көч куллану белән янап —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, биш елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Әлеге статьяның беренче, икенче яисә өченче өлешләрендә каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) оешкан төркем;

б) гомер яисә сәламәтлек өчен куркыныч көч кулланып йә шундый көч куллану белән янап;

в) *үз көчен югалтты* —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, сигез елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

227 статья. Пиратлык

1. Диңгез яисә елга судносына чит мөлкәтне биләү максатында көч кулланып йә көч куллану белән янап һөҗүм иткән өчен —

биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Корал яисә корал сыйфатында файдаланыла торган предметлар кулланып, шул ук гамәлне кылган өчен —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән зат-

ның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, сигез елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләр өчен, әгәр аларны оешкан төркем кылса йә алар саксызлык аркасында кеше үлеменә яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ун елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

25 бүлек. Халыкның сәламәтлегенә һәм җәмгыятьнең әхлаклылыгына каршы җинаятьләр

228 статья. Наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне законсыз юнәтү, саклау, ташу, әзерләү, эшкәртү

1. Наркотик чараларны, психотроп матдәләрне яисә аларның аналогларын, сату максатыннан тыш, күп микъдарда законсыз юнәткән, саклаган, ташыган, әзерләгән, эшкәрткән өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне аеруча күп күләмдә кылган өчен —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, өч елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмәләр. 1. Әлеге статьяда каралган җинаять кылган, наркотик чараларны, психотроп матдәләрне яисә аларның аналогларын ихтыяри рәвештә тапшырган һәм наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең яисә аларның аналогларының законсыз әйләнешенә бәйле җинаятьләрне ачуга яисә булдырмауга, җинаять кылган затларны фаш итүгә, җинаять юлы белән табылган мөлкәтне ачыклауга актив ярдәм иткән затлар әлеге җинаять өчен җаваплылыгыннан азат ителә. Затны тоткарлаганда, шулай ук аларны ачыклау һәм тартып алу буенча тикшерү гамәлләрен алып барганда күрсәтелгән чараларны тартып алу наркотик чараларны, психотроп матдәләрне яисә аларның аналогларын ихтыяри рәвештә тапшыру дип танылa алмый.

2. Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең күп һәм аеруча күп микъдарлары әлеге Кодексның шушы статья-

сы максатлары өчен, шулай ук 228.1 һәм 229 статьялары өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана.

3. Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр аналогларының күп һәм аеруча күп микъдарлары аналоглары булып торган наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең күп һәм аеруча күп микъдарларына туры килә.

228.1 статья. Наркотик чараларны, психотроп матдәләрне һәм аларның аналогларын законсыз җитештерү, сату яисә җибәрү

1. Наркотик чараларны, психотроп матдәләрне һәм аларның аналогларын законсыз җитештергән, саткан яисә җибәргән өчен —

дүрт елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) аеруча күп микъдарда;

в) унсигез яшьтән узган зат белә торып балигъ булмаган затка карата —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, биш елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче статьяларында каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) оешкан төркем;

б) зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып;

в) белә торып ундүрт яшькә җитмәгән затка карата;

г) аеруча күп күләмдә —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып яисә аннан башка, сигез елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

228.2 статья. Наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр әйләнеше кагыйдәләрен бозу

1. Наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне йә махсус контрольдәге наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне әзерләү өчен файдаланыла торган матдәләрне, инструментларны яисә җайланманы җитештерү, әзерләү, эшкәртү, саклау, исәпкә алу, җибәрү, реализацияләү, сату, бүлү, ташу, күчерү, юнәтү, файдалану, читтән кертү, читкә чыгару йә юкка чыгару кагыйдәләрен, шулай ук наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне җитештерү өчен файдаланылучы үсемлекләрне культивацияләү кагыйдәләрен аларның югалуына

китерерлек итеп бозган өчен, әгәр ул гамәлне күрсәтелгән кагыйдәләрне үтәү вазифасы йөкләнгән зат кылса, —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне астыртын ниятләрдә йә саксызлык аркасында кешенең сәламәтлегенә зыян салуга яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерерлек итеп кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яки аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

229 статья. Наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне урлау яисә куркытып алу

1. Наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне урлаган яисә куркытып алган өчен —

өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) *үз көчен югалтты;*

в) зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып;

г) гомер яисә сәламәтлек өчен куркыныч булмаган көч кулланып йә мондый көч куллану белән янап —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, алты елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче статьяларында каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) оешкан төркем;

б) күп микъдардагы наркотик чараларга яисә психотроп матдәләргә бәйле;

в) гомер яисә сәламәтлек өчен куркыныч көч кулланып йә мондый көч куллану белән янап;

г) *үз көчен югалтты —*

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, сигез елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

230 статья. Наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне куллануга җәлеп итү

1. Наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне куллануга җәлеп иткән өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем;

б) *үз көчен югалтты;*

в) беләторып балигъ булмаган затка яисә ике яки аннан күбрәк затка карата;

г) көч кулланып йә мондый көч куллану белән янап —

өч елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче статьяларында каралган гамәлләрне саксызлык аркасында зыян күрүченең үлеменә яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерерлек итеп кылган өчен —

алты елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяның гамәли көче, әгәр бу гамәлләр башкарма хакимиятнең сәламәтлек саклау өлкәсендәге органнары һәм наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен тикшереп торучы органнары белән килешенеп башкарылган булса, наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне куллану өчен файдаланылучы тиешле инструментларны яисә җайланманы ВИЧ-инфекцияне һәм башка куркыныч йогышлы авыруларны кисәтү максатларында куллануны пропагандалау очрагына кагылмый.

231 статья. Наркотик матдәләре булган һәм үстерү тыелган үсемлекләрне законсыз культивацияләү

1. Үстерү тыелган үсемлекләрне чәчкән яисә үстергән, шулай ук җитен, мәк яисә наркотик матдәләре булган башка үсемлек сортларын культивацияләгән өчен —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем;

б) *үз көчен югалтты;*

в) күп күләмдә —

өч елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Наркотик матдәләре булган, үстерү тыелган үсемлекләрнең күләме әлеге статья максатында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана.

232 статья. Наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр куллану өчен притоннар оештыру йә тоту

1. Наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр куллану өчен притоннар оештырган йә тоткан өчен —

дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне оешкан төркем кылган өчен —

өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

233 статья. Наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр алу хокукы бирә торган рецептларны яисә башка документларны законсыз бирү йә ясау

Наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр алу хокукы бирә торган рецептларны яисә башка документларны законсыз биргән йә ясаган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яки аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

234 статья. Сату максатларында көчле тәэсир итүче яисә агулы матдәләрнең законсыз әйләнеше

1. Наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр булмаган көчле тәэсир итүче яисә агулы матдәләрне йә аларны әзерләү яки эшкәртү җайланмасын сату максатларында законсыз әзерләгән, эшкәрткән, юнәткән, саклаган, ташыган яисә җибәргән өчен, шулай ук законсыз сатып җибәргән өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне алдан килешенгән затлар төркеме кылган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр тө-

зәтү эшләре, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне оешкан төркем кылган йә көчле тәэсир итүче күп микъдардагы матдәләргә бәйле кылган өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә дүрт елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Көчле тәэсир итүче яисә агулы матдәләрне җитештерү, юнәтү, саклау, исәпкә алу, җибәрү, ташу яисә күчерү кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр бу саксызлык аркасында аларның югалуына йә башка төрле җитди зыян салуга китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

235 статья. Хосусый медицина практикасы яисә хосусый фармацевтика эшчәнлеге белән законсыз шөгыльләнү

1. Үзе сайлаган эшчәнлек төренә лицензиясе булмаган зат хосусый медицина практикасы яисә хосусый фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнгән өчен, әгәр бу саксызлык аркасында кеше сәламәтлегенә зыян салуга китерсә, —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр ирекне чикләү яисә шул ук чорга иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

236 статья. Санитария-эпидемиология кагыйдәләрен бозу

1. Санитария-эпидемиология кагыйдәләрен саксызлык аркасында кешеләрнең күпләп авыруына яисә агулануына китерерлек итеп бозган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер

елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч елга кадәр ирекне чикләү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә биш елга кадәр ирекне чикләү, йә шул ук чорга иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

237 статья. Кешеләрнең гомеренә яисә сәламәтлегенә куркыныч тудыручы хәлләр турындагы мәгълүматны яшерү

1. Кешеләрнең гомеренә яисә сәламәтлегенә йә әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудыручы вакыйгалар, фактлар яисә күренешләр турындагы мәгълүматны шундый куркынычны бетерү чараларын күрергә вәкаләтле органнарны һәм халыкны күрсәтелгән мәгълүмат белән тәэмин итәргә тиешле зат яшергән яисә бозып күрсәткән өчен —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Россия Федерациясенең дәүләт вазифасын биләүче яисә Россия Федерациясе субъектының дәүләт вазифасын биләүче зат, шулай ук җирле үзидарә органы башлыгы шул ук гамәлләрне кылган өчен, йә шундый гамәлләр аркасында кешенең сәламәтлегенә зыян килсә яисә алар башка төрле авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

йөз меңнән биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

238 статья. Иминлек таләпләренә җавап бирми торган товарларны һәм продукцияне җитештерү, саклау, ташу йә сату, эшләр башкару яисә хезмәт күрсәтү

1. Кулланучыларның тормыш яисә сәламәтлек иминлеге таләпләренә җавап бирми торган товарларны һәм продукцияне сату максатларында җитештергән, саклаган яисә ташыган, эшләр башкарган яисә хезмәт күрсәткән өчен, шулай ук әлеге товарларның, эшләрнең яисә хезмәт күрсәтүләрнең иминлек таләпләренә туры килүен таныклый торган рәсми

документны тиешенчә дөрес итеп бирмәгән яисә файдаланмаган өчен —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәрге чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр ирекне чикләү, йә ике елга кадәр irектән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем;

б) *үз көчен югалтты;*

в) алты яшькә кадәрге балалар өчен каралган товарларга, эшләргә яисә хезмәт күрсәтүләргә карата;

г) саксызлык аркасында кешенең сәламәтлегенә зур зыян китереп яисә кеше үлеменә китереп —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә, биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне саксызлык аркасында ике яисә аннан күбрәк затның үлеменә китереп кылган өчен —

дүрт елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

239 статья. Гражданнарның шәхесенә һәм хокукларына янаучы берләшмә оештыру

1. Эшчәнлеге гражданнарга карата көч куллануга яисә аларның сәламәтлегенә башкача зыян салуга йә гражданнарны үзләренең гражданлык бурычларын үтәүдән баш тартуга яисә хокукка каршы башка гамәлләр кылуга бәйле дини яки иҗтимагый берләшмә төзегән, шулай ук мондый берләшмәгә җитәкчелек иткән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Күрсәтелгән берләшмә эшчәнлегендә катнашкан, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлләрне пропагандалаган өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

240 статья. Фахишәлек белән шөгыльләнүгә җәлеп итү

1. Фахишәлек белән шөгыльләнүгә җәлеп иткән яисә фахишәлек белән шөгыльләнүне дәвам итәргә мәҗбүр иткән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә шул ук срокка иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) көч кулланып яисә көч куллану белән янап;

б) зыян күрүчене Россия Федерациясе Дәүләт чиге аша алып чыгып яисә аны законсыз рәвештә чит илдә тотып;

в) алдан килешенгән затлар төркеме —

алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне оешкан төркем кылган йә белә торып балигъ булмаган затка карата кылган өчен —

өч елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

241 статья. Фахишәлек шөгылен оештыру

1. Башка затлар белән фахишәлек шөгылен оештыруга юнәлдерелгән, шулай ук фахишәлек белән шөгыльләнү өчен притоннар тоткан яисә фахишәлек белән шөгыльләнү өчен даими рәвештә биналар биргән өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып;

б) көч кулланып яисә көч куллану белән янап;

в) фахишәлек белән шөгыльләнү өчен белә торып балигъ булмаган затларны файдаланып —

алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне фахишәлек белән шөгыльләнү өчен ундүрт яшькә җитмәгән затларны белә торып файдаланып кылган өчен —

өч елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

242 статья. Порнография материалларын яисә предметларын законсыз тарату

Порнография материалларын яисә предметларын тарату яисә рекламалау максатларында законсыз әзерләгән яисә рекла-

малаган, тараткан өчен, шулай ук порнография характерындагы матбугат басмаларын, кино- яисә видеоматериалларны, сурәтләрне яки башка предметларны законсыз саткан өчен —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

242.1 статья. Балигъ булмаган затларның порнография сурәтләре төшерелгән материалларны яисә предметларны әзерләү һәм аларның әйләнеше

1. Белә торып балигъ булмаган затларның порнография сурәтләре төшерелгән материалларны һәм предметларны тарату, халыкка демонстрацияләү яисә рекламалау максатларында әзерләгән, саклаган яисә Россия Федерациясе Дәүләт чиге аша алып чыккан йә тараткан, халыкка демонстрацияләгән яисә рекламалаган өчен, шулай ук унсигез яшьтән узган зат белә торып балигъ булмаган затларны порнографиягә бәйле тантаналы чараларда катнашу өчен башкаручы буларак җәлеп иткән өчен —

алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) ата-аналар яисә закон белән балигъ булмаган затны тәрбияләү йөкләнгән башка зат, шулай ук балигъ булмаган затны күзәтү йөкләнгән мәгариф, тәрбия, дәвалау йә башка учреждение педагогы яисә башка хезмәткәре тарафыннан;

б) белә торып ундүрт яшькә җитмәгән затка карата;

в) алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем —

өч елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

243 статья. Тарих һәм мәдәният ядкярләрен юкка чыгару яисә зарарлау

1. Тарих һәм мәдәният ядкярләрен, табигать комплексларын яисә дәүләт саклавына алынган объектларны, шулай ук тарихи һәм мәдәни кыйммәткә ия әйберләрне яисә документларны юкка чыгарган яисә зарарлаган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Аеруча кыйммәтле объектларга яисә Гомумроссия әһәмиятендәге һәйкәлләргә бәйле шул ук гамәлләрне кылган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә

хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

244 статья. Мәетләрне һәм аларны күмү урыннарын мәсхәрәләү

1. Мәетләрне мәсхәрәләгән йә күмү урыннарын, кабер өстендәге корылмаларны яисә вафат булганнарны күмүгә яисә аларны искә алуга бәйле тантаналар өчен каралган зират биналарын юкка чыгарган, аларга зыян китергән яисә мәсхәрәләгән өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем;

б) милли, раса, дини нәфрәт яисә дошманлык сәбәбе белән, шулай ук фашизмга каршы көрәшкә яисә фашизм корбаннарына багышланган скульптура, архитектура корылмаларына йә фашизмга каршы көрәштә катнашучыларны күмү урыннарына бәйле рәвештә;

в) көч кулланып яисә көч куллану белән янап —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

245 статья. Хайваннарга карата кырыс мөгамәлә

1. Хайваннарның кырылуына яисә имгәнүенә китерерлек итеп кырыс мөгамәләдә булган өчен, әгәр бу гамәл хулиганлык максатларыннан яисә явызлык максатларыннан чыгып, яки ерткычларча алымнар кулланып, яки балалар алдында башкарылса, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

26 бүлек. Экология җинаятьләре

246 статья. Эшләр башкарганда әйләнә-тирә мохитне саклау кагыйдәләрен бозу

Сәнәга, авыл хуҗалыгы, фәнни һәм башка объектларны проектлаганда, урнаштырганда, төзегәндә, файдалануга тапшырганда һәм файдаланганда әйләнә-тирә мохитне саклау кагыйдәләрен үтәүгә җаваплы затлар әлеге кагыйдәләрне бозган өчен, әгәр бу радиоактив фонның җитди үзгәрүенә, кешенең сәламәтлегенә зыян салуга, хайваннарның күпләп кырылуына яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

247 статья. Экологик хәвефле матдәләр һәм калдыклар әйләнеше кагыйдәләрен бозу

1. Хәвефле калдыкларның тыелган төрләрен җитештергән, радиоактив, бактериологик, химик матдәләрне һәм калдыкларны билгеләнгән кагыйдәләрне бозып транспортировкалаган, саклаган, күмгән, файдаланган яисә башкача әйләнештә йөрткән өчен, әгәр бу гамәлләр кешенең сәламәтлегенә яисә әйләнә-тирә мохиткә җитди зыян китерү куркынычын тудырса, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Әйләнә-тирә мохитне пычратуга, агулауга яисә зарарлауга, кешенең сәламәтлегенә зыян салуга йә хайваннарның күпләп кырылуына китергән, шулай ук экологик афәтләр зонасында яисә гадәттән тыш экологик вазгыять зонасында кылган гамәлләр өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне саксызлык аркасында кеше үлеменә йә кешеләрнең күпләп авыруларына китерерлек итеп кылган өчен —

өч елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

248 статья. Микробиологик йә башка биологик агентлар яисә токсиннар белән эш иткәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен бозу

1. Микробиологик йә башка биологик агентлар яисә токсиннар белән эш иткәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр ул кеше сәламәтлегенә зыян салуга, эпидемияләр яисә эпизоотияләр таралуга яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

249 статья. Ветеринария кагыйдәләрен һәм үсемлек авырулары һәм корткычлары белән көрәшү өчен билгеләнгән кагыйдәләрне бозу

1. Саксызлык аркасында эпизоотияләр таралуга яисә башка авыр нәтиҗәләргә китерерлек итеп ветеринария кагыйдәләрен бозган өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында үсемлек авырулары һәм корткычлары белән көрәшү өчен билгеләнгән кагыйдәләрне бозган өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәрге чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр ирекне чикләү рәвешендә җәза бирелә.

250 статья. Суларны пычрату

1. Җир өстендәге яисә җир астындагы суларны, эчәр су чыганакларын пычраткан, чүпләгән, саектырган өчен йә алар-

ның табигый үзенчәлекләрен башкача үзгәрткән өчен, әгәр әлеге гамәлләр хайваннар яисә үсемлекләр дөньясына, балык запасына, урман яисә авыл хуҗалыгына җитди зыян салуга китерсә, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Кешенең сәламәтлегенә зыян салуга яисә хайваннарның күпләп кырылуына китергән, шулай ук тыюлык яисә заказник территориясендә йә экологик афәт зонасында яисә гадәттән тыш экологик вазгыять зонасында кылган шул ук гамәлләр өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган, саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән гамәлләр өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

251 статья. Атмосфераны пычрату

1. Атмосферага пычраткыч матдәләрне чыгару кагыйдәләрен бозган яисә җайланмалардан, корылмалардан һәм башка объектлардан файдалануны бозган өчен, әгәр бу гамәлләр һаваны пычратуга яисә аның табигый үзенчәлекләрен башкача үзгәртүгә китерсә, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше сәламәтлегенә зыян салуга китергән шул ук гамәлләр өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә ка-

ралган гамәлләрне саксызлык аркасында кеше үлеменә китереп кылган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

252 статья. Диңгез мохитен пычрату

1. Диңгез мохитен коры җирдә урнашкан чыганаклардан пычраткан йә күмү кагыйдәләрен бозу яисә транспорт чараларыннан яисә диңгездәге ясалма корылмалардан кешенең сәламәтлеге, диңгездәге тереклек ресурслары өчен зарарлы йә диңгез мохитеннән дөрес файдалануга комачаулый торган матдәләр һәм материаллар чыгарып ташлау аркасында пычраткан өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә дүрт айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Кешенең сәламәтлегенә, хайваннар яисә үсемлекләр дөньясына, балык запасларына, әйләнә-тирә мохиткә, ял итү зоналарына йә закон белән саклана торган башка мәнфәгатьләргә җитди зыян салуга китергән шул ук гамәлләр өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне саксызлык аркасында кеше үлеменә китереп кылган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

253 статья. Россия Федерациясенең континенталь шельфы һәм махсус икътисади зонасы турында Россия Федерациясе законнарын бозу

1. Россия Федерациясе континенталь шельфында корылмаларны законсыз төзегән, алар тирәсендә яисә Россия Федерациясенең махсус икътисади зонасы тирәсендә законсыз рәвештә иминлек зоналары төзегән, шулай ук әлеге корылмаларны төзү, эксплуатацияләү, саклау һәм ликвидацияләү кагыйдәләрен һәм диңгез суднолары йөреше иминлеген тәэмин итү чараларын бозган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт ха-

кы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

2. Россия Федерациясе континенталь шельфының яисә Россия Федерациясе махсус икътисади зонасының табигый байлыкларын тиешле рөхсәттән башка тикшергән, эзләгән, эшкәрткән өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

254 статья. Җир бозу

1. Җирне ашламалар, үсемлекләрне үстерү стимуляторлары, агулы химикатлар һәм башка куркыныч химик һәм биологик матдәләрне саклаганда, файдаланганда һәм транспортировкалаганда алар белән эш итү кагыйдәләрен кешенең сәламәтлегенә яисә әйләнә-тирә мохиткә зыян китерерлек итеп бозу аркасында хуҗалык яисә башка эшчәнлекнең зарарлы продуктлары белән агулаган, пычраткан яисә бүтәнчә бозган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне экологик афәт зонасында яисә гадәттән тыш экологик вазгыять зонасында кылган өчен —

ике елга кадәр ирекне чикләү яисә шул ук срокка иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне саксызлык аркасында кеше үлеменә китереп кылган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

255 статья. Җир асты байлыкларын саклау һәм алардан файдалану кагыйдәләрен бозу

Җир асты байлыклары чыгару предприятиеләрен яисә файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын проектлаганда, урнаштырганда, төзегәндә, файдала-

нуга тапшырганда һәм файдаланганда җир асты байлыкларын саклау һәм алардан файдалану кагыйдәләрен бозган, шулай ук файдалы казылмалар ятмалары мәйданнарында үз белдеге белән төзелеш алып барган өчен, әгәр бу гамәлләр сизелерлек зыян салуга китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

256 статья. Су хайваннарын һәм үсемлекләрен законсыз тоту (чыгару)

1. Балыкны, диңгез җәнлекләрен һәм башка су хайваннарын яисә диңгез промыселлары үсемлекләрен законсыз тоткан (чыгарган) өчен, әгәр бу гамәл:

а) зур зыян китерсә;

б) үзйөрешле йөзмә транспорт чарасын яисә шартлаткыч һәм химик матдәләрне, электр тогын йә күрсәтелгән су хайваннарын һәм үсемлекләрен күпләп юкка чыгаруның башка алымнарын кулланып башкарылса;

в) уылдык чәчү урыннарында яисә аларның миграция юлларында башкарылса;

г) тыюлык, заказник йә экологик афәт яисә гадәттән тыш экология вазгыять зонасы территориясендә башкарылса, —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Диңгез мәчеләрен, су кондызларын яисә ачык диңгездә яисә башка зоналарда бүтән диңгез имезүчеләрен законсыз тоткан өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылган йә алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем кылган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр хезмәт хакы

яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

257 статья. Балык запасларын саклау кагыйдәләрен бозу

Балык запасларын саклау кагыйдәләрен бозып урман кискән, күперләр, дамбалар төзегән, агач һәм башка урман продукциясен урман үзәненнән ташыган, шартлату һәм башка төрле эшләр башкарган, шулай ук су корылмаларын һәм суүткәргеч механизмнардан файдаланган өчен, әгәр бу гамәлләр балыкларның яисә башка су хайваннарының күпләп кырылуларына, сизелерлек күләмнәрдә туклану запасларын юкка чыгаруга йә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

258 статья. Законсыз аучылык

1. Законсыз аучылык өчен, әгәр ул гамәл түбәндәгечә башкарылса:

а) зур зыян китереп;

б) механик транспорт чарасын яисә һава судносын, шартлаткыч матдәләрне, газларны яисә кошларны һәм җәнлекләрне күпләп юкка чыгаруның башка ысулларын кулланып;

в) аучылык тулысынча тыелган кошларга һәм җәнлекләргә карата;

г) тыюлык, заказник территориясендә йә экологик афәт зонасында яисә гадәттән тыш экологик вазгыять зонасында —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылган йә алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем кылган шул ук гамәл өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

259 статья. Россия Федерациясе Кызыл китабына кертелгән организмнар өчен критик яшәү мохитен юкка чыгару

Россия Федерациясе Кызыл китабына кертелгән организмнарның үрчүен бетерерлек итеп критик яшәү мохитен юкка чыгарган өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү яисә шул ук чорга иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

260 статья. Агачларны һәм куаклыкларны законсыз кисү

1. Беренче төркем урманнарда йә барлык төркемдәге урманнарның аеруча саклаулы кишәрлекләрендә агачларны, куаклыкларны һәм лианаларны законсыз кискән, шулай ук үсмәслек дәрәҗәгә җиткереп зарарлаган өчен, шулай ук урман фондына кертелмәгән яисә кисү тыелган агачларны, куаклыкларны һәм лианаларны кискән өчен, әгәр бу гамәлләр сизелерлек күләмдә башкарылса, —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә алты айдан бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Барлык төркемнәрдәге урманнарда агачларны, куаклыкларны һәм лианаларны, шулай ук урман фондына керми торган үсемлекләрне үсмәслек дәрәҗәгә җиткереп зарарлаган өчен, әгәр бу гамәлләр түбәндәгечә башкарылса:

а) затлар төркеме;

б) *үз көчен югалтты;*

в) үзенең хезмәт урыныннан файдаланып;

г) зур күләмдә —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне аеруча зур күләмдә, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем кылган өчен —

йөз меңнән биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән

шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда сизелерлек күләмдә дигәндә урман фондына һәм урман фондына керми торган урманнарга Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган такса буенча — ун мең сумнан арткан зыян, зур күләмдә дигәндә — йөз мең сумнан, аеруча зур күләмдә дигәндә, ике йөз илле мең сумнан арткан зыян таныла.

261 статья. Урманнарны бетерү яисә зарарлау

1. Урманнарны, шулай ук урман фондына керми торган үсемлекләрне ут белән яисә башка аеруча куркыныч чыганаклар белән саксыз мөнәсәбәт аркасында бетергән яисә зарарлаган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Урманнарны, шулай ук урман фондына керми торган үсемлекләрне яндырып, башка гомуми куркыныч ысул белән йә зарарлы матдәләр, калдыклар, атмосферага чыгарган башка төрле зыян белән бетергән яисә зарарлаган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, ун мең сумнан йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер айдан бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

262 статья. Махсус сакланылучы табигать территорияләре һәм табигать объектлары режимын бозу

Тыюлыклар, заказниклар, милли парклар, табигать ядкярләре һәм дәүләт тарафыннан махсус сакланылучы башка табигать территорияләре режимын сизелерлек зыян китерерлек итеп бозган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

27 бүлек. Транспорт хәрәкәте иминлегенә һәм эксплуатацияләүгә каршы җинаятьләр

263 статья. Тимер юл, һава һәм су транспортының хәрәкәт иминлеген һәм эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу

1. Тимер юл, һава, диңгез яисә елга транспортының хәрәкәт иминлеге һәм аларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен эшләү барышында яисә биләгән вазифасы буенча әлеге кагыйдәләрне сакларга тиешле зат бозган өчен, әгәр әлеге гамәл саксызлык аркасында кешенең сәламәтлегенә зур зыян салуга китерсә, —

биш елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр ректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр ирректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлне саксызлык аркасында ике яисә аннан күбрәк затның үлеменә китерерлек итеп кылган өчен —

җиде елга кадәр ирректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

264 статья. Юл хәрәкәте һәм транспорт чараларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу

1. Автомобиль, трамвай йә башка механик транспорт чарасы белән идарә итүче зат юл хәрәкәте яисә транспорт чараларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен саксызлык аркасында бозган өчен, әгәр әлеге гамәл кешенең сәламәтлегенә зур зыян салуга китерсә, —

биш елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр транспорт белән идарә итү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр ирректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

өч елга кадәр транспорт чарасы белән идарә итү хокукыннан мәхрүм итеп, биш елга кадәр ирректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлне саксызлык аркасында ике яисә аннан күбрәк затның үлеменә китерерлек итеп кылган өчен —

өч елга кадәр транспорт чарасы белән идарә итү хокукын-

нан мәхрүм итеп, җиде елга кадәр ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда башка механик транспорт чаралары дигәндә троллейбуслар, шулай ук тракторлар һәм башка үзйөрешле машиналар, мотоцикллар һәм башка механик транспорт чаралары аңлашыла.

265 статья. *Үз көчен югалтты.*

266 статья. Транспорт чараларын сыйфатсыз ремонтлау һәм аларны техник төгәлсезлекләр белән эксплуатациягә чыгару

1. Транспорт чараларын, аралашу юлларын, сигнализация яисә элемтә чараларын йә башка транспорт җайланмасын сыйфатсыз ремонтлаган өчен, шулай ук транспорт чараларының техник торышы өчен җаваплы затлар техник яктан төзек булмаган транспорт чараларын эксплуатациягә чыгарган өчен, әгәр әлеге гамәлләр саксызлык аркасында кешенең сәламәтлегенә зур зыян салуга китерсә, —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәлләр өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлләрне саксызлык аркасында ике яисә аннан күбрәк затның үлеменә китерерлек итеп кылган өчен —

җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

267 статья. Транспорт чараларын яисә аралашу юлларын яраксыз хәлгә китерү

1. Транспорт чарасын, аралашу юлларын, сигнализация яисә элемтә чараларын йә башка транспорт җайланмасын җимергән, зарарлаган яисә башка алым белән яраксыз хәлгә китергән өчен, шулай ук транспорт коммуникацияләрен блокировкалаган өчен, әгәр бу гамәлләр саксызлык аркасында кешенең сәламәтлегенә зур зыян салуга йә авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт ха-

кы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәлләр өчен —

өч елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлләрне саксызлык аркасында ике яисә аннан күбрәк затның үлеменә китерерлек итеп кылган өчен —

алты елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

268 статья. Транспортның хәвефсез эшләвен тәэмин итүче кагыйдәләрне бозу

1. Пассажир, җәяүле яисә хәрәкәттә башка төрле катнашучы (әлеге Кодексның 263 һәм 264 статьяларында күрсәтелгән затлардан тыш) хәрәкәт иминлеге яисә транспорт чараларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр бу гамәл саксызлык аркасында кешенең сәламәтлегенә зур зыян салуга китерсә, —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә ике айдан дүрт айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр ирекне чикләү яисә шул ук срокка иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлне саксызлык аркасында ике яисә аннан күбрәк затның үлеменә китерерлек итеп кылган өчен —

җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

269 статья. Магистраль торбаүткәргечләрне төзегәндә, эксплуатацияләгәндә яисә ремонтлаганда иминлек кагыйдәләрен бозу

1. Магистраль торбаүткәргечләрне төзегәндә, эксплуатацияләгәндә яисә ремонтлаганда иминлек кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр бу гамәл саксызлык аркасында кешенең сәламәтлегенә зур зыян салуга китерсә, —

дүрт елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлне саксызлык аркасында ике яисә аннан күбрәк затның үлеменә китерерлек итеп кылган өчен —

җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

270 статья. Судно капитанының афәткә юлыгучыларга ярдәм күрсәтмәве

Судно капитаны диңгездә яисә башка су юлында афәткә юлыккан кешеләргә ярдәм күрсәтмәгән өчен, әгәр бу ярдәм үзенең судносына, аның экипажына һәм пассажирларына җитди куркыныч янамыйча күрсәтелә алган булса, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

271 статья. Халыкара очыш кагыйдәләрен бозу

Очышның рөхсәттә күрсәтелгән маршрутларын, туктау урыннарын, һава капкаларын, биеклеген үтәмәгән өчен яисә халыкара очыш кагыйдәләрен башкача бозган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр ирекне чикләү, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

28 бүлек. Компьютер мәгълүматы өлкәсендәге җинаятьләр

272 статья. Компьютер мәгълүматына хокуксыз керү

1. Закон белән саклانучы компьютер мәгълүматына, ягъни машина чыганакларындагы, электрон исәпләү машинасындагы (ЭВМ), ЭВМ системасындагы яисә аларның челтәрендәге мәгълүматка хокуксыз кергән өчен, әгәр бу гамәл мәгълүматны юкка чыгаруга, блокировкалауга, модификацияләүгә йә

күчерүгә, ЭВМ, ЭВМ системасы яисә аларның челтәр эшен бозуга китерсә, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә алты айдан бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем, йә үзенең хезмәт урыныннан файдаланган, шулай ук ЭВМга, ЭВМ системасына яисә аларның челтәренә керү мөмкинлеге булган зат шул ук гамәлне кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

273 статья. ЭВМ өчен зарарлы чыганагы булган программалар төзү, куллану һәм тарату

Мәгълүматны күрәләтә санкцияләнмәгән юкка чыгаруга, блокировкалауга, модификацияләүгә йә күчерүгә, ЭВМ, ЭВМ системасын яисә аларның челтәрен бозуга китерә торган программалар төзегән яисә булган программаларга үзгәрешләр керткән өчен, шулай ук мондый программаларны яисә шундый программалы машина чыганакларын кулланган йә тараткан өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәлләр өчен —

өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

274 статья. ЭВМ, ЭВМ системасын яисә аларның челтәрен эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу

1. ЭВМ, ЭВМ системасына яисә аларның челтәренә керү мөмкинлеге булган зат тарафыннан ЭВМ, ЭВМ системасы яисә аларның челтәрен эксплуатацияләү кагыйдәләрен закон белән саклана торган ЭВМ мәгълүматының юкка чыгуына, блокировкалануына яисә модификацияләнүенә китерерлек итеп бозган өчен, әгәр бу гамәл сизелерлек зыян салуга китерсә, —

биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә ике елга кадәр ирекне чикләү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәл өчен —

дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

X кисәк. Дәүләт хакимиятенә каршы җинаятьләр

29 бүлек. Дәүләтнең конституциячел корылышы нигезләренә һәм иминлегенә каршы җинаятьләр

275 статья. Дәүләткә хыянәт

Россия Федерациясе гражданы тарафыннан дәүләткә хыянәт, ягъни шпионаж, дәүләт серен саткан йә чит илгә, чит ил оешмасына яисә аларның вәкилләренә Россия Федерациясенең тышкы иминлегенә зыян китереп, дошманлык эшчәнлеге алып барганда башка төрле ярдәм күрсәткән өчен —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, унике елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Бу Кодексның әлеге статьясында, шулай ук 276 һәм 278 статьяларында каралган җинаятьләрне кылган зат, хакимият органнарына ихтыяри һәм үз вакытында хәбәр итеп яисә башка рәвешле Россия Федерациясе мәнфәгатьләренә алга таба зыян килүне туктатуга ярдәм итсә, һәм аның гамәлләрендә бүтән җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

276 статья. Шпионаж

Чит илгә, чит ил оешмасына яисә аларның вәкилләренә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне тапшырган, шулай ук җыйган, урлаган яисә тапшыру максатларында саклаган, шулай ук чит ил разведкасы йөкләмәсе буенча башка белешмәләрне Россия Федерациясенең тышкы иминлегенә зыян китерерлек итеп файдаланып тапшырган яисә җыйган өчен, әгәр бу гамәлләрне чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат кылса, —

ун елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

277 статья. Дәүләт яисә җәмәгать эшлеклесе гомеренә кул сузу

Дәүләт яисә җәмәгать эшлеклесе гомеренә аның дәүләт яисә башка сәяси эшчәнлеген туктату йә шундый эшчәнлек өчен үч алу (террорлык акты) максатларында кул сузган өчен —

унике елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү, йә гомерлеккә иректән мәхрүм итү, йә үлем җәзасы рәвешендә җәза бирелә.

278 статья. Хакимиятне көч кулланып алу яисә хакимиятне көч кулланып тоту

Россия Федерациясе Конституциясен бозып, хакимиятне көч кулланып алуга яисә хакимиятне көч кулланып тотуга юнәлдерелгән гамәлләр, шулай ук Россия Федерациясенең конституциячел төзелешен көч кулланып үзгәртүгә юнәлдерелгән гамәлләр кылган өчен —

унике елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

279 статья. Хәрби фетнә

Россия Федерациясенең конституциячел төзелешен бәреп төшерү яисә көч кулланып үзгәртү йә Россия Федерациясенең территориаль бөтенлеген бозу максатларында хәрби фетнә оештырган йә анда актив катнашкан өчен —

унике елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

280 статья. Экстремистлык эшчәнлеген башкаруга ачыктан-ачык өндәүләр

1. Экстремистлык эшчәнлеген башкаруга ачыктан-ачык өндәгән өчен —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдаланып кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

281 статья. Диверсия

1. Россия Федерациясенең икътисади иминлеген һәм оборона сәләтен өзү максатларында халыкның яшәешен тәэмин итү предприятиеләрен, корылмаларын, юлларын һәм арала-

шу чараларын, элемтә чараларын, объектларын шартлаткан, яндырган яисә аларны бозуга яисә зарарлауга юнәлдергән башка гамәлләр кылган өчен —

ун елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне оешкан төркем кылган өчен —

унике елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

282 статья. Нәфрәт йә дошманлык тудыру, шулай ук кешелек абруен төшерү

1. Ачыктан-ачык яисә массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдаланып, нәфрәт йә дошманлык тудыруга, шулай ук кешенең йә затлар төркеменең җенесе, расасы, милләте, теле, килеп чыгышы, дингә мөнәсәбәте, шулай ук нинди дә булса социаль төркемгә каравы буенча абруен төшерүгә юнәлдерелгән гамәлләр өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) көч куланып яисә көч куллану белән янап;

б) зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып;

в) оешкан төркем —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз егерме сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

282.1 статья. Экстремистлык җәмгыяте оештыру

1. Экстремистлык җәмгыяте оештырган, ягъни идеологик, сәяси, раса, милли яисә дини нәфрәт йә дошманлык сәбәпләре белән, шулай ук нинди дә булса социаль төркемгә карата нәфрәт йә дошманлык сәбәпләре белән әлеге Кодексның 148, 149 статьяларында, 213 статьясының беренче һәм икенче өлешләрендә, 214, 243, 244, 280 һәм 282 статьяларында каралган җинаятьләрне (экстремистлыкка юнәлдерелгән җинаятьләр-

не) әзерләү яисә кылу максатыннан затлар төркеме оештырган өчен, шулай ук мондый экстремистлык җәмгыятенә, аның өлешенә яисә шундый җәмгыятькә керә торган структур бүлекчәләргә җитәкчелек иткән өчен, шулай ук экстремистлыкка юнәлдерелгән җинаятьләрне кылу планнарын һәм (яисә) шартларын булдыру максатларында мондый җәмгыятьнең өлешләре яисә структур бүлекчәләре оештыручылары, җитәкчеләре яисә бүтән вәкилләре берләшмәләрен төзегән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Экстремистлык җәмгыятендә катнашкан өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне зат үзенең хезмәт урыныннан файдаланып кылган өчен —

йөз меңнән өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Экстремистлык җәмгыятендә катнашуын ихтыяри туктаткан зат, әгәр аның гамәлләрендә башка җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

282.2 статья. Экстремистлык оешмасы эшчәнлеген оештыру

1. Экстремистлык эшчәнлеген башкаруга бәйле эшчәнлеген бетерү яисә тыю турында суд тарафыннан кабул ителгән законлы көченә кергән карары булган иҗтимагый яисә дини берләшмә йә башка оешма эшчәнлеген оештырган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Экстремистлык эшчәнлеген башкаруга бәйле эшчән-

леген бетерү яисә тыю турында суд тарафыннан кабул ителгән законлы көченә кергән карары булган иҗтимагый яисә дини берләшмә йә башка оешма эшчәнлегендә катнашкан өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән керeме күләмендә штраф, йә дүрт айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Экстремистлык эшчәнлеген башкаруга бәйле эшчәнлеген бетерү яисә тыю турында суд тарафыннан кабул ителгән законлы көченә кергән карары булган иҗтимагый яисә дини берләшмә йә башка оешма эшчәнлегендә катнашуын ихтыяри туктаткан зат, әгәр аның гамәлләрендә башка җинаять составы булмаса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

283 статья. Дәүләт серен ачу

1. Дәүләт сере ышанып тапшырылган яки хезмәт яисә эш буенча дәүләт сере мәгълүм булган зат дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне ачкан өчен, әгәр бу белешмәләр, дәүләткә хыянәт билгеләре булмыйча, башка затлар файдаланырлык итеп ачыкланса, —

дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәл өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

284 статья. Дәүләт серен тәшкил итүче документларны югалту

Дәүләт сереннән файдалану мөмкинлеге булган зат дәүләт сере булган документлар, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләре булган предметлар белән эш итүнең билгеләнгән кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр бу саксызлык аркасында аларның югалуына һәм авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

30 бүлек. Дәүләт хакимиятенә, дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнарындагы хезмәт мәнфәгатьләренә каршы җинаятьләр

285 статья. Урындагы зат вәкаләтләреннән явыз ниятләрдә файдалану

1. Урындагы зат үзенең хезмәт вәкаләтләреннән хезмәт мәнфәгатьләренә каршы килеп файдаланган өчен, әгәр бу гамәл явыз нияттән яисә башка шәхси кызыксынудан чыгып башкарылса һәм гражданнарның яисә оешмаларның мәнфәгатьләрен йә җәмгыятьнең яисә дәүләтнең закон белән сакланучы мәнфәгатьләрен сизелерлек бозуга китерсә, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне Россия Федерациясе дәүләт вазифасын яисә Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазифасын биләүче зат, шулай ук җирле үзидарә органы башлыгы кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләр авыр нәтиҗәләргә китереп кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмәләр. 1. Әлеге бүлек статьяларында урындагы затлар дигәндә даими, вакытлы яисә махсус вәкаләт буенча хакимият вәкиле вазифасын башкаручы йә дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдә, шулай ук Россия Федерациясе Хәрби Көчләрендә, Россия Федерациясенең башка гаскәрләрендә һәм хәрби формированиеләрендә оештыру-боеру, административ-хуҗалык вазифаларын башкаручы затлар аңлашыла.

2. Әлеге Кодексның шушы бүлеге статьяларында һәм башка статьяларында Россия Федерациясенең дәүләт вазифаларын биләүче затлар дигәндә, дәүләт органнары вәкаләтләрен турыдан-туры башкару өчен Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар һәм федераль за-

коннар белән билгеләнә торган эш урыннарын биләүче затлар аңлашыла.

3. Әлеге Кодексның шушы бүлеге статьяларында һәм башка статьяларында Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазифаларын биләүче затлар дигәндә дәүләт органнары вәкаләтләрен турыдан-туры башкару өчен Россия Федерациясе субъектларының конституцияләре яисә уставлары белән билгеләнә торган эш урыннарын биләүче затлар аңлашыла.

4. Дәүләт хезмәткәрләре һәм җирле үзидарә органнарының урындагы затлар исәбенә керми торган хезмәткәрләре әлеге бүлек статьялары буенча тиешле статьяларда каралган махсус очракларда җинаять җаваплылыгына тартыла.

285.1 статья. Бюджет акчаларын максатсыз тоту

1. Бюджет акчаларын алучы урындагы зат бюджет акчаларын аларны алу буенча бюджет, бюджет язмасы, бюджет ассигнованиеләре турындагы хәбәрнамә, керемнәр һәм чыгымнар сметасы йә бюджет акчаларын алуга нигез булып торган башка документ белән расланган билгеләнгән шартларга туры килми торган максатларга зур күләмдә тоткан өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) аеруча зур күләмдә —

ике йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге Кодексның бу статьясында, шулай ук 285.2 статьясында зур күләмдә дигәндә — бер миллион биш йөз мең сумнан арткан бюджет акчасы суммасы, ә аеруча зур күләмдә дигәндә җиде миллион биш йөз мең сумнан арткан бюджет акчасы суммасы аңлашыла.

285.2 статья. Бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчаларын максатсыз тоту

1. Урындагы зат бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчала-

рын аларның эшчәнлеген җайга сала торган Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән шартларга һәм күрсәтелгән фондларның бюджетларына туры килми торган максатларга зур күләмдә тоткан өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме;

б) аеруча зур күләмдә —

ике йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яисә бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

286 статья. Эш урынындагы вәкаләтләрне арттырып куллану

1. Урындагы зат үз вәкаләтләре чикләреннән чыгып һәм гражданнарның яисә оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен йә җәмгыятьнең яисә дәүләтнең закон белән саклана торган мәнфәгатләрен җитди бозуга китерерлек гамәлләр кылган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне Россия Федерациясе дәүләт вазифасын яисә Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазифасын биләүче зат, шулай ук җирле үзидарә органы башлыгы кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) көч кулланып яисә көч куллану белән янап;
б) корал яисә махсус чаралар кулланып;
в) авыр нәтиҗәләргә китереп —
өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, өч елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

287 статья. Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә яисә Россия Федерациясе Хисап палатасына мәгълүмат бирүдән баш тарту

1. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советына, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына яисә Россия Федерациясе Хисап палатасына мәгълүмат (документлар, материаллар) бирүдән законсыз баш тарткан яисә читләшкән, шулай ук күрәләтә тулы булмаган йә ялган мәгълүмат биргән өчен, әгәр бу гамәлләр мондый мәгълүматны бирергә тиешле урындагы зат тарафыннан башкарылса, —
ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елдан биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне Россия Федерациясе дәүләт вазифасын яисә Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазифасын биләүче зат кылган өчен —
йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:
а) дәүләт хакимияте органнарының урындагы затлары кылган хокук бозуларны яшерүгә бәйле рәвештә;
б) алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем;
в) авыр нәтиҗәләргә китереп —
өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, дүрт елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

288 статья. Урындагы затның вәкаләтләрен үзләштерү

Дәүләт хезмәткәре яисә җирле үзидарә органының урындагы зат булып тормаган хезмәткәре урындагы зат вәкаләтләрен үзләштергән өчен һәм аларга бәйле рәвештә гражданнарның яисә оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен җитди бозуга китерерлек гамәлләр кылган өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

289 статья. Эшкуарлык эшчәнлегендә законсыз катнашу

Урындагы зат эшкуарлык эшчәнлеген башкаручы оешманы гамәлгә куйган йә мондый оешма белән идарә итүдә шәхсән үзе яисә ышанычлы зат аша законда билгеләнгән тыюга каршы килеп идарә итүдә катнашкан өчен, әгәр бу гамәлләр әлеге оешмага ташламалар һәм өстенлекләр бирүгә яисә башка рәвешле яклауга бәйле булса, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

290 статья. Ришвәт алу

1. Урындагы зат шәхсән яисә арадашчы аша ришвәт бирүче яисә ул тәкъдим иткән затлар файдасына эш башкарган (башкармаган) өчен акча, кыйммәтле кәгазьләр, башка мөлкәт яисә мөлкәти характердагы файда алган өчен, әгәр бу гамәлләр (гамәл кылмаулар) урындагы затның хезмәт вәкаләтләренә керсә йә вазифаи хәле ярдәмендә мондый гамәлләргә (гамәл кылмауларга) булышлык күрсәтерлек булса, шулай ук хезмәт буенча гомуми яклау күрсәткән яисә узындырган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Урындагы зат законсыз гамәлләренә (гамәл кылмауларына) ришвәт алган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эш-

чәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне Россия Федерациясе дәүләт вазифасын яисә Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазифасын биләүче зат, шулай ук җирле үзидарә органы башлыгы кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Әлеге статьяның беренче, икенче яисә өченче өлешләрендә каралган гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем;

б) *үз көчен югалтты;*

в) ришвәтне куркытып алып;

г) зур күләмдә —

бер миллион сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның биш елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Йөз илле мең сумнан арткан акча, кыйммәтле кәгазьләр, башка мөлкәт яисә мөлкәти характердагы файда суммасы зур күләмдәге ришвәт дип таныла.

291 статья. Ришвәт бирү

1. Урындагы затка шәхсән яисә арадашчы аша ришвәт биргән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Урындагы затка аның белә торып кылган законсыз гамәлләренә (гамәл кылмауларына) ришвәт биргән өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Ришвәт биргән зат, әгәр урындагы зат ягыннан ришвәтне куркытып алу факты булса яисә әлеге зат ул хакта җинаять эше кузгату хокукына ия органга хәбәр итсә, җинаять җаваплылыгыннан азат ителә.

292 статья. Хезмәт урынындагы алдау

Хезмәт урынындагы алдау, ягъни урындагы зат, шулай ук дәүләт хезмәткәре яисә җирле үзидарә органының урындагы

зат булып тормаган хезмәткәре рәсми документларга күрәләтә ялган белешмәләр керткән, шулай ук күрсәтелгән документларга аларның дөрес эчтәлеген бозарлык төзәтмәләр ясаган өчен, әгәр бу гамәлләр астыртып нияттән яисә башка шәхси кызыксынудан чыгып башкарылса, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

293 статья. Ваемсызлык

1. Ваемсызлык, ягъни урындагы зат намуссыз яисә хезмәткә карата саксыз мөнәсәбәт аркасында үз вазифаларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен, әгәр бу зур зыян салуга китерсә, —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айдан бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кешенең сәламәтлегенә зур зыян салуга яисә үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлләрне саксызлык аркасында ике яисә аннан күбрәк затның үлеменә китерерлек итеп кылган өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяда зур зыян дип йөз мең сумнан арткан суммадагы зыян танылa.

31 бүлек. Хөкем итүгә каршы җинаятьләр

294 статья. Хөкем итүгә һәм алдан һәрьяклап тикшерүне башкаруга каршылык күрсәтү

1. Хөкем итүгә каршылык күрсәтү максатларында суд эшчәнлегенә ничек булса да тыкшынган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Прокурор, тикшерүче яисә алдан сорау алуны башкаручы зат эшчәнлегенә эшне күпьяклы, тулысынча һәм объектив һәрьяклап тикшерүгә каршылык күрсәтү максатларында ничек булса да тыкшынган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне зат хезмәт урыныннан файдаланып кылган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

295 статья. Хөкем итүче яисә алдан һәрьяклап тикшерү алып баручы затның гомеренә кул сузу

Судьяның, присяжный утырышчының яисә хөкем итүдә катнашучы башка затның, прокурорның, тикшерүченең, алдан сорау алуны башкаручы затның, яклаучының, экспертның, белгечнең, суд приставының, суд башкаручысының, шулай ук аларның якыннарының гомерләренә эшләрне яисә материалларны судта карауга, алдан һәрьяклап тикшерү алып баруга йә хөкем, суд карарын яисә суд актын башкаруга бәйле рәвештә күрсәтелгән затларның законлы эшчәнлегенә каршылык күрсәтү йә шундый эшчәнлек өчен үч алу максатларында кул сузган өчен —

унике елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү, йә гомерлеккә иректән мәхрүм итү, йә үлем җәзасы рәвешендә җәза бирелә.

296 статья. Хөкем итүгә яисә алдан һәрьяклап тикшерү алып баруга бәйле янау яисә көч куллану гамәлләре

1. Судьяга, присяжный утырышчыга яисә хөкем итүдә катнашучы башка затка, шулай ук аның якыннарына карата судта эшләр яисә материаллар карауга бәйле рәвештә үтерү, сәла-

мәтлегенә зыян салу, мөлкәтне юкка чыгару яисә зарарлау белән янаган өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Прокурорга, тикшерүчегә, башлап сорау алуны башкаручы затка, яклаучыга, экспертка, белгечкә, суд приставына, суд башкаручысына, шулай ук аларның якыннарына карата алдан һәрьяклап тикшерү алып баруга, судта эшләрне яисә материалларны карауга йә хөкем, суд карары яисә башка суд актын башкаруга бәйле рәвештә шундый ук гамәлне кылган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне гомер яисә сәламәтлек өчен куркыныч булмаган көч кулланып кылган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне гомер яисә сәламәтлек өчен куркыныч көч кулланып кылган өчен —

биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

297 статья. Судка ихтирамсызлык күрсәтү

1. Судка карата суд тикшерүендә катнашучыларны хурлауда чагыла торган ихтирамсызлык күрсәткән өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә ике айдан дүрт айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Судьяны, присяжный утырышчыны яисә хөкем итүдә катнашучы башка затны хурлауда чагыла торган шул ук гамәл өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

298 статья. Судьяга, присяжный утырышчыга, прокурорга, тикшерүчегә, башлап сорау алуны башкаручы затка, суд приставына, суд башкаручысына карата яла ягу

1. Судьяга, присяжный утырышчыга яисә хөкем итүдә катнашучы башка затка карата судта эшләрне яисә материалларны карауга бәйле рәвештә яла яккан өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән керемe күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Прокурорга, тикшерүчегә, алдан сорау алуны башкаручы затка, суд приставына, суд башкаручысына карата алдан һәрьяклап тикшерү алып баруга йә хөкем, суд карарын яисә башка суд актын үтәүгә бәйле рәвештә шундый ук гамәл кылган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган, затның авыр яисә аеруча авыр җинаять кылуда гаепләнүенә бәйле гамәлләр кылган өчен —

дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

299 статья. Гаепсез затны белә торып җинаять җаваплылыгына тарту

1. Гаепсез затны белә торып җинаять җаваплылыгына тарткан өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Затны авыр яисә аеруча авыр җинаять кылуда гаепләүгә бәйле шул ук гамәл өчен —

өч елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

300 статья. Җинаять җаваплылыгыннан законсыз азат итү

Җинаять кылуда шикле яисә гаепле затны прокурор, тикшерүче яисә алдан сорау алуны башкаручы зат җинаять җаваплылыгыннан законсыз азат иткән өчен —

ике елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

301 статья. Законсыз тоткарлау, сак астына алу яисә сак астында тоту

1. Белә торып законсыз тоткарлаган өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү

яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Белә торып законсыз рәвештә сак астына алган яисә сак астында тоткан өчен —

дүрт елга кадәр ирекләнгән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне авыр нәтиҗәләргә китереп кылган өчен —

өч елдан сигез елга кадәр ирекләнгән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

302 статья. Күрсәтмәләр бирүгә мәҗбүр итү

1. Тикшерүче яисә алдан сорау алуны башкаручы зат, шулай ук тикшерүче яисә алдан сорау алуны башкаручы затның күрәләтә яки сүзсез ризалыгы белән башка зат шикле затны, гаепләнүчене, зыян күрүче затны, шаһитны күрсәтмәләр бирүгә йә экспертны, белгечне бәяләмә яисә күрсәтмәләр бирүгә янау, шантаж яисә башка законсыз гамәлләр куллану юлы белән мәҗбүр иткән өчен —

өч елга кадәр ирекләнгән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Көч куллануга, мәсхәрәләүгә яисә җәберләүгә бәйле шул ук гамәл өчен —

ике елдан сигез елга кадәр ирекләнгән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

303 статья. Дәлилләрне фальсификацияләү

1. Граждан эше буенча эштә катнашучы зат яисә аның вәкиле дәлилләрне фальсификацияләгән өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике айдан дүрт айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Җинаять эше буенча алдан сорау алуны башкаручы зат, тикшерүче, прокурор яисә яклаучы дәлилләрне фальсификацияләгән өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, өч елга кадәр ирекләнгән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Авыр яисә аеруча авыр җинаять турында җинаять эше буенча дәлилләрне, шулай ук авыр нәтиҗәләргә китергән дәлилләрне фальсификацияләгән өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, өч елдан җиде елга кадәр ирекләнгән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

304 статья. Ришвәт алуга йә коммерциячел сатып алуга провокацияләү

Ришвәт алуга йә коммерциячел сатып алуга провокацияләгән, ягъни урындагы затка йә коммерциячел яисә башка оешмаларда идарә функцияләрен башкаручы затка аның ризалыгыннан башка акча, кыйммәтле кәгазьләр, башка мөлкәт тапшырырга тырышкан яисә аңа җинаять йә шантаж кылуда ясалма дәлилләр булдыру максатларында мөлкәти характердагы хезмәтләр күрсәткән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

305 статья. Белә торып гадел булмаган хөкем карары, суд карары яисә башка суд акты чыгару

1. Судья (судьялар) белә торып гадел булмаган хөкем карары, суд карары яисә башка суд акты чыгарган өчен —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Иректән мәхрүм итүгә карата законсыз хөкем карары чыгаруга бәйле яисә башка авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәл өчен —

өч елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

306 статья. Белә торып ялган әләк

1. Җинаять кылу турында белә торып ялган әләк җиткергән өчен —

йөз егерме мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Затны авыр яисә аеруча авыр җинаять кылуда гаепләүгә бәйле шул ук гамәл өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гаепләү дәлилләрен ясалма булдыруга бәйле гамәлләр өчен —

алты елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

307 статья. Белә торып ялган күрсәтмә бирү, эксперт, белгеч бәяләмәсе яисә дөрес тәрҗемә итмәү

1. Судта йә алдан һәрьяклап тикшерү барышында шаһит, зыян күрүче белә торып ялган күрсәтмә биргән йә эксперт белә торып ялган бәяләмә яки күрсәтмә биргән, белгеч белә торып ялган күрсәтмә биргән, шулай ук белә торып дөрес тәрҗемә итмәгән өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Затны авыр яисә аеруча авыр җинаять кылуда гаепләүгә бәйле шул ук гамәлләр өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Шаһит, зыян күрүче, эксперт, белгеч алдан сорау алу, алдан тикшерү яисә суд тикшерүе барышында ихтыяри рәвештә хөкем карары яисә суд карары чыгарылганчыга кадәр үзләре биргән күрсәтмәләрнең, бәяләмәнең яисә тәрҗемәче тәрҗемәнең дөрес түгеллеге турында хәбәр итсәләр, җинаять җаваплылыгыннан азат ителәләр.

308 статья. Шаһитның яисә зыян күрүченең күрсәтмәләр бирүдән баш тартуы

Шаһит яисә зыян күрүче күрсәтмәләр бирүдән баш тарткан өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Үзенә, үзенең иренә (хатынына) яисә үзенең башка якын туганнарына каршы күрсәтмәләр бирүдән баш тарткан өчен зат җинаять җаваплылыгына тартылмый.

309 статья. Күрсәтмәләр бирү яисә күрсәтмәләр бирүдән читләшү йә дөрес тәрҗемә итмәү өчен сатып алу яисә мәҗбүр итү

1. Шаһитны, зыян күрүчене ялган күрсәтмәләр бирү максатларында йә экспертны, белгечне аларга ялган бәяләмә яисә

ялган күрсәтмәләр бирү максатларында, шулай ук тәрҗемәчене дөрес тәрҗемә итмәү максатларында сатып алган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Шаһитны, зыян күрүчене ялган күрсәтмәләр бирүгә, экспертны, белгечне ялган бәяләмә бирүгә яисә тәрҗемәчене дөрес тәрҗемә итмәүгә мәҗбүр иткән, шулай ук күрсәтелгән затларны шантажга, үлем белән янауга, әлеге затларның яисә аларның якыннарының сәламәтлегенә зыян салуга, мөлкәтен юкка чыгаруга яисә зарарлауга бәйле күрсәтмәләр бирүдән читләшергә мәҗбүр иткән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның икенче өлешендә каралган гамәлне күрсәтелгән затларның гомерләре яисә сәламәтлекләре өчен куркыныч булмаган көч кулланып кылган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

4. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне оешкан төркем кылган йә күрсәтелгән затларның гомерләре яисә сәламәтлекләре өчен куркыныч көч кулланып кылган өчен —

өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

310 статья. Алдан һәрьяклап тикшерү белешмәләрен фаш итү

Алдан һәрьяклап тикшерү белешмәләрен фаш итүнең мөмкин түгеллеге турында законда билгеләнгән тәртиптә кисәтелгән зат аларны фаш иткән өчен, әгәр ул прокурор, тикшерүче яисә алдан сорау алуны башкаручы зат ризалыгыннан тыш башкарылса, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

311 статья. Судьяга һәм җинаять процессында катнашучыларга карата кулланыла торган иминлек чаралары турындагы белешмәләрне фаш итү

1. Судьяга, присяжный утырышчыга яисә хөкем итүдә кат-

нашучы башка затка, суд приставына, суд башкаручысына, зыян күрүчегә, шаһитка, җинаять процессында башка катнашучыларга карата, шулай ук аларның якыннарына карата кулланыла торган иминлек чаралары турындагы белешмәләрне фаш иткән өчен, әгәр бу гамәл әлеге белешмәләр ышанып тапшырылган яисә хезмәт эшчәнлегенә бәйле рәвештә мәгълүм булган зат тарафыннан башкарылса, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

312 статья. Опись ясалган яисә арест салынган йә конфискацияләнергә тиешле мөлкәткә карата законсыз гамәлләр

1. Опись ясалган яисә арест салынган мөлкәт тапшырылган зат шул мөлкәтне сарыф иткән, читләштергән, яшергән яисә законсыз тапшырган, шулай ук кредит оешмасы хезмәткәре арест салынган акча (кертемнәр) белән банк операцияләре башкарган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Хөкем карары буенча конфискацияләнергә тиешле мөлкәтне яшергән яисә үзләштергән, шулай ук мөлкәтне конфискацияләүне билгеләү турында законлы көченә кергән хөкем карарын үтәүдән башкача читләшкән өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, сиксән мең сумга кадәр яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып, өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

313 статья. Иректән мәхрүм итү, кулга алу яисә сак астында тоту урыныннан качу

1. Җәза узучы яисә алдан ябылып тоту урынындагы зат иректән мәхрүм итү, кулга алу яисә сак астында тоту урыныннан качкан өчен —

өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем кылган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне гомер яисә сәламәтлек өчен куркыныч көч кулланып йә шундый көч куллану белән янап, шулай ук корал яисә корал сыйфатында файдаланылучы предметлар кулланып кылган өчен —

сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

314 статья. Иректән мәхрүм ителүдән читләшү

Иректән мәхрүм итү урыныннан читкә чыгу рөхсәт ителгән йә хөкем карарын үтәү яисә җәза узу урыныннан кичектерү бирелгән зат читкә чыгу яисә кичектерү вакыты беткәннән соң урынына кайтмаган өчен —

ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

315 статья. Судның хөкем карарын, суд карарын яисә башка суд актын үтәмәү

Хакимият вәкиле, дәүләт хезмәткәре, җирле үзидарә органы хезмәткәре, шулай ук дәүләт яисә муниципаль учреждение, коммерция яисә башка оешма хезмәткәре судның үз законлы көченә кергән хөкем карарын, суд карарын яисә бүтән суд актын явыз ният белән үтәмәгән өчен, шулай ук аларны үтәүгә каршылык күрсәткән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә биш елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

316 статья. Җинаятьләрне яшереп калу

Аеруча авыр җинаятьләрне алдан ышандырмыйча яшереп калган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Үзенең ире (хатыны) яисә якын туганы кылган җинаятьне алдан ышандырмыйча яшереп калган зат җинаять җаваплылыгына тартылмый.

32 бүлек. Идарә итү тәртибенә каршы җинаятьләр

317 статья. Хокук саклау органы хезмәткәре гомеренә кул сузу

Хокук саклау органы хезмәткәре, хәрби хезмәткәр, шулай ук аларның якыннары гомеренә аларның иҗтимагый тәртипне саклау һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итү буенча законлы эшчәнлегенә каршы килү максатларында йә шундый эшчәнлеккә үч итү йөзеннән кул сузган өчен —

унике елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү, йә гомерлеккә иректән мәхрүм итү, йә үлем җәзасы рәвешендә җәза бирелә.

318 статья. Хакимият вәкиленә карата көч куллану

1. Хакимият вәкиленә яисә аның якыннарына карата хезмәт вазифаларын үтәүгә бәйле рәвештә гомер яисә сәламәтлек өчен куркыныч булмаган көч кулланган йә көч куллану белән янаган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән затларга карата гомерләре яисә сәламәтлекләре өчен куркыныч көч кулланган өчен —

биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге Кодексның бу статьясында һәм башка статьяларында хакимият вәкиле дип хокук саклау яисә тикшереп тору органының урындагы заты, шулай ук законда билгеләнгән тәртиптә аның буйсынуында булмаган затларга карата боеру вәкаләтләре бирелгән урындагы зат таныла.

319 статья. Хакимият вәкилен хурлау

Хакимият вәкилен хезмәт вазифаларын үтәгәндә яисә аларны үтәүгә бәйле рәвештә халык алдында хурлаган өчен —

кырык мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз егерме сәгатьтән йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айдан бер елга кадәр төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирелә.

320 статья. Хокук саклау яисә контрольдә тоту органының урындагы затына карата кулланыла торган иминлек чаралары турындагы белешмәләрне фаш итү

1. Хокук саклау яисә контрольдә тоту органының урындагы затына, шулай ук аларның якыннарына карата кулланыла торган иминлек чаралары турындагы белешмәләрне фаш иткән өчен, әгәр бу гамәл аның хезмәт эшчәнлегенә каршылык күрсәтү максатларында башкарылган булса, —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә дүрт айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

321 статья. Җәмгыятьтән изоляцияләүне тәэмин итүче учреждениеләр эшчәнлеген таркату

1. Хөкем ителгән затны төзәтүгә каршылык күрсәтү максатларында яисә учреждение яки җинаять-башкару системасы органы администрациясенә аңа ярдәм күрсәткән өчен үч алу максатында хөкем ителгән затның гомере яисә сәламәтлеге өчен куркыныч булмаган көч кулланган йә аңа каршы көч куллану белән янаган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлләрне иректән мәхрүм итү яисә сак астында тоту урыны хезмәткәренә карата аның яисә якыннарының хезмәт эшчәнлеген башкаруга бәйле рәвештә кылган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне оешкан төркем йә гомере яисә сәламәтлеге өчен көч кулланып кылган гамәл өчен —

биш елдан унике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

322 статья. Россия Федерациясе Дәүләт чиген законсыз үтү

1. Россия Федерациясе Дәүләт чиген Россия Федерациясенә керү яисә Россия Федерациясеннән чыгу хокукына тиешле документлардан йә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алынган тиешле рөхсәттән башка үткән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Россия Федерациясе Дәүләт чиген алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем йә, көч кулланып яисә көч куллану белән янап, законсыз үткән өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.
Искәрмә. Әлеге статья Россия Федерациясенә Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә сәяси сыену хокукыннан файдалану өчен, әгәр әлеге затларның гамәлләрендә бүтән җинаять составы булмаса, Россия Федерациясенең Дәүләт чиген үтү кагыйдәләрен бозып килгән чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларына кагылмый.

322.1 статья. Законсыз миграция оештыру

Чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның Россия Федерациясенә законсыз үтеп керүләрен, аларның Россия Федерациясендә законсыз булуларын яисә Россия Федерациясе территориясе аша законсыз транзит үтүләрен оештырган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә алты айдан бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) оешкан төркем;

б) Россия Федерациясе территориясендә җинаять кылу максатында —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, ике елдан биш елга кадәр ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

323 статья. Россия Федерациясе Дәүләт чиген хокукка каршы килеп үзгәртү

1. Россия Федерациясе Дәүләт чиген хокукка каршы килеп үзгәртү максатында чик буе тамгаларын алып ташлаган, күчереп куйган яисә юкка чыгарган өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәлләр өчен —

дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

324 статья. Рәсми документларны һәм дәүләт бүләкләрен юнәтү яки сату

Хокук бирә яисә вазифалардан азат итә торган рәсми документларны, шулай ук Россия Федерациясе, РСФСР, СССР дәүләт бүләкләрен законсыз юнәткән яисә саткан өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән зат-

ның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яисә бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

325 статья. Документлар, штамплар, мөһерләр урлау яисә зарарлау йә акциз җыемнары маркаларын, махсус маркаларны яисә тәңгәллек тамгаларын урлау

1. Астыртын ниятгә яисә бүтән шәхси кызыксыну максатыннан чыгып, рәсми документларны, штампларны яисә мөһерләрне урлаган, юкка чыгарган, зарарлаган яисә яшергән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә дүрт айга кадәр кулга алу, йә бер елга кадәр ирекгән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Гражданның паспортын яисә башка мөһим шәхси документын урлаган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

3. Охшатып ясаудан якланган акциз җыемнары маркаларын, махсус маркаларны яисә тәңгәллек тамгаларын урлаган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә ике елга кадәр ирекгән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

326 статья. Транспорт чарасының идентефикация номерын охшатып ясау яисә юкка чыгару

1. Транспорт чарасын эксплуатацияләү яисә сату максатларында транспорт чарасының кузов, шасси, двигатель номерын, шулай ук дәүләт теркәве тамгасын охшатып ясаган яисә идентефикация номерын юкка чыгарган өчен, шулай ук транспорт чарасын белә торып ялган идентефикация номеры, кузов, шасси, двигатель номеры яисә белә торып ялган дәүләт теркәү тамгасы белән саткан йә кузовны, шассины, двигательне белә торып охшатып ясалган номер белән саткан өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә бер елга кадәр төзәтү эшләре, йә ике елга кадәр ирекне чикләү, йә ике елга кадәр ирекгән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем кылган өчен —

ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

327 статья. Ялган документларны, дәүләт бүләкләрен, штампларны, мөһерләрне, бланкларны охшатып ясау, әзерләү яисә сату

1. Вазифалар башкаруга хокук бирә торган яисә вазифалардан азат итә торган таныклык яисә башка рәсми документны аннан файдалану йә сату максатларында охшатып ясаган, шулай ук шундый ук максатларда охшатып ясалган Россия Федерациясе, РСФСР, СССР дәүләт бүләкләрен, штампларны, мөһерләрне, бланкларны әзерләгән яисә саткан өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне башка җинаятьне яшереп калу яисә аны кылуны җиңеләйтү максатларында кылган өчен —

дүрт елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Күрәләтә ялган документтан файдаланган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

327.1 статья. Охшатып ясалган акциз җыемнары маркаларын, махсус маркаларны яисә тәңгәллек тамгаларын әзерләү, сату йә алардан файдалану

1. Охшатып ясалган акциз җыемнары маркаларын, махсус маркаларны яисә охшатып ясалудан сакланган тәңгәллек тамгаларын сату максатларында әзерләгән яисә саткан өчен —

йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Белә торып охшатып ясалган акциз җыемнары маркаларыннан, махсус маркалардан яисә охшатып ясаудан сакланган тәңгәллек тамгаларыннан файдаланган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

328 статья. Хәрби хезмәт һәм альтернатив граждан хезмәте узудан читләшү

1. Хәрби хезмәткә чакырылудан, әлеге хезмәттән азат ителү өчен законлы нигезләр булмаганда, читләшкән өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Хәрби хезмәттән азат ителгән затлар альтернатив граждан хезмәте узудан читләшкән өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

329 статья. Россия Федерациясе Дәүләт гербын яисә Россия Федерациясе Дәүләт флагын мәсхәрәләү

Россия Федерациясе Дәүләт гербын яисә Россия Федерациясе Дәүләт флагын мәсхәрәләгән өчен —

ике елга кадәр ирекне чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә бер елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

330 статья. Башбаштаклык

1. Башбаштаклык, ягъни законда яисә башка норматив хокукый актта билгеләнгән тәртипкә каршы килеп, законлылыгы оешма яисә граждан тарафыннан дәгъвалана торган теләсә нинди гамәл кылган өчен, әгәр бу гамәлләр җитди зыян китерсә, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә йөз сиксән сәгатьтән ике йөз кырык сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр, йә бер елдан ике елга кадәр төзәтү эшләре, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне көч кулланып яисә көч куллану белән янап кылган өчен —

өч елга кадәр ирекне чикләү, йә дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

XI кисәк. Хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр

33 бүлек. Хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр

331 статья. Хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр төшенчәсе

1. Хәрби хезмәт узуның әлеге бүлектә каралган билгеләнгән тәртибен бозуга каршы Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә, Россия Федерациясенең башка гаскәрләрендә һәм хәрби формированиеләрендә чакыру буенча йә контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр тарафыннан, шулай ук запастагы гражданнар тарафыннан алар хәрби җыеннар узган вакытта кылган җинаятьләр хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр дип таныла.

2. Әлеге бүлек статьялары нигезендә Россия Федерациясе Оборона министрлыгы, Россия Федерациясенең башка министрлыклары һәм ведомстволары хәрби-төзелеш отрядларының (частьларының) хәрби төзүчеләре җинаять җаваплылыгына тартыла.

3. Сугыш вакытында йә хәрби вазгыятьтә хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр өчен җинаять җаваплылыгы Россия Федерациясенең сугыш вакытындагы законнары белән билгеләнә.

332 статья. Боерыкны үтәмәү

1. Билгеләнгән тәртиптә башлык биргән боерыкны буйсынучы хезмәт мәнфәгатьләренә җитди зыян китерерлек итеп үтәмәгән өчен —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем, шулай ук авыр нәтиҗәләргә китерерлек итеп кылган өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Боерыкны хезмәткә карата сакчыл булмаган йә намуссыз мөнәсәбәт аркасында авыр нәтиҗәләргә китерерлек итеп үтәмәгән өчен —

бер елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә өч айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту рәвешендә җәза бирелә.

333 статья. Башлыкка каршы килү яисә аны хәрби хезмәт вазифаларын бозуга мәҗбүр итү

1. Башлыкка, шулай ук хәрби хезмәт вазифаларын үтәү йөкләнгән бүтән затка каршы килгән яисә аны, көч кулланып

яисә көч куллану белән янап, әлеге вазифаларны бозуга мәҗбүр иткән өчен —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем;

б) корал кулланып;

в) сәламәтлеккә зур яисә уртача зыян салып яисә башка авыр нәтиҗәләргә китереп —

өч елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

334 статья. Башлыкка каршы көч куллану гамәлләре

1. Башлыкны хәрби хезмәт вазифаларын үтәү вакытында яисә әлеге вазифаларны үтәүгә бәйле рәвештә кыйнаган яисә башка төрле көч кулланган өчен —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне түбәндәгечә кылган өчен:

а) затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем;

б) корал кулланып;

в) сәламәтлеккә зур яисә уртача зыян салып яисә башка авыр нәтиҗәләргә китереп —

өч елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

335 статья. Хәрби хезмәткәрләр арасында үзара буйсыну мөнәсәбәтләре булмаганда, үзара мөнәсәбәтләрнең устав кагыйдәләрен бозу

1. Хәрби хезмәткәрләр арасында үзара буйсыну мөнәсәбәтләре булмаганда, намусны һәм абруйны кимсетүгә яисә зыян күрүчене җәберләүгә йә көч куллануга бәйле рәвештә үзара мөнәсәбәтләрнең устав кагыйдәләрен бозган өчен —

ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту яисә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлне түбәндәгечә кылган өчен:

а) *үз көчен югалтты;*

б) ике яисә аннан күбрәк затка карата;

в) затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем;

г) корал кулланып;

д) сәламәтлеккә зур яисә уртача зыян салып —
биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.
3. Әлеге статьяның беренче яисә икенче өлешләрендә каралган гамәлләрне авыр нәтиҗәләргә китереп кылган өчен —
ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

336 статья. Хәрби хезмәткәрне хурлау
1. Хәрби хезмәт вазифаларын үтәгән вакытта яисә үтәүгә бәйле рәвештә бер хәрби хезмәткәр икенче хәрби хезмәткәрне хурлаган өчен —
алты айга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү яисә шул ук срокка дисциплинар хәрби частьта тоту рәвешендә җәза бирелә.
2. Хәрби хезмәт вазифаларын үтәгән вакытта яисә үтәүгә бәйле рәвештә буйсынучы башлыкны хурлаган, шулай ук башлык буйсынучыны хурлаган өчен —
бер елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү яисә шул ук срокка дисциплинар хәрби частьта тоту рәвешендә җәза бирелә.

337 статья. Частьны яисә хезмәт урынын башбаштакланып ташлап китү
1. Частьны яисә хезмәт урынын башбаштакланып ташлап киткән, шулай ук нигезле сәбәпләр булмыйча частьтан киткәндә, билгеләнеп куелганда, күчерелгәндә, командировкадан кайтканда, отпусктан яисә дәвалау учреждениесеннән кайтканда ике тәүлектән артык, ләкин ун тәүлектән дә озаграк булмаган вакыт кире кайтмаган өчен чакыру буенча хәрби хезмәт уза торган хәрби хезмәткәрләргә —
алты айга кадәр кулга алу яисә бер елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту рәвешендә җәза бирелә.
2. Шул ук гамәлләрне дисциплинар хәрби частьта җәза узучы хәрби хезмәткәр кылган өчен —
ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.
3. Частьны яисә хезмәт урынын башбаштакланып ташлап киткән, шулай ук нигезле сәбәпләр булмыйча ун тәүлектән артык, ләкин бер айдан да озаграк булмаган вакыт кире кайтмаган өчен чакыру яисә контракт буенча хәрби хезмәт уза торган хәрби хезмәткәрләргә —
ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.
4. Әлеге статьяның өченче өлешендә каралган гамәлләрне бер айдан озаграк итеп кылган өчен —
биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.
Искәрмә. Әлеге статьяда каралган гамәлләрне беренче тапкыр кылган хәрби хезмәткәрнең частьтан башбаштакланып

китүе авыр сәбәпләргә бәйле булса, ул җинаять җаваплылыгыннан азат ителергә мөмкин.

338 статья. Дезертирлык

1. Дезертирлык, ягъни хәрби хезмәт узудан читләшү максатларында частьтан яисә хезмәт урыныннан башбаштакланып киткән, шулай ук хезмәт урынына шул ук максатларда килмәгән өчен —

җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Хезмәт буенча ышанып тапшырылган корал белән дезертирлык иткән, шулай ук алдан килешенгән затлар төркеме яисә оешкан төркем дезертирлык иткән өчен —

өч елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган дезертирлыкны беренче тапкыр кылган хәрби хезмәткәр, әгәр аны авыр сәбәпләр аркасында кылса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителергә мөмкин.

339 статья. Хәрби хезмәт вазифаларын үтәүдән авыруга сабышып яисә башка алымнар белән читләшү

1. Хәрби хезмәткәр хәрби хезмәт вазифаларын үтәүдән авыруга сабышу яисә үзенә нинди дә булса зыян салу юлы белән (әгъзасына зыян китерү) яисә ялган документлар яки башка төрле алдау юлы белән читләшкән өчен —

бер елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә бер елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту рәвешендә җәза бирелә.

2. Хәрби хезмәт вазифаларын үтәүдән тулысынча азат ителү максатларында шул ук гамәлне кылган өчен —

җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

340 статья. Хәрби дежур тору кагыйдәләрен бозу

1. Россия Федерациясенә кинәт һөҗүм итүне вакытында ачыклау һәм чагылдыру йә аның иминлеген тәэмин итү буенча хәрби дежур тору (хәрби хезмәт) кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр бу гамәл дәүләт иминлеге мәнфәгатьләренә зыян китерсә яисә зыян китерү ихтималы булса, —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәл өчен —

ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Хәрби дежур тору (хәрби хезмәт) кагыйдәләрен саксыз яисә намуссыз мөнәсәбәт аркасында авыр нәтиҗәләргә китерерлек итеп бозган өчен —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә өч елга кадәр ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

341 статья. Чик буе хезмәтен узу кагыйдәләрен бозу

1. Чик буе наряды составына керүче яисә чик буе хезмәтенең башка вазифаларын үтәүче зат чик буе хезмәтен узу кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр бу гамәл дәүләт иминлеге мәнфәгатьләренә зыян китерсә яисә зыян китерү ихтималы булса, —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә өч елга кадәр ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Чик буе хезмәтен узу кагыйдәләрен саксыз яисә намуссыз мөнәсәбәт аркасында авыр нәтиҗәләргә китерерлек итеп бозган өчен —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә ике елга кадәр ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

342 статья. Каравыл хезмәтенең устав кагыйдәләрен бозу

1. Каравыл (вахта) составына керүче зат каравыл (вахта) хезмәтенең устав кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр бу гамәл каравыл (вахта) белән саклана торган объектларга зыян китерсә, —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә ике елга кадәр ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәл өчен —

өч елга кадәр ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Каравыл (вахта) хезмәте кагыйдәләрен саксыз яисә намуссыз мөнәсәбәт аркасында авыр нәтиҗәләргә китерерлек итеп бозган өчен —

бер елга кадәр ирektән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

343 статья. Җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү хезмәтен узу кагыйдәләрен бозу

1. Җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү буенча хәрби наряд составына керүче зат хезмәт узу кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр бу гамәл гражданнарның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә зыян китерсә, —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

344 статья. Эчке хезмәт узу һәм гарнизонда патрульлек итүнең устав кагыйдәләрен бозу

Частьның тәүлеклек нарядына керүче зат (каравыл һәм вахтадан тыш) эчке хезмәт узуның устав кагыйдәләрен бозган, шулай ук патруль наряды составына керүче зат гарнизонда патрульлек итү кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр бу гамәлләр авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту рәвешендә җәза бирелә.

345 статья. Һәлакәткә юлыккан хәрби корабльне ташлап китү

Үз хезмәт вазифаларын ахыргача үтәмәгән хәрби корабль командиры, шулай ук командирның тиешле әмере булмаган килеш корабль командасы составы заты һәлакәткә юлыккан хәрби корабльне ташлап киткән өчен —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

346 статья. Хәрби мөлкәтне аңлы рәвештә юкка чыгару яисә зарарлау

1. Коралны, сугыш кирәк-яракларын яисә хәрби техника предметларын аңлы рәвештә юкка чыгарган яисә зарарлаган өчен —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә өч айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Авыр нәтиҗәләргә китергән шул ук гамәлләр өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

347 статья. Хәрби мөлкәтне саксызлык аркасында юкка чыгару яисә зарарлау

Коралны, сугыш кирәк-яракларын яисә хәрби техника пред-

метларын саксызлык аркасында юкка чыгарган яисә зарарлаган өчен —

ике йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның унсигез айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

348 статья. Хәрби мөлкәтне югалту

Хезмәттә файдалану өчен ышанып тапшырылган коралны, сугыш кирәк-яракларын яисә хәрби техника предметларын саклау кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр бу саксызлык аркасында аларның югалуына китерсә, —

сиксән мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның алты айга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф, йә ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү, йә алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту, йә ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

349 статья. Тирә-юньдәгеләр өчен аеруча куркыныч корал һәм предметлар белән эш итү кагыйдәләрен бозу

1. Тирә-юньдәгеләр өчен аеруча куркыныч булган корал, сугыш кирәк-яраклары, радиоактив материаллар, шартлаткыч яисә башка матдәләр һәм предметлар белән эш итү кагыйдәләрен бозган өчен, әгәр бу саксызлык аркасында кешенең сәламәтлегенә зур зыян салуга, хәрби техниканы юкка чыгаруга йә башка авыр нәтиҗәләргә китерсә, —

ике елга кадәр хәрби хезмәт буенча чикләү яисә ике елга кадәр дисциплинар хәрби частьта тоту рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлне саксызлык аркасында ике яисә аннан күбрәк затның үлеменә китереп кылган өчен —

ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

350 статья. Машина йөртү яисә эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу

1. Хәрби, махсус яисә транспорт машинасын йөртү кагыйдәләрен саксызлык аркасында кешенең сәламәтлегенә зур зыян салырлык итеп бозган өчен —

дүрт айдан алты айга кадәр кулга алу, йә ике елга кадәр

дисциплинар хәрби частьта тоту, йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, ике елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Саксызлык аркасында кеше үлеменә китергән шул ук гамәл өчен —

өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп яисә аннан башка, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган гамәлне саксызлык аркасында ике яисә аннан күбрәк затның үлеменә китереп кылган өчен —

җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

351 статья. Очыш яисә аңа әзерлек кагыйдәләрен бозу

Очыш яисә аңа әзерлек кагыйдәләрен йә хәрби очу аппаратларын эксплуатацияләүнең башка кагыйдәләрен саксызлык аркасында кеше үлеменә йә башка авыр нәтиҗәләргә китерерлек итеп бозган өчен —

җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

352 статья. Корабль йөртү кагыйдәләрен бозу

Хәрби корабльләр йөртү яисә эксплуатацияләү кагыйдәләрен саксызлык аркасында кеше үлеменә йә башка авыр нәтиҗәләргә китерерлек итеп бозган өчен —

җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

XII кисәк. Тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә каршы җинаятьләр

34 бүлек. Тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә каршы җинаятьләр

353 статья. Агрессив сугышны планлаштыру, әзерләү, башлау яисә алып бару

1. Агрессив сугышны планлаштырган, әзерләгән яисә башлаган өчен —

җиде елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Агрессив сугыш алып барган өчен —

ун елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

354 статья. Агрессив сугыш башлауга ачыктан-ачык өндәүләр

1. Агрессив сугыш башлауга ачыктан-ачык өндәгән өчен —

өч йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның ике елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә өч елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Шул ук гамәлләрне массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдаланып кылган йә Россия Федерациясенең дәүләт вазифасын яисә Россия Федерациясе субъектының дәүләт вазифасын биләүче зат кылган өчен —

йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның бер елдан өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф йә, өч елга кадәр аерым эш урыннарын биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итеп, биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

355 статья. Күпләп юк итү коралын эшләү, җитештерү, туплау, юнәтү яисә сату

Химик, биологик, агулы һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе белән тыелган башка төрле күпләп юк итү коралын эшләгән, җитештергән, туплаган, юнәткән яисә саткан өчен —

биш елдан ун елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

356 статья. Сугыш алып баруның тыелган чараларын һәм ысулларын куллану

1. Басып алган территориядә хәрби әсирләр яисә гражданнар белән рәхимсез мөнәсәбәттә булган өчен, гади халыкны депортацияләгән, милли мөлкәтне талаган, хәрби конфликтта Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре белән тыелган чаралар һәм ысуллар кулланган өчен —

егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе белән тыелган күпләп юк итү коралын кулланган өчен —

ун елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

357 статья. Геноцид

Милли, этник, раса яисә дини төркемне әлеге төркем әгъзаларын үтерү юлы белән тулысынча яисә өлешчә юкка чыгаруга, аларның сәламәтлегенә зур зыян салуга, бала тудыруга

көч кулланып каршы килүгә, балаларны мәҗбүри тапшыруга, көч кулланып күченүгә, йә әлеге төркем әгъзаларын физик яктан юкка чыгаруга исәп тотылган башка төрле яшәү шартлары тудыруга юнәлдерелгән гамәлләр өчен —

унике елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү, йә гомерлеккә иректән мәхрүм итү, йә үлем җәзасы рәвешендә җәза бирелә.

358 статья. Экоцид

Үсемлекләр яисә хайваннар дөньясын күпләп юкка чыгарган, атмосфераны яисә су ресурсларын агулаган, шулай ук экологик бәла-каза китерергә сәләтле башка гамәлләр кылган өчен —

унике елдан егерме елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

359 статья. Яллау

1. Ялланучыны вербовкалаган, өйрәткән, финанслаган яисә башкача матди тәэмин иткән өчен, шулай ук аны хәрби конфликтта яисә хәрби гамәлләрдә файдаланган өчен —

дүрт елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Үзенең хезмәт урыныннан файдаланып яисә балигъ булмаган затка карата кылган шул ук гамәл өчен —

биш йөз мең сумга кадәр күләмдә яисә хөкем ителгән затның өч елга кадәр чордагы хезмәт хакы яки бүтән кереме күләмендә штраф салып йә аннан башка, җиде елдан унбиш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

3. Ялланучы хәрби конфликтта яисә хәрби гамәлләрдә катнашкан өчен —

өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Искәрмә. Матди бүләк алу максатларында эш итүче, хәрби конфликтта яисә хәрби гамәлләрдә катнашучы, дәүләтнең гражданы булып тормаган, аның территориясендә даими яшәмәүче, шулай ук рәсми вазифалар башкару йөкләнмәгән зат ялланучы дип таныла.

360 статья. Халыкара яклаудан файдаланучы затларга яисә учреждениеләргә һөҗүм итү

1. Халыкара яклаудан файдаланучы чит ил вәкиленә яисә халыкара оешма хезмәткәренә, шулай ук халыкара яклаудан файдаланучы затларның хезмәт яисә торак биналарына йә транспорт чараларына һөҗүм иткән өчен —

биш елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

2. Сугышны провакацияләү яисә халыкара мөнәсәбәтләрне катлауландыру максатларында шул ук гамәлне кылган өчен — өч елдан җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза бирелә.

Россия Федерациясе
Президенты Б.Ельцин

Мәскәү, Кремль
1996 елның 13 июне
№ 63-ФЗ

«Россия Федерациясе Җинаять кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль закон

1996 елның 13 июнендәге 64-ФЗ номерлы

(1996 елның 27 декабрендәге, 2002 елның 10 гыйнварындагы, 2003 елның 8 декабрендәге үзгәрешләр белән)

Дәүләт Думасы тарафыннан 1996 елның 24 маенда кабул ителде

Федерация Советы тарафыннан 1996 елның 5 июнендә хупланды

1 статья. Россия Федерациясе Җинаять кодексын, әлеге Федераль закон белән гамәлгә кертүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, 1997 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

2 статья. 1997 елның 1 гыйнварыннан «РСФСР Җинаять кодексын раслау турында» 1960 елның 27 октябрендәге РСФСР Законы белән расланган РСФСР Җинаять кодексының, шулай ук 1960 елның 27 октябреннән 1997 елның 1 гыйнварына кадәрге чорда кабул ителгән барлык законнарның һәм норматив хокукый актларның РСФСР Җинаять кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өлешләрендә үз көчләрен югалтуын танырга.

Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган башка законнар һәм бүтән норматив хокукый актлар Россия Федерациясе Җинаять кодексына туры китерелергә тиеш.

Россия Федерациясе Җинаять кодексына туры китергәнгә кадәр әлеге законнар һәм башка норматив хокукый актлар Россия Федерациясе Җинаять кодексына каршы килми торган өлешләрендә кулланылалар. Суд карары буенча конфискацияләнми торган мөлкәт исемлеге (РСФСР Җинаять кодексына кушымта) Россия Федерациясе Җинаять кодексының 52 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Россия Федерациясе җинаять-башкару законнарында каралган яңа исемлекне раслаганчы кулланыла.

Суд карары буенча конфискацияләнми торган мөлкәт исемлеге 1997 елның 1 июленнән гамәлгә кертелгән 1997 елның 8 гыйнварындагы 1-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җинаять-башкару кодексының беренче кушымтасында бирелә.

3 статья. 1960 елгы РСФСР Җинаять кодексы буенча 1997 елның 1 гыйнварына кадәр 1996 елгы Россия Федерациясе Җинаять кодексы нигезендә җинаять дип танылмый торган гамәлләр өчен хөкем ителгән затларны җәзадан (төп һәм өстәмә) азат итәргә.

Элек гамәлдә булган җинаять законы буенча хөкем ителгән һәм җәза узмаган затларга җәза чараларын, суд тарафыннан аларга бирелгән җәза Россия Федерациясе Җинаять кодексының тиешле статьясындагы санкциянең иң югары чигеннән катырак итеп билгеләнгән очракларда, Россия Федерациясе Җинаять кодексына туры китерергә.

Әгәр җинаять законы җинаять кылган затларның, шул исәптән җәза узучы яисә җәза узган, әмма хөкем ителүе алынмаган затларның хәлен яхшыртса, суд карарлары һәм җинаятихокукый характердагы бүтән чараларны куллану турында башка суд актлары хөкем карарын чыгарган суд тарафыннан яисә хөкем ителгән зат җәза уза торган урындагы суд тарафыннан кабат каралырга тиеш.

Җинаять кылган затларны әлеге статьяның беренче, икенче һәм өченче өлешләрендә каралган очракларда җәзадан азат итү, аларга җәзаны йомшарту, аларның хәлләрен башкача яхшырту РСФСР Җинаять-процессуаль кодексының 361.1, 368 һәм 369 статьяларында каралган тәртиптә башкарыла.

Әлеге статьяның беренче һәм өченче өлешләре нигезендә җәза узудан азат ителүче затларның, шулай ук элек җәза узган яисә шартлы-вакытыннан алда азат ителгән затларның, әгәр алар Россия Федерациясе Җинаять кодексы нигезендә җинаять дип танылмый торган гамәлләр өчен хөкем ителгән булса, хөкем ителүләре юк дип санала.

Судлар, алдан тикшерү органнары һәм башлап сорау алу органнары каравында торучы, Россия Федерациясе Җинаять кодексы нигезендә җинаять дип танылмый торган гамәлләр турындагы җинаять эшләрен, шулай ук җинаять җаваплылыгына тартуның Россия Федерациясе Җинаять кодексындагы 78 статьяның беренче өлешендәге «а» пунктында билгеләнгән дәгъвалау чоры узган җинаять эшләрен 1997 елның 1 гыйнварыннан туктатырга.

4 статья. Әлеге Кодексның мәҗбүри эшләр, ирекне чикләү һәм кулга алу рәвешендәге җәзалар турындагы нигезләмәләре Россия Федерациясе Җинаять-башкару кодексы үз көченә кергәннән соң, әлеге җәза төрләрен үтәү өчен тиешле шартлар тудырылгач, әмма мәҗбүри эшләр рәвешендәге җәза турында — 2004 елдан соңга калмыйча, ирекне чикләү рәве-

шендәге җәза турында — 2005 елдан соңга калмыйча, кулга алу рәвешендәге җәза турында — 2006 елдан да соңга калмыйча, федераль закон яисә федераль законнар белән гамәлгә кертелә.

5 статья. Эш урыныннан азат итү (РСФСР Җинаять кодексының 21 статьясы 5 пункты), китерелгән зыянны бетерү вазифаларын йөкләү (РСФСР Җинаять кодексының 21 статьясы 6 пункты), җәмәгатьчелек шелтәсе белдерү (РСФСР Җинаять кодексының 21 статьясы 7 пункты) рәвешендәге җәзага хөкем ителгән затлар, хөкем карарын чыгарган суд тарафыннан аларның хөкем ителүен юкка чыгарып, җәза узудан азат ителәләр.

6 статья. Иректән мәхрүм итмичә, төзәтү эшләре рәвешендәге җәзага хөкем ителеп, аны эш урыныннан читтә узучы затларга (РСФСР Җинаять кодексының 27 статьясы) әлеге җәза хөкем карарын чыгарган суд яисә хөкем ителгән зат җәза уза торган урындагы суд тарафыннан дәүләт кеременә тотылырга тиешле сумма күләмендә штраф рәвешендәге җәзага алмаштырыла. Россия Федерациясе Җинаять кодексы гамәлгә кергән вакытка түләнгән сумма исәпкә алынырга тиеш. Билгеләнгән штраф мондый очракта Россия Федерациясе Җинаять кодексының тиешле статьясында каралган штрафның максималь күләменнән артмаска тиеш.

7 статья. РСФСР Җинаять кодексының 24.1 статьясы нигезендә аеруча куркыныч рецидивистлар дип танылган затлар махсус режимдагы хезмәт белән төзәтү колонияләрендә иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәза узалар.

8 статья. Россия Федерациясе Җинаять кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында федераль законнар проектлары Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына бары тик Россия Федерациясе Хөкүмәтенең һәм Россия Федерациясе Югары Судының рәсми бәяләмәләре булганда гына кертелергә мөмкин.

Россия Федерациясе
Президенты — Б.Ельцин

Мәскәү, Кремль
1996 елның 13 июне
№ 64-ФЗ

ЭЧТӘЛЕК

Россия Федерациясе Җинаять кодексы

ГОМУМИ ӨЛЕШ

I кисәк. Җинаять законы

1 бүлек. Россия Федерациясе Җинаять кодексының бурычлары һәм принциплары

1 статья. Россия Федерациясе җинаять законнары 3
2 статья. Россия Федерациясе Җинаять кодексының бурычлары 3
3 статья. Законлылык принцибы 4
4 статья. Гражданнарның закон каршында тигезлек принцибы 4
5 статья. Гаепләү принцибы 4
6 статья. Гаделлек принцибы 4
7 статья. Гуманизм принцибы 4
8 статья. Җинаять җаваплылыгы өчен нигез 4

2 бүлек. Җинаять законының гамәлдә булу вакыты һәм даирәсе

9 статья. Җинаять законының гамәлдә булу вакыты 5
10 статья. Җинаять законының кире көчкә ия булуы 5
11 статья. Россия Федерациясе территориясендә җинаять кылган затларга карата җинаять законының гамәлдә булуы 5
12 статья. Россия Федерациясеннән читтә җинаять кылган затларга карата җинаять законының гамәлдә булуы 6
13 статья. Җинаять кылган затларны тапшыру 6

II кисәк. Җинаять

3 бүлек. Җинаять төшенчәсе һәм җинаять төрләре

14 статья. Җинаять төшенчәсе 7
15 статья. Җинаять категорияләре 7
16 статья. *Үз көчен югалтты.* 7
17 статья. Җинаятьләр җыелмасы 7
18 статья. Җинаятьләр рецидивы 8

4 бүлек. Җинаять җаваплылыгына тартылырга тиешле затлар

19 статья. Җинаять җаваплылыгының төп шартлары 9
20 статья. Җинаять җаваплылыгы башлана торган яшь 9
21 статья. Үз акылында булмау 10
22 статья. Психикасы үз акылына зыян китермәслек итеп какшаган затларның җинаять җаваплылыгы 10
23 статья. Исерек килеш җинаять кылган затларның җинаять җаваплылыгы 10

5 бүлек. Гаеп

24 статья. Гаеп рәвешләре 10
25 статья. Аңлы рәвештә кылган җинаять 10

26 статья. Саксызлык аркасында кылган җинаять 11
27 статья. Ике төрле гаебе булган җинаять кылган өчен җаваплылык . . 11
28 статья. Гаепсез зыян китерү 11

6 бүлек. Тәмамланмаган җинаять

29 статья. Тәмамланган һәм тәмамланмаган җинаятьләр 12
30 статья. Җинаятькә әзерләнү һәм җинаять кылуга омтылу 12
31 статья. Җинаятьтән ихтыяри рәвештә баш тарту 12

7 бүлек. Җинаятьтә катнашу

32 статья. Җинаятьтә катнашу төшенчәсе 13
33 статья. Җинаятьтә катнашучыларның төрләре 13
34 статья. Җинаятьтә катнашучыларның җаваплылыгы 14
35 статья. Затлар төркеме, алдан килешенгән затлар төркеме, оешкан төркем яисә җинаять берлеге (җинаять оешмасы) тарафыннан җинаять кылу 14
36 статья. Җинаять башкаручының эксцессы 15

8 бүлек. Кылган гамәлдәге җинаятьчелләкне юкка чыгаручы шартлар

37 статья. Үз-үзеңне яклау 16
38 статья. Җинаять кылган затны кулга алганда зыян китерү 16
39 статья. Иң чик зарурлык 17
40 статья. Физик яисә психик мәҗбүр итү 17
41 статья. Нигезле рәвештә хәтәр гамәл кылу 17
42 статья. Боерыкны яисә күрсәтмәне үтәү 18

III кисәк. Җәза

9 бүлек. Җәза төшенчәсе һәм максатлары. Җәза төрләре

43 статья. Җәза төшенчәсе һәм максатлары 18
44 статья. Җәза төрләре 18
45 статья. Төп һәм өстәмә җәза төрләре 19
46 статья. Штраф 19
47 статья. Аерым вазифаларны биләү яисә аерым эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм итү 19
48 статья. Махсус, хәрби яисә мактаулы исемнәрдән, класслы чиннан һәм дәүләт бүләкләреннән мәхрүм итү 20
49 статья. Мәҗбүри эшләр 20
50 статья. Төзәтү эшләре 21
51 статья. Хәрби хезмәт буенча чикләү 21
52 статья. *Үз көчен югалтты.* 22
53 статья. Ирекне чикләү 22
54 статья. Кулга алу 22
55 статья. Дисциплинар хәрби частьта тоту 23
56 статья. Билгеле бер срокка иректән мәхрүм итү 23
57 статья. Гомерлеккә иректән мәхрүм итү 23
58 статья. Иректән мәхрүм итүгә хөкем ителгән затларга төзәтү учреждениесе рәвешен билгеләү 24
59 статья. Үлем җәзасы 25

10 бүлек. Җәза билгеләү

60 статья. Җәза билгеләүнең гомуми башлангычлары 25
61 статья. Җәзаны җиңеләйтә торган шартлар 25
62 статья. Җәзаны җиңеләйтә торган шартлар булганда җәза билгеләү 26
63 статья. Җәзаны авырайта торган шартлар 26
64 статья. Кылган җинаять өчен каралганнан җиңелрәк җәза билгеләү 27
65 статья. Присяжный утырышчыларның мәрхәмәтлелек күрсәтү турында вердикты булганда җәза бирү 28
66 статья. Тәмамланмаган җинаять өчен җәза билгеләү 28
67 статья. Катнашып кылган җинаять өчен җәза билгеләү 29
68 статья. Җинаятьләр рецидивы булганда җәза билгеләү 29
69 статья. Җинаятьләр җыелмасы буенча җәза билгеләү 29
70 статья. Хөкем карарлары җыелмасы буенча җәза билгеләү 30
71 статья. Җәзаларны берләштергәндә җәза срокларын билгеләү тәртибе 30
72 статья. Җәза срокларын исәпләү һәм җәзаны исәпкә кертү 31
73 статья. Шартлы хөкем итү 32
74 статья. Шартлы хөкем итүне юкка чыгару яисә сынау срогын озайту 32

IV кисәк. Җинаять җаваплылыгыннан һәм җәзадан азат итү

11 бүлек. Җинаять җаваплылыгыннан азат итү

75 статья. Эшлекле тәүбә итүгә бәйле рәвештә җинаять җаваплылыгыннан азат итү 33
76 статья. Зыян күрүче белән килешүгә бәйле рәвештә җинаять җаваплылыгыннан азат итү 34
77 статья. *Үз көчен югалтты.* 34
78 статья. Җавапка тарту сроклары узуга бәйле рәвештә җинаять җаваплылыгыннан азат итү 34

12 бүлек. Җәзадан азат итү

79 статья. Җәза узудан шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итү . . 35
80 статья. Узып бетмәгән җәза өлешен җиңелрәк җәза төренә алмаштыру 36
80.1 статья. Шартлар үзгәрү аркасында җәзадан азат итү 36
81 статья. Чирләү аркасында җәзадан азат итү 37
82 статья. Йөкле хатыннарга һәм кечкенә балалары булган хатын-кызларга җәза узуны кичектерү 37
83 статья. Судның хөкем карарының җавапка тарту срогы чыгуга бәйле рәвештә җәза узудан азат итү 38

13 бүлек. Амнистия. Ярлыкау. Хөкем ителү

84 статья. Амнистия 38
85 статья. Ярлыкау 39
86 статья. Хөкем ителү 39

V кисәк. Балигъ булмаган затларның җинаять җаваплылыгы

14 бүлек. Балигъ булмаган затларның җинаять җаваплылыгы һәм аларга җәза үзенчәлекләре

87 статья. Балигъ булмаган затларның җинаять җаваплылыгы 40
88 статья. Балигъ булмаган затларга билгеләнүче җәза төрләре 40
89 статья. Балигъ булмаган затка җәза билгеләү 41
90 статья. Тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чаралар куллану 41
91 статья. Тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чараларның асылы 42
92 статья. Балигъ булмаган затларны җәзадан азат итү 43
93 статья. Җәза узудан шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итү . . . 44
94 статья. Җавапка тарту сроклары 44
95 статья. Хөкем ителүне юкка чыгару сроклары 44
96 статья. Әлеге бүлек нигезләмәләрен унсигез яшьтән егерме яшькә кадәрге затларга карата куллану 44

VI кисәк. Медицина характерындагы мәҗбүри чаралар

15 бүлек. Медицина характерындагы мәҗбүри чаралар

97 статья. Медицина характерындагы мәҗбүри чараларны куллану нигезләре 45
98 статья. Медицина характерындагы мәҗбүри чараларны куллану максатлары 45
99 статья. Медицина характерындагы мәҗбүри чараларның төрләре . . 46
100 статья. Амбулатор мәҗбүри күзәтү һәм психиатр-табибта дәвалану 46
101 статья. Психиатрия стационарында мәҗбүри дәвалау 46
102 статья. Медицина характерындагы мәҗбүри чаралар куллануны озайту, үзгәртү һәм туктату 47
103 статья. Медицина характерындагы мәҗбүри чаралар куллану вакытын исәпкә керту 47
104 статья. Җәза узуга өстәлгән медицина характерындагы мәҗбүри чаралар 48

МАХСУС ӨЛЕШ

VII кисәк. Шәхескә каршы җинаятьләр

16 бүлек. Гомергә һәм сәламәтлеккә каршы җинаятьләр

105 статья. Үтерү 48
106 статья. Ана кешенең яңа туган баласын үтерүе 49
107 статья. Аффект хәлендә булганда үтерү 49
108 статья. Үз-үзеңне яклау чикләрен арттырып җибәргәндә йә җинаять кылган затны тоткарлау өчен кирәкле чаралар куллануны арттырып җибәргәндә үтерү 50
109 статья. Саксызлык аркасында үлемгә китерү 50
110 статья. Үз-үзен үтерүгә җиткерү 50
111 статья. Аңлы рәвештә сәламәтлеккә зур зыян китерү 50
112 статья. Аңлы рәвештә сәламәтлеккә уртача авырлыкта зыян китерү 51

113 статья. Аффект хәлендә сәламәтлеккә зур яисә уртача авырлыкта зыян китерү 52
114 статья. Үз-үзеңне яклау чикләрен арттырып җибәргәндә йә җинаять кылган затны тоткарлау өчен кирәкле чаралар куллануны арттырып җибәргәндә сәламәтлеккә зур яисә уртача авырлыкта зыян китерү 52
115 статья. Сәламәтлеккә аңлы рәвештә җиңелчә зыян китерү 52
116 статья. Кыйнаулар 53
117 статья. Җәфалау 53
118 статья. Саксызлык аркасында сәламәтлеккә зур зыян китерү 54
119 статья. Үтерү яисә сәламәтлеккә зур зыян китерү белән янау 54
120 статья. Трансплантацияләү өчен кеше әгъзаларын яисә тукымаларын алырга мәҗбүр итү 54
121 статья. Венерик авыру йоктыру 55
122 статья. ВИЧ-инфекция йоктыру 55
123 статья. Законсыз аборт ясау 56
124 статья. Авыруга ярдәм күрсәтмәү 56
125 статья. Куркыныч астында калдыру 56

17 бүлек. Шәхеснең ирегенә, намусына һәм абруена каршы җинаятьләр

126 статья. Кеше урлау 57
127 статья. Законсыз рәвештә иректән мәхрүм итү 57
127.1 статья. Кешеләр белән сәүдә итү 58
127.2 статья. Коллык хезмәтеннән файдалану 59
128 статья. Психиатрия стационарына законсыз урнаштыру 59
129 статья. Яла ягу 60
130 статья. Хурлау 60

18 бүлек. Шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенес ирегенә каршы җинаятьләр

131 статья. Көчләү 61
132 статья. Сексуаль характердагы көч куллану гамәлләре 61
133 статья. Сексуаль характердагы гамәлләр кылуга мәҗбүр итү 62
134 статья. Уналты яше тулмаган зат белән җенси мөнәсәбәткә керү һәм сексуаль характердагы башка гамәлләр кылу 62
135 статья. Бозыклык гамәлләре кылу 63

19 бүлек. Кеше һәм гражданның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә каршы җинаятьләр

136 статья. Кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре тигезлеген бозу 63
137 статья. Хосусый тормыш кагылгысызлыгын бозу 63
138 статья. Хатлар язышу, телефоннан сөйләшү, почта, телеграф яисә башкача хәбәрләшү серен бозу 64
139 статья. Торак кагылгысызлыгын бозу 64
140 статья. Гражданга мәгълүмат бирүдән баш тарту 65
141 статья. Сайлау хокукларын гамәлгә ашыруга яисә сайлау комиссияләренең эшенә комачаулык итү 65
141.1 статья. Кандидатның, сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының

сайлау кампаниясен финанслау, референдум уздыру буенча инициатив төркемнең, референдумда катнашучыларның бүтән төркеменең эшчәнлек тәртибен бозу 66
142 статья. Сайлау документларын, референдум документларын фальсификацияләү 68
142.1 статья. Тавыш бирү йомгакларын фальсификацияләү . . . 69
143 статья. Хезмәтне саклау кагыйдәләрен бозу 70
144 статья. Журналистларның законлы профессиональ эшчәнлегенә комачаулау 70
145 статья. Йөкле хатын-кызны яисә өч яшькә кадәрге балалары булган хатын-кызны эшкә алудан нигезсез баш тарту яисә нигезсез эштән азат итү 70
145.1 статья. Хезмәт хакын, пенсияләрне, стипендияләрне, пособияләрне һәм башка түләүләрне түләмәү 71
146 статья. Авторлык хокукларын һәм катнаш хокукларны бозу 71
147 статья. Уйлап табу һәм патентлык хокукларын бозу 72
148 статья. Вөҗдан һәм дин тоту ирегe хокукын гамәлгә ашыруга комачаулык итү 72
149 статья. Җыелыш, митинг, демонстрация, урам йөрешләрен, пикетлауларны уздыруга яисә аларда катнашуга комачаулык итү 73

20 бүлек. Гаиләгә һәм балигъ булмаган затларга каршы җинаятьләр

150 статья. Балигъ булмаган затны җинаять кылуга җәлеп итү 73
151 статья. Балигъ булмаган затны җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү 74
152 статья. *Үз көчен югалтты.* 74
153 статья. Бала алыштыру 74
154 статья. Законсыз уллыкка (кызлыкка) алу 74
155 статья. Уллыкка (кызлыкка) алу серен фаш итү 75
156 статья. Балигъ булмаган затны тәрбияләү вазифаларын үтәмәү 75
157 статья. Балаларны яисә хезмәткә сәләтсез ата-аналарны тоту өчен акчалар түләүдән явыз ният белән читләшү 75

VIII кисәк. Икътисад өлкәсендә җинаятьләр

21 бүлек. Милеккә каршы җинаятьләр

158 статья. Караклык 76
159 статья. Мошенниклык 77
160 статья. Үзләштерү яисә өскә чыгару (растрата) 78
161 статья. Талау 79
162 статья. Юлбасарлык 79
163 статья. Куркытып алу 80
164 статья. Аерым кыйммәткә ия предметларны урлау 81
165 статья. Алдау яисә ышанычка керү юлы белән мөлкәти зарар китерү 81
166 статья. Урлау максатыннан башка гына законсыз рәвештә автомобильгә яисә башка транспорт чарасына хуҗа булу 82
167 статья. Мөлкәтне аңлы рәвештә юкка чыгару яисә зарарлау 82
168 статья. Саксызлык аркасында мөлкәтне юкка чыгару яисә зарарлау 83

22 бүлек. Икътисади эшчәнлек өлкәсендә җинаятьләр

169 статья. Законлы эшкуарлык эшчәнлегенә яисә башка эшчәнлеккә комачаулау 83
170 статья. Җир белән законсыз алыш-бирешләрне теркәү 84
171 статья. Законсыз эшкуарлык эшчәнлеге 84
171.1 статья. Маркировкаланмаган товарларны һәм продукцияне җитештерү, юнәтү, саклау, ташу яисә сату 85
172 статья. Законсыз банк эшчәнлеге 85
173 статья. Ялган эшкуарлык эшчәнлеге 86
174 статья. Җинаять юлы белән башка затлар тарафыннан юнәтелгән акчаларны яисә башка мөлкәтне легальләштерү 86
174.1 статья. Зат тарафыннан җинаять кылып юнәтелгән акчаларны яисә бүтән мөлкәтне легальләштерү 87
175 статья. Җинаять юлы белән табылганын белә торып, мөлкәтне алу яисә сату 88
176 статья. Законсыз кредит алу 89
177 статья. Кредит бурычын түләүдән явыз ният белән читләшү 89
178 статья. Конкуренцияне булдырмау, чикләү яисә бетерү 89
179 статья. Алыш-биреш гамәлләрен кылуга яисә аны кылудан баш тартуга мәҗбүр итү 90
180 статья. Товар тамгасын законсыз файдалану 90
181 статья. Дәүләт пробалары келәймәләрен әзерләү һәм файдалану кагыйдәләрен бозу 91
182 статья. *Үз көчен югалтты.* 91
183 статья. Коммерция, салым яисә банк серен тәшкил итүче белешмәләрне законсыз алу һәм фаш итү 91
184 статья. Һөнәри спорт ярышларында һәм тамашалы коммерция конкурсларында катнашучыларны һәм оештыручыларны сатып алу 92
185 статья. Кыйммәтле кәгазьләрне эмиссияләгәндә явыз ният белән файдалану 93
185.1 статья. Инвесторга яисә контроль органына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән кыйммәтле кәгазьләр турында мәгълүмат бирүдән явыз ният белән читләшү 94
186 статья. Ялган акчалар яисә кыйммәтле кәгазьләр әзерләү яки сату 94
187 статья. Ялган кредит йә исәп-хисап карталарын һәм бүтән түләү документларын әзерләү яисә сату 95
188 статья. Контрабанда 95
189 статья. Күпләп юк итү коралы ясауда, коралланууда һәм хәрби техника ясауда кулланылырга мөмкин булган чималны, материалларны, җайланманы, технологияләрне, фәнни-техник мәгълүматны читкә законсыз чыгару яисә тапшыру, эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) законсыз башкару 96
190 статья. Россия Федерациясе территориясенә Россия Федерациясе һәм чит ил халыкларының сәнгати, тарихи һәм археологик казаныш предметларын кире кайтармау 97
191 статья. Кыйммәтле металларның, табигый кыйммәтле ташларның яисә энҗенең законсыз әйләнеше 97
192 статья. Дәүләткә кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле ташлар тапшыру кагыйдәләрен бозу 98
193 статья. Чит ил валютасын чит илдән кире кайтармау 98
194 статья. Оешмадан яисә физик заттан алына торган таможня түләүләрен түләүдән читләшү 98
195 статья. Бөлгенлек вакытында кылган законсыз гамәлләр 99

196 статья. Алдан ниятләп бөлгенлеккә төшү 100
197 статья. Фиктив бөлгенлек 100
198 статья. Физик заттан салымнар һәм (яисә) җыемнар түләүдән читләшү 101
199 статья. Оешмалардан салымнар һәм (яисә) җыемнар түләүдән читләшү 101
199.1 статья. Салым агенты вазифаларын үтәмәү 102
199.2 статья. Оешманың яисә индивидуаль эшкуарның салымнар һәм (яисә) җыемнар түләнергә тиешле акчаларын йә мөлкәтен яшереп калу 103
200 статья. *Үз көчен югалтты.* 103

23 бүлек. Коммерция оешмаларында һәм башка оешмаларда хезмәт мәнфәгатьләренә каршы җинаятьләр

201 статья. Вәкаләтләрдән явыз ниятгә файдалану 103
202 статья. Хосусый нотариуслар һәм аудиторлар тарафыннан вәкаләтләрне явыз ниятгә файдалану 104
203 статья. Детектив хезмәтләр яисә хосусый сак хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен арттырып куллланулары 105
204 статья. Коммерциячел сатып алу 105

IX кисәк. Җәмәгать иминлегенә һәм җәмәгать тәртибенә каршы җинаятьләр

24 бүлек. Җәмәгать иминлегенә каршы җинаятьләр

205 статья. Террорчылык 106
205.1 статья. Террорчылык характерындагы җинаятьләр кылуга җәлеп итү яисә аларны кылуга башкача булышу 107
206 статья. Тотык алу 108
207 статья. Террорчылык акты турында белә торып ялган хәбәр итү . . 108
208 статья. Законсыз кораллы формирование оештыру яисә анда катнашу 108
209 статья. Бандитчылык 109
210 статья. Җинаятьчел җәмгыять (җинаятьчел оешма) оештыру . . . 109
211 статья. Һава яисә су транспорты судносын йә тимер юл хәрәкәте составын куып алып китү 110
212 статья. Массакүләм тәртипсезлекләр 111
213 статья. Хулиганлык 111
214 статья. Вандализм 111
215 статья. Атом энергетикасы объектларында куркынычсызлык кагыйдәләрен бозу 112
215.1 статья. Электр энергиясен бирүне туктату яисә чикләү йә башка яшәеш чыганакларын өзү 112
215.2 статья. Яшәеш объектларын яраксыз хәлгә җиткерү 113
216 статья. Тау, төзелеш эшләрен яисә башка эшләрне алып барганда куркынычсызлык кагыйдәләрен бозу 113
217 статья. Шартлау куркынычы булган объектларда куркынычсызлык кагыйдәләрен бозу 114
218 статья. Шартлаткыч, тиз кабынучан матдәләрне һәм пиротехника әйберләрен исәпкә алу, саклау, ташу һәм файдалану кагыйдәләрен бозу 114
219 статья. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу 115

220 статья. Атом-төш материаллары яисә радиоактив матдәләр белән законсыз эш итү 115
221 статья. Атом-төш материалларын яисә радиоактив матдәләрне урлау йә куркытып алу 116
222 статья. Коралны, аның төп өлешләрен, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне яисә шартлаткыч җайланмаларны законсыз юнәтү, тапшыру, сату, саклау, ташу яисә йөртү 116
223 статья. Коралны законсыз әзерләү 117
224 статья. Утлы ату коралын саксыз рәвештә саклау 118
225 статья. Коралны, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне һәм шартлаткыч җайланмаларны саклау йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәү 118
226 статья. Коралны, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне һәм шартлаткыч җайланмаларны урлау йә куркытып алу 119
227 статья. Пиратлык 119

25 бүлек. Халыкның сәламәтлегенә һәм җәмгыятьнең әхлаклылыгына каршы җинаятьләр

228 статья. Наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне законсыз юнәтү, саклау, ташу, әзерләү, эшкәртү 120
228.1 статья. Наркотик чараларны, психотроп матдәләрне һәм аларның аналогларын законсыз җитештерү, сату яисә җибәрү 121
228.2 статья. Наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр әйләнеше кагыйдәләрен бозу 121
229 статья. Наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне урлау яисә куркытып алу 122
230 статья. Наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне куллануга җәлеп итү 123
231 статья. Наркотик матдәләре булган һәм үстерү тыелган үсемлекләрне законсыз культивацияләү 123
232 статья. Наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр куллану өчен притоннар оештыру йә тоту 124
233 статья. Наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр алу хокукы бирә торган рецептларны яисә башка документларны законсыз бирү йә ясау 124
234 статья. Сату максатларында көчле тәэсир итүче яисә агулы матдәләрнең законсыз әйләнеше 124
235 статья. Хосусый медицина практикасы яисә хосусый фармацевтика эшчәнлеге белән законсыз шөгыльләнү 125
236 статья. Санитария-эпидемиология кагыйдәләрен бозу 125
237 статья. Кешеләрнең гомеренә яисә сәламәтлегенә куркыныч тудыручы хәлләр турындагы мәгълүматны яшерү 126
238 статья. Иминлек таләпләренә җавап бирми торган товарларны һәм продукцияне җитештерү, саклау, ташу йә сату, эшләр башкару яисә хезмәт күрсәтү 126
239 статья. Гражданнарның шәхесенә һәм хокукларына янаучы берләшмә оештыру 127
240 статья. Фахишәлек белән шөгыльләнүгә җәлеп итү 128
241 статья. Фахишәлек шөгылен оештыру 128
242 статья. Порнография материалларын яисә предметларын законсыз тарату 128
242.1 статья. Балигъ булмаган затларның порнография сурәтләре төше-

релгән материалларны яисә предметларны әзерләү һәм аларның әйләнеше . . . 129
243 статья. Тарих һәм мәдәният ядкярләрен юкка чыгару яисә зарарлау . . . 129
244 статья. Мәетләрне һәм аларны күмү урыннарын мәсхәрәләү . . . 130
245 статья. Хайваннарга карата кырыс мөгамәлә . . . 130

26 бүлек. Экология җинаятьләре

246 статья. Эшләр башкарганда әйләнә-тирә мохитне саклау кагыйдәләрен бозу . . . 131
247 статья. Экологик хәвефле матдәләр һәм калдыклар әйләнеше кагыйдәләрен бозу . . . 131
248 статья. Микробиологик йә башка биологик агентлар яисә токсиннар белән эш иткәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен бозу . . . 132
249 статья. Ветеринария кагыйдәләрен һәм үсемлек авырулары һәм корткычлары белән көрәшү өчен билгеләнгән кагыйдәләрне бозу . . . 132
250 статья. Суларны пычрату . . . 132
251 статья. Атмосфераны пычрату . . . 133
252 статья. Диңгез мохитен пычрату . . . 134
253 статья. Россия Федерациясенең континенталь шельфы һәм махсус икътисади зонасы турында Россия Федерациясе законнарын бозу . . . 134
254 статья. Җир бозу . . . 135
255 статья. Җир асты байлыкларын саклау һәм алардан файдалану кагыйдәләрен бозу . . . 135
256 статья. Су хайваннарын һәм үсемлекләрен законсыз тоту (чыгару) . . . 136
257 статья. Балык запасларын саклау кагыйдәләрен бозу . . . 137
258 статья. Законсыз аучылык . . . 137
259 статья. Россия Федерациясе Кызыл китабына кертелгән организмнар өчен критик яшәү мохитен юкка чыгару . . . 138
260 статья. Агачларны һәм куаклыкларны законсыз кисү . . . 138
261 статья. Урманнарны бетерү яисә зарарлау . . . 139
262 статья. Махсус сакланылучы табигать территорияләре һәм табигать объектлары режимын бозу . . . 139

27 бүлек. Транспорт хәрәкәте иминлегенә һәм эксплуатацияләүгә каршы җинаятьләр

263 статья. Тимер юл, һава һәм су транспортының хәрәкәт иминлеген һәм эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу . . . 140
264 статья. Юл хәрәкәте һәм транспорт чараларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу . . . 140
265 статья. *Үз көчен югалтты.* . . . 141
266 статья. Транспорт чараларын сыйфатсыз ремонтлау һәм аларны техник төгәлсезлекләр белән эксплуатациягә чыгару . . . 141
267 статья. Транспорт чараларын яисә аралашу юлларын яраксыз хәлгә китерү . . . 141
268 статья. Транспортның хәвефсез эшләвен тәэмин итүче кагыйдәләрне бозу . . . 142
269 статья. Магистраль торбаүткәргечләрне төзегәндә, эксплуатацияләгәндә яисә ремонтлаганда иминлек кагыйдәләрен бозу . . . 142

270 статья. Судно капитанының афәткә юлыгучыларга ярдәм күрсәтмәве 143
271 статья. Халыкара очыш кагыйдәләрен бозу 143

28 бүлек. Компьютер мәгълүматы өлкәсендәге җинаятьләр

272 статья. Компьютер мәгълүматына хокуксыз керү 143
273 статья. ЭВМ өчен зарарлы чыганагы булган программалар төзү, куллану һәм тарату 144
274 статья. ЭВМ, ЭВМ системасын яисә аларның челтәрен эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу 144

X кисәк. Дәүләт хакимиятенә каршы җинаятьләр

29 бүлек. Дәүләтнең конституциячел корылышы нигезләренә һәм иминлегенә каршы җинаятьләр

275 статья. Дәүләткә хыянәт 145
276 статья. Шпионаж 145
277 статья. Дәүләт яисә җәмәгать эшлеклесе гомеренә кул сузу 146
278 статья. Хакимиятне көч кулланып алу яисә хакимиятне көч кулланып тоту 146
279 статья. Хәрби фетнә 146
280 статья. Экстремистлык эшчәнлеген башкаруга ачыктан-ачык өндәүләр 146
281 статья. Диверсия 146
282 статья. Нәфрәт йә дошманлык тудыру, шулай ук кешелек абруен төшерү 147
282.1 статья. Экстремистлык җәмгыяте оештыру 147
282.2 статья. Экстремистлык оешмасы эшчәнлеген оештыру 148
283 статья. Дәүләт серен ачу 149
284 статья. Дәүләт серен тәшкил итүче документларны югалту 149

30 бүлек. Дәүләт хакимиятенә, дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнарындагы хезмәт мәнфәгатьләренә каршы җинаятьләр

285 статья. Урындагы зат вәкаләтләреннән явыз ниятләрдә файдалану 150
285.1 статья. Бюджет акчаларын максатсыз тоту 151
285.2 статья. Бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчаларын максатсыз тоту 151
286 статья. Эш урынындагы вәкаләтләрне арттырып куллану 152
287 статья. Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә яисә Россия Федерациясе Хисап палатасына мәгълүмат бирүдән баш тарту 153
288 статья. Урындагы затның вәкаләтләрен үзләштерү 154
289 статья. Эшкуарлык эшчәнлегендә законсыз катнашу 154
290 статья. Ришвәт алу 154
291 статья. Ришвәт бирү 155
292 статья. Хезмәт урынындагы алдау 155
293 статья. Ваемсызлык 156

31 бүлек. Хөкем итүгә каршы җинаятьләр

294 статья. Хөкем итүгә һәм алдан һәрьяклап тикшерүне башкаруга каршылык күрсәтү 156
295 статья. Хөкем итүче яисә алдан һәрьяклап тикшерү алып баручы затның гомеренә кул сузу 157
296 статья. Хөкем итүгә яисә алдан һәрьяклап тикшерү алып баруга бәйле янау яисә көч куллану гамәлләре 157
297 статья. Судка ихтирамсызлык күрсәтү 158
298 статья. Судьяга, присяжный утырышчыга, прокурорга, тикшерүчегә, башлап сорау алуны башкаручы затка, суд приставына, суд башкаручысына карата яла ягу 158
299 статья. Гаепсез затны белә торып җинаять җаваплылыгына тарту . 159
300 статья. Җинаять җаваплылыгыннан законсыз азат итү 159
301 статья. Законсыз тоткарлау, сак астына алу яисә сак астында тоту . 159
302 статья. Күрсәтмәләр бирүгә мәҗбүр итү 160
303 статья. Дәлилләрне фальсификацияләү 160
304 статья. Ришвәт алуга йә коммерциячел сатып алуга провокацияләү 161
305 статья. Белә торып гадел булмаган хөкем карары, суд карары яисә башка суд акты чыгару 161
306 статья. Белә торып ялган әләк 161
307 статья. Белә торып ялган күрсәтмә бирү, эксперт, белгеч бәяләмәсе яисә дөрес тәрҗемә итмәү 162
308 статья. Шаһитның яисә зыян күрүченең күрсәтмәләр бирүдән баш тартуы 162
309 статья. Күрсәтмәләр бирү яисә күрсәтмәләр бирүдән читләшү йә дөрес тәрҗемә итмәү өчен сатып алу яисә мәҗбүр итү . . . 162
310 статья. Алдан һәрьяклап тикшерү белешмәләрен фаш итү . . . 163
311 статья. Судьяга һәм җинаять процессында катнашучыларга карата кулланыла торган иминлек чаралары турындагы белешмәләрне фаш итү 163
312 статья. Опись ясалган яисә арест салынган йә конфискацияләнергә тиешле мөлкәткә карата законсыз гамәлләр 164
313 статья. Иректән мәхрүм итү, кулга алу яисә сак астында тоту урыныннан качу 164
314 статья. Иректән мәхрүм ителүдән читләшү 165
315 статья. Судның хөкем карарын, суд карарын яисә башка суд актын үтәмәү 165
316 статья. Җинаятьләрне яшереп калу 165

32 бүлек. Идарә итү тәртибенә каршы җинаятьләр

317 статья. Хокук саклау органы хезмәткәре гомеренә кул сузу . . . 166
318 статья. Хакимият вәкиленә карата көч куллану 166
319 статья. Хакимият вәкилен хурлау 166
320 статья. Хокук саклау яисә контрольдә тоту органының урындагы затына карата кулланыла торган иминлек чаралары турындагы белешмәләрне фаш итү 166
321 статья. Җәмгыятьтән изоляцияләүне тәэмин итүче учреждениеләр эшчәнлеген таркату 167
322 статья. Россия Федерациясе Дәүләт чиген законсыз үтү . . . 167
322.1 статья. Законсыз миграция оештыру 168
323 статья. Россия Федерациясе Дәүләт чиген хокукка каршы килеп үзгәртү 168

324 статья. Рәсми документларны һәм дәүләт бүләкләрен юнәтү яки сату 168
325 статья. Документлар, штамплар, мөһерләр урлау яисә зарарлау йә акциз җыемнары маркаларын, махсус маркаларны яисә тәңгәллек тамгаларын урлау 169
326 статья. Транспорт чарасының идентефикация номерын охшатып ясау яисә юкка чыгару 169
327 статья. Ялган документларны, дәүләт бүләкләрен, штампларны, мөһерләрне, бланкларны охшатып ясау, әзерләү яисә сату 170
327.1 статья. Охшатып ясалган акциз җыемнары маркаларын, махсус маркаларны яисә тәңгәллек тамгаларын әзерләү, сату йә алардан файдалану 170
328 статья. Хәрби хезмәт һәм альтернатив граждан хезмәте узудан читләшү 171
329 статья. Россия Федерациясе Дәүләт гербын яисә Россия Федерациясе Дәүләт флагын мәсхәрәләү 171
330 статья. Башбаштаклык 171

XI кисәк. Хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр

33 бүлек. Хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр

331 статья. Хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр төшенчәсе 172
332 статья. Боерыкны үтәмәү 172
333 статья. Башлыкка каршы килү яисә аны хәрби хезмәт вазифаларын бозуга мәҗбүр итү 172
334 статья. Башлыкка каршы көч куллану гамәлләре 173
335 статья. Хәрби хезмәткәрләр арасында үзара буйсыну мөнәсәбәтләре булмаганда, үзара мөнәсәбәтләрнең устав кагыйдәләрен бозу . . . 173
336 статья. Хәрби хезмәткәрне хурлау 174
337 статья. Частьны яисә хезмәт урынын башбаштакланып ташлап китү 174
338 статья. Дезертирлык 175
339 статья. Хәрби хезмәт вазифаларын үтәүдән авыруга сабышып яисә башка алымнар белән читләшү 175
340 статья. Хәрби дежур тору кагыйдәләрен бозу 175
341 статья. Чик буе хезмәтен узу кагыйдәләрен бозу 176
342 статья. Каравыл хезмәтенең устав кагыйдәләрен бозу 176
343 статья. Җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү хезмәтен узу кагыйдәләрен бозу 176
344 статья. Эчке хезмәт узу һәм гарнизонда патрульлек итүнең устав кагыйдәләрен бозу 177
345 статья. Һәлакәткә юлыккан хәрби корабльне ташлап китү 177
346 статья. Хәрби мөлкәтне аңлы рәвештә юкка чыгару яисә зарарлау 177
347 статья. Хәрби мөлкәтне саксызлык аркасында юкка чыгару яисә зарарлау 177
348 статья. Хәрби мөлкәтне югалту 178
349 статья. Тирә-юньдәгеләр өчен аеруча куркыныч корал һәм предметлар белән эш итү кагыйдәләрен бозу 178
350 статья. Машина йөртү яисә эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу . . 178
351 статья. Очыш яисә аңа әзерлек кагыйдәләрен бозу 179
352 статья. Корабль йөртү кагыйдәләрен бозу 179

XII кисәк. Тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә каршы җинаятьләр

34 бүлек. Тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә каршы җинаятьләр

353 статья. Агрессив сугышны планлаштыру, әзерләү, башлау яисә алып бару 179
354 статья. Агрессив сугыш башлауга ачыктан-ачык өндәүләр 180
355 статья. Күпләп юк итү коралын эшләү, җитештерү, туплау, юнәтү яисә сату 180
356 статья. Сугыш алып баруның тыелган чараларын һәм ысулларын куллану 180
357 статья. Геноцид 180
358 статья. Экоцид 181
359 статья. Яллау 181
360 статья. Халыкара яклаудан файдаланучы затларга яисә учреждениеләргә һөҗүм итү 181

«РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ҖИНАЯТЬ КОДЕКСЫН ГАМӘЛГӘ КЕРТҮ ТУРЫНДА» ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОН 183

Заказное издание

УГОЛОВНЫЙ КОДЕКС РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Заказ басма

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ҖИНАЯТЬ КОДЕКСЫ

Редакторы *В.Р.Камалиева*
Бизәлеш редакторы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Г.Х.Сундукова, Л.З.Шиһапова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.06.2006. Форматы $60\times84^{1}/_{16}$.
Шартлы басма табагы 11,62. Шартлы буяу-оттиск 11,74. Нәшер-хисап табагы 11,69.
Тиражы 2000. Заказ З-479.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.